*Татарстанда*

# ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ

**№4 НОЯБРЬ 2015**

МЕСТНОЕ САМОУПРАВЛЕНИЕ В ТАТАРСТАНЕ

ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 16867
















## Муниципаллар Казанда җыелды

8 бит

*Татарстанда*
# ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ
**МЕСТНОЕ САМОУПРАВЛЕНИЕ В ТАТАРСТАНЕ**

№4, ноябрь 2015
Мәгълүмати-аналитик, иҗтимагый-сәяси басма

**БАШ МӨХӘРРИР**
Нияз ӘХМӘДУЛЛИН, e-mail: redaktorms@gmail.com

**БАШ МӨХӘРРИР УРЫНБАСАРЫ**
Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ

**ЧЫГАРЫЛЫШ МӨХӘРРИРЕ**
Фәридә Әхмәтҗанова

**ЖУРНАЛИСТЛАР**
Любовь Гусева, Вероника Кәлимуллина,
Людмила Карташова, Олег Платонов

**ФОТОГРАФ**
Андрей Титов

**ВЕРСТКА**
Евгений Курьянов

**КОРРЕКТОР**
Айсылу Корманова

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт Идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү турындагы таныклык ПИ №ТУ 16-00621, 29.09.2011.

Журнал татар һәм рус телләрендә нәшер ителә.
Гомуми тираж: 3073 данә (татар телендә – 1311 данә,
рус телендә – 1762 данә)

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстанда җирле үзидарә» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

**РЕДАКЦИЯ:**
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2нче йорт
Тел.: (843) 293-60-15

«Казанская недвижимость» Нәшрият йорты» ЯАҖндә басылды.
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2нче йорт
Заказ: № 10676
Офсет басма
Басарга кул куелды: 24.11.2015

16+

**Гамәлгә куючы һәм нәшер итүче:**
**Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы 420014,**
**Татарстан Республикасы, Казан, Кремль**

## ЭЧТӘЛЕК



*Рөстәм МИҢНЕХАНОВ: «Без тагын да бердәмрәк, көчлерәккә әверелдек»* **4 бит**



*ТАТАРСТАН – үрнәк төбәк (Россия муниципаллары Казанга җыелды)* **8 бит**



*Виктор КИДЯЕВ: «Бурыч – кешеләрнең тормышын уңайлырак, хакимиятне якынрак итү»* **12 бит**

**РЕДКОЛЛЕГИЯ:**
РӘИС –
**Шакиров Минсәгыйть Закирович,** Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе

**Андреева Людмила Николаевна** – Казан шәһәр думасы секретаре

**Белов Александр Николаевич** – Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча департамент җитәкчесе

**Воропаева Татьяна Васильевна** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе урынбасары

**Гарипов Илнур Мәхмүтович** – ТР Президенты Аппараты җитәкчесе урынбасары – ТР Президентының Территорияләр белән эш идарәсе башлыгы

**Гусева Любовь Акимовна** – сәясәт фәннәре кандидаты, КФУның дәүләт һәм муниципаль идарә кафедрасы доценты

**Ратникова Римма Атласовна** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары

**Хәбибуллин Альберт Галимҗанович** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе



*РЕСПУБЛИКА саннарда* **18 бит**

*«Кар өстендәге ИСЛАМ», яки Киләчәккә йөз тоткан традицияләр* **22 бит**





*ҖИРЛЕ үзидарә: чит илләр тәҗрибәсе* **24 бит**

*Барыр ЮЛЛАР киң булсын* **28 бит**







*БАРЫСЫН да кадрлар хәл итә* **30 бит**

*ТУГАН йорт ишекләре һәрчак ачык* **34 бит**



*КЫРДАГЫ һава торышы* **36 бит**

*ШӘХСИ хуҗалыкта – дәүләт мәнфәгате* **40 бит**






*ТИУ: куллану буенча күрсәтмә* **44 бит**

*БӘХЕТЕН туган җирендә тапкан* **48 бит**






*НУРЛАТ районы: үсеш стратегиясе* **52 бит**

*Унбер «МИН»* **56 бит**





*КАНУН яңалыклары* **60 бит**

*АСК көне* **64 бит**



## ЭКСТРЕМИЗМГА КАРШЫ КООРДИНАЦИЯ

22 октябрьдә Чистайда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә Татарстан Республикасында Терроризмга каршы көрәш комиссиясе һәм ТРнда Хокук тәртибен тәэмин итү буенча координация киңәшмәсенең берләштерелгән утырышы булып узды. Чарада ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР Куркынычсызлык советы сәркатибе Айрат Шәфигуллин, ТР Премьер-министрының беренче урынбасары Алексей Песошин, ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсагыйть Шакиров һәм башкалар катнашты.

Республика башлыгы, катнашучылар алдында чыгыш ясап, хәзерге заман экстремизмы һәм терроризмның үзгәрүен һәм төрле идеологик һәм икътисадый доктриналар, шул исәптән дин артына яшеренүләрен билгеләп үтте. Дини мәгънәдәге экстремистик оешмаларның эшчәнлеге Россиядәге социаль-икътисадый хәлнең тотрыклылыгын бозуның мөһим факторы булып кала һәм дәүләтнең конфессиональ куркынычсызлыгына һәм территориаль бөтенлегенә җитди куркыныч яный.

Татарстанда республика дәрәҗәсендә дә, муниципаль дәрәҗәдә дә терроризм һәм экстремизмны кисәтүгә зур игътибар бирелә, аерым алганда, рухи һәм әхлакый кыйммәтләрне формалаштыру, яшьләргә гражданлык һәм патриотик тәрбия бирү, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне җайга салу, миграция агымнарын тәртипләү, экстремизм һәм терроризм идеологиясен таратуга каршы тору буенча зур эш үткәрелә.

«Хакимият, җирле үзидарә органнарының һәм хокук саклау структураларының иҗтимагый һәм дини оешмалар һәм берләшмәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм гражданлык җәмгыятенең башка институтлары белән бергәләп эшләүләре мөһим өлеш булып тора», – дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов.



## «СКОЛКОВО»ДАН БҮЛӘК



20 октябрьдә Россия Хөкүмәте рәисе Дмитрий Медведев «Сколково» Мәскәү идарә мәктәбенең Халыкара попечительләр советы утырышын үткәрде, анда ТР Премьер-министры Илдар Халиков та катнашты. Россия Хөкүмәте башлыгы мәктәпкә күптән түгел тугыз яшь тулганлыгын билгеләп үтте: «Бу еллар эчендә мәктәптә 12 мең чамасы кеше укыды. Узган елда гына 2 мең чамасы кеше белем алды, өстәвенә, яртысы – Россия һәм халыкара эшмәкәрлек рейтингының төп исемлегенә керә торган иң зур компания хезмәткәрләре».

Утырыш барышында ТР Премьер-министры Илдар Халиков укытуның уртак программаларын тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасы һәм «Сколково» Мәскәү идарә мәктәбе арасындагы хезмәттәшлек тәҗрибәсе, республиканың дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрен укыту юнәлешләре турында сөйләде.

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов инициативасы буенча 2015 елда «Сколково» Мәскәү идарә мәктәбе, Казан (Идел буе) федераль университетының Югары дәүләт һәм муниципаль идарә мәктәбе белән берлектә, Татарстан Республикасы министрлыклары, ведомстволары һәм муниципаль берәмлекләре җитәкчеләрен «Нәтиҗәле идарә: Стратегия. Эш. Нәтиҗәләр» темасы буенча укытуны тормышка ашыра. Программада 70 кеше (министрлар, ведомство җитәкчеләре, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыклары) катнаша. Укыту барышында тематикасы «2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе» белән бәйле проект эшенә зур игътибар бирелә.

Нәкъ менә шул проектны тормышка ашырганы өчен Татарстан Республикасы Skolkovo Trend Awards премиясенә лаек булды, аны Илдар Халиковка РФ Премьер-министры Дмитрий Медведев тапшырды.

## САНКЦИЯЛӘРГӘ КАРШЫ ЛОКАЛЬЛӘШҮ

Октябрь азагында «Алабуга» МИЗ территориясендә чираттагы проект – нефть-газ тармагы өчен коррозиягә каршы сыек материал җитештерү буенча «3М Волга» заводы эшли башлады. Аны ачу тантанасында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Россиядә 3М компаниясе генераль директоры Роберт Николс катнашты.

«3М Волга» проектын тормышка ашыруның беренче этабында нефть-газ сәнәгате өчен елына 2,5 млн литр күләмендә коррозиягә каршы сыек материал (сыек эпоксид һәм полиуретан ябу материаллары) җитештерү күздә тотыла. Компания Россия базарын үз продукциясе белән тулысынча тәэмин итәргә, шулай ук аларны БДБ илләренә дә озатырга планлаштыра. Тантананы ачып, Рөстәм Миңнеханов әлеге проектның уңышлы тормышка ашырылуын билгеләп үтте. Ул 3М компаниясенең төрле өлкәләрдә тәкъдим ителгәнлеген билгеләп үтте. «Без бүген чит ил товарларын алыштыру турында сөйлибез. Әлеге предприятиедә җитештереләчәк продукция нефтехимиклар, газчылар һәм нефтьчеләр өчен бик кирәк. Мин 3М компаниясе товарына ихтыяҗ күп булыр, дип ышанам». Республика башлыгы фикеренчә, киләчәктә республика белән хезмәттәшлекне башка юнәлешләрдә дә: машина төзелеше, оптик сүслар җитештерү, сәламәтлек саклау һәм башкаларда да дәвам итәргә мөмкин. «3М компаниясе кебек компаниянең үзенең җитештерүен локальләштерү өчен «Алабуга» МИЗ сайлавы безнең өчен зур хөрмәт. Мин киләчәктә дә сезнең барлык башлангычларыгызга булышлык күрсәтербез, дип ышандырам», – диде Татарстан Президенты.



Журналистлар белән аралашып, Рөстәм Миңнеханов «Алабуга» МИЗ территориясендә бүген 45 резидентның уңышлы эшләп килүен, тагын күп кенә проектларның әзерлек этабында булуын билгеләп үтте. «Көнбатыш санкцияләре күпмедер кыенлыклар китереп чыгарды, – дип таныды ул, – әмма шулай булса да, күп кенә Америка һәм Төркия компанияләре Россия базары белән кызыксынуларын саклап калдылар».

«Эшкуарлык бүген Россиягә әзер продукт белән түгел, ә аны биредә җитештерерлек итеп керергә кирәклеген аңлый. Бу арзанрак та, уңайлырак та. Без, үз чиратыбызда, уңай шартлар тудырабыз, ташламалы салым режимы, белгечләр әзерлибез – боларның барысы да Көнбатыш партнерларыбыз биредә үз җитештерүләрен ачсын өчен әйбәт нигез булып тора», – диде Татарстан Президенты.

## БИЗНЕС-ДИПЛОМАТИЯ



Сентябрь азагында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Татарстан Республикасының РФ субъектларындагы һәм чит илдәге вәкилләре белән киңәшмә уздырды.

Республика башлыгы Татарстанның экспортка юнәлгән республика булуын: җитештерелгән продукциянең 50%ының читкә чыгарылуын билгеләп үтте. «Республика партнерлар белән бәйләнешләрнең саклаunion калуы турында кайгырта. Шул ук вакытта яңа базарлар эзләү дәвам итә. Үткән вакыт эчендә ТР вәкилләкләре Кырымда, Севастопольдә, БГӘ һәм Кытайда ачылды. АКШта, Казахстанда, Санкт-Петербургта һәм Ленинград өлкәсендә яңа кадрлар билгеләнде», – диде Татарстан Президенты.

Бүген республика, чит ил партнерлары белән берлектә, күпсанлы уртак проектларны тормышка ашыра. «Төркия, Кытай белән хезмәттәшлекнең зур потенциалы бар», – дип саный Рөстәм Миңнеханов. Санкцияләр булуга карамастан, Татарстан Франция, Чехия һәм Финляндия белән үзара хезмәттәшлеген саклап кала алды. БДБ илләреннән Казахстан һәм Белоруссия белән икътисадый хезмәттәшлек аеруча уңышлы үсә. Татарстан Президенты вәкиллекләрнең барлык юнәлешләр буенча да үз илләре һәм төбәкләре белән хезмәттәшлекнең координацияләү үзәкләре булып торуын, ә сәүдә-икътисадый һәм инвестиция мөнәсәбәтләре хезмәттәшлекнең төп нигезе булып калуын ассызыклады.



## ИНВЕСТОРЛАРНЫ КӨТӘБЕЗ



19 октябрьдә Казанда ТР Инвестиция советы утырышы булды. Республика башлыгы Рөстәм Миңнеханов республикада инвесторларны иң югары дәрәҗәдә кызыктырырлык шартлар тудырырга кирәклегенә басым ясады. Бу хәзер гади булмаган сәяси һәм икътисадый шартларда инвестицияләргә юлның катлауланган вакытында бигрәк тә актуаль. Инвестицияләрне кирәкле күләмдә җәлеп итү икътисадны үстерү мөмкинлеген бирә, яңа хезмәт урыннары булдыруны, яңа салымнар керүне тәэмин итә. Шулай ук барлык мөһим инфраструктураны булдыруга да игътибар итү мөһим – бу потенциаль инвесторларга оператив рәвештә үз бизнесларын үстерергә мөмкинлек бирә. Шулай ук эре инвестиция мәйданчыкларына – «Алабуга» МИЗ, «Мастер» Кама индустриаль паркына гына игътибар итәргә кирәкми, диде Рөстәм Миңнеханов, шулай ук, үсәргә мөмкинлекләре булсын өчен, башкаларына да йөз белән борылырга кирәк.

Төп чыгышны ТР Инвестиция агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина ясады. Ул тулаем алганда инвестиция проектлары базасында гомуми бәясе 764 млрд сумлык 152 проект барлыгын хәбәр итте. Инвестицияләрнең иң зур күләме сәнәгать һәм авыл хуҗалыгына, шулай ук төзелеш, медицина һәм башкаларга туры килә.

Инвестицион климатны алга таба да яхшырту максатында чишелергә тиешле мәсьәләләр арасында докладчы инвестиция проектлары өлкәсендә муниципаль районнардан һәм дәүләт органнарыннан керә торган мәгълүматларның үзара туры килмәвен, документация эшләү өчен чаралар юклыгын, шулай ук инженерлык инфраструктурасы булмавын атады.

## ЯҢА ЧАКЫРЫЛЫШ

Сайлау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнарына 7710 депутат сайланган. 6 мандат вакансиядә калган. Муниципаль сайлауларга катнашу 83,5%ны тәшкил иткән. Партияләр арасында сәяси өстенлекләр түбәндәгечә бүленгән: 6106 депутат («Бердәм Россия»), 312 депутат (КПРФ), 242 депутат («Гадел Россия»), 171 депутат (ЛДПР), 15 («Россия ветераннары партиясе»), 7 («Россия коммунистлары» Коммунистлар партиясе), 5 («Россия патриотлары»), 1 («Ватан партиясе»). 117 депутат иҗтимагый оешмалардан сайланган, 734 – үз-үзләрен тәкъдим иткән депутатлар.

Яңа сайланган депутатлар корпусының 74%ын ирләр тәшкил итә, 26%ы – хатын-кызлар. 5,3%тан әз генә артыгы (412 кеше) – утыз яшьтән яшьрәкләр.





# *Рөстәм* МИҢНЕХАНОВ: *«Без тагын да бердәмрәк, көчлерәккә әвереләдек»*

СЕНТЯБРЬ АХЫРЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЯҢА САЙЛАНГАН ПРЕЗИДЕНТЫ РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ РЕСПУБЛИКА ПАРЛАМЕНТЫНА ТРАДИЦИОН ЕЛЛЫК ЮЛЛАМА БЕЛӘН МӨРӘҖӘГАТЬ ИТТЕ. ИКЕНЧЕ СРОККА ПРЕЗИДЕНТ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ АЛГАН РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЮЛЛАМАСЫ БУЛУЫ ТАТАРСТАН БАШЛЫГЫ ЧЫГЫШЫНЫҢ БЫЕЛГЫ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕН БИЛГЕЛӘДЕ. КҮЗӘТҮЧЕЛӘРНЕҢ КҮБЕСЕ АНЫ ТАТАРСТАН ЛИДЕРЫНЫҢ ЕЛЛЫК ПЕРСПЕКТИВАДАН БИГРӘК, АЛДАГЫ БИШ ЕЛ ӨЧЕН ПРОГРАММ ЧЫГЫШЫ БУЛАРАК БӘЯЛӘДЕЛӘР. ҮЗЕНЕҢ ЧЫГЫШЫНДА РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ РЕСПУБЛИКА ҮСЕШЕНЕҢ МӨҺИМ ӨСТЕНЛЕКЛӘРЕН БИЛГЕЛӘДЕ, ҺӘМ ШУЛАЙ УК ХӘЛ ИТҮДӘ, ХАКИМИЯТНЕҢ ДӘҮЛӘТ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ОРГАННАРЫ БЕЛӘН БЕРРӘТТӘН, ТУЛАЕМ ҖӘМГЫЯТЬНЕҢ УРТАК КӨЧЕ ТАЛӘП ИТЕЛГӘН БУРЫЧЛАРНЫ АТАДЫ. ТР ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ ТУРЫДАН-ТУРЫ ЧЫГЫШЫНЫҢ ТӨП ТЕЗИСЛАРЫ НИНДИ СОҢ?

**– Татарстан бүгенге көндә – Россиянең үзенчәлекле һәм мөстәкыйль төбәге.** Без яңа эш алымнарын һәм заманча технологияләрне, беренче чиратта, нефть чыгару, нефть эшкәртү һәм нефть химиясе, машина төзү тармакларында һәм IT-өлкәдә кулланышка кертү буенча алдынгы урынны биләп торабыз. Татарстанда гаять куәтле производстволар ачылды һәм алар уңышлы эшләп килә. Ил картасында яңа Иннополис шәһәре пәйда булды. Казан Россиянең спорт башкаласы дигән исемгә хаклы рәвештә лаек булуын раслады.

– Тулай төбәк продукты 1,6 трлн сум күләменнән артты; икътисад структурасында мөһим үзгәрешләр булды, сәнәгатьтә эшкәртү производстволары 70% ка җитте, ә чимал сегменты 22% ка кадәр кимеде; нефть эшкәртү күләме ике тапкырга артты. **30 дан артык республика программасын һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру барышында биш ел эчендә меңнән артык социаль-мәдәни объект төзелде.**

**– 2030 елга кадәрге социаль-икътисадый үсеш стратегиясе расланды.** Аның өстенлекле юнәлешләренә кеше капиталын формалаштыру һәм аны ишәйтү, аңа ихтыяҗ тудырырдай, уңышлы эшләвен тәэмин итәрдәй шартлар, уңайлы тирәлек булдыру керә. Стратегияне гамәлгә ашыру Татарстанның яшәү һәм бизнес алып бару өчен уңайлы төбәк буларак позициясен ныгытырга ярдәм



итәчәк, аңа глобаль көндәшлеккә ия территорияләр арасында лаеклы урын алырга мөмкинлек бирәчәк.

– Күптән түгел булып узган Татарстан Президентын һәм җирле үзидарәнең вәкиллекле органнарын турыдан-туры сайлаулар республика халкының без сайлаган курсны хуплавын күрсәтте. **Сәяси партияләрнең, беренче чиратта, парламент сәяси партияләренең муниципаль дәрәҗәдә вәкилләре саны артты. Актив гражданлык позициясендә торучы яңа депутатлар сайланды. Бу муниципалитетлар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итәргә тиеш.** Сайлау алды кампаниясе вакытында яңгыраган барлык тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне системалы анализлап, аларны тормышка ашыруга юнәлтелгән чаралар эшләргә кирәк. Сайлау йомгакларын республикадагы тулаем хакимият системасына бәя бирү һәм башлаган үзгәртеп кору эшләрен дәвам итәргә күрсәтмә буларак кабул итәм.

**– Ирешелгән уңышларыбызның иң кыйммәтлесе – милләтара һәм динара татулыкка һәм тынычлыкка ирешү.** Төрле милләт вәкилләре катнашкан хәрәкәт республикада көннән-көн активлаша һәм ныгый бара. Моңа дәүләт милли сәясәте программалары чараларының тулы күләмдә тормышка ашырылуы булышлык итә. Бөтендөнья татар конгрессы, Рус милли-мәдәни берләшмәсе, Татарстан халыклары ассамблеясе эшчәнлегенә зур игътибар бирелә. Республикада төрле милләт вәкилләре хәрәкәтенең инфраструктурасы да камилләштерелә. Казанда, Чаллы, Тәтеш, Түбән Кама, Менделеевск һәм Нурлатта Халыклар дуслыгы йортлары эшләп килә. Лениногорск һәм Алабуга шәһәрләрендә шундый йортлар ачарга әзерләнәләр. **Болар барысы да муниципаль берәмлекләр башлыкларының этно-мәдәни эш ресурслар базасын формалаштыруга җитди каравына һәм милли иҗтимагый берләшмәләр белән нәтиҗәле хезмәттәшлегенә мисал булып тора.**

**– Хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар һәм территориаль иҗтимагый үзидарәләр хакимият һәм халык арасындагы үзара хезмәттәшлекнең нәтиҗәле механизмы булып тора.** Әлеге институтларны алга таба да үстерергә кирәк. Болар республикада яшәүче һәркемгә балалар өчен уен мәйданчыклары һәм спорт мәйданчыклары төзү, машина кую урыннарын тәртипкә китерү, өй яны территорияләрен электр белән яктырту һәм анда агачлар утырту, төрле чаралар уздыру кебек әһәмиятле мәсьәләләрне чишүгә шәхси өлеш кертү мөмкинлеге тудыра.

**– Бүген 140 тан артык илдәге партнерлар белән үзара файдалы хезмәттәшлек уңышлы рәвештә алып барыла.** Ел башланганда тышкы сәүдә әйләнешенең күләме 22 млрд доллардан, республика икътисадына кертелгән чит ил инвестицияләре күләме 5 ел эчендә 7 млрд АКШ долларыннан артып китте. Татарстанның югары технологияле компанияләренең дөнья базарларына чыгуына һәм бизнесның халыкара икътисадый кооперациядә катнашуына актив рәвештә ярдәм итү зарур.

**Без чит ил компанияләренең Россиягә кергәндә үз идеяләрен һәм технологияләрен, бизнесларын алга этәрү өчен республикабызны старт мәйданчыгы итеп сайлавы белән кызыксынабыз.**

– Якындагы 5 елда икътисадны 1,2 тапкырга үстерү бурычы тора. Инвестицияләр кертүне арттырырга, моның өчен барлык мөмкинлекләребезне дә файдаланырга кирәк. Кама агломерациясе чикләрендә «ИнноКам» инновацияле-җитештерү үзәген булдыру – шул мөмкинлекләрнең берсе. Биредә инфраструктура проектларына, система тәшкил итүче тармакларны модернизацияләүгә, кадрларның белеменә һәм квалификацияләренә аеруча зур игътибар бирү таләп ителә. Быел «ИнноКам»ның үсеш концепциясен илебез Хөкүмәте дәрәҗәсендә расларга кирәк. **Моңа бәйле рәвештә, бүген моношәһәрләр Алгарышлы үсеш территорияләрен булдыру мөмкинлегенә ия, якын араларда Чаллы һәм Яшел Үзән шәһәрләренә шундый статус бирелүенә ирешергә тиешбез. Бу безгә өстәмә ресурслар җәлеп итү һәм бизнесны үстерү өчен уңайлы шартлар булдыру һәм әлеге шәһәрләрнең моноструктур икътисадын диверсификацияләү мөмкинлеге бирәчәк.**

– Республика икътисадының төп үсеш ноктасы булып нефть-газ-химия комплексы кала. **Бүген әлеге тармак компанияләре алдында җитди бурычлар тора. Бу – «Татнефть» һәм кече нефть компанияләре тарафыннан утә узле һәм сланецлы нефть табу, алга таба авыр чыгарыла торган запаслы ятмаларны эшкәртү өлкәсенә инновацияләрне гамәлгә кертү проектларын тормышка ашыру.** Моннан тыш, «Татнефть» компанияләр төркеме каршында шиннар җитештерүнең нәтиҗәлелеген арттыру, ТАНЕКОда нефтьне беренчел эшкәртү буенча яңа ЭЛОУ-АВТ-6 җайланмасын төзү бурычы тора, бу 2018 елга республикада 22 млн тоннага кадәр нефтьне эшкәртү мөмкинлеге бирәчәк. Нефтьнең авыр калдыкларын тирәнтен эшкәртү буенча ике яңа комплексны эксплуатациягә кертү ТАНЕКО һәм ТАИФ-НКда нефтьне эшкәртүне 95 һәм 98%ка җиткерүне тәэмин итәчәк.

**– Республикада яңа бизнес төрләрен булдыруга, үзара бәйләнгән сәнәгать тармакларын үстерүгә шулай ук махсус икътисадый зоналар да булышлык итәргә тиеш.** Алабугада инде 19 производство эшләп килә. Быелның ахырына тагын 3 завод ачылачак. 2020 елга кадәр 90 компания-резидентны җәлеп итү планлаштырыла, алар кертергә тиешле инвестицияләр күләме 243 млрд сум тәшкил итәчәк. Иннополиста беренче 15 резидентның проектлары хупланды инде. Тиз арада әлеге зонаның Лаеш мәйданчыгын да файдалана башларга кирәк.

Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге базасында өченче махсус икътисадый зона формалаштыру буенча да эшне тизләтергә кирәк. Махсус икътисадый зоналарыбыз эшчәнлегенең үсә баручы уртак нәтиҗәлелеге аларны бердәм идарә кластерына берләштерү хисабына мөмкин булачак. Мондый тәҗрибә Россиядә беренче булачак.

– Кече һәм урта бизнесны үстерү – икътисад үсешендә мөһим фактор, ул икътисадтагы үзгәрешләргә аеруча сизгер, шул ук вакытта ул чынбарлыкка да бик тиз яраклаша. **Хөкүмәтебез һәм муниципалитетларыбыз кече бизнесны үстерүгә аеруча зур игътибар бирергә тиеш. Бүген республикабыз халкының дүрттән бере әлеге**

**өлкәдә хезмәт куя. 2020 елга әлеге күрсәткечне 30%ка кадәр җиткерергә кирәк.**

Безнең бурыч – эшкуарлар өчен уңайлы мохит тудыру. Муниципаль сәнәгать мәйданчыкларыбыз зур мөмкинлекләргә ия. Бүгенге көндә 28 районда 45 мәйданчык булдырылды. Шуларның яртысы гына нәтиҗәле эшли дип табылды. **Сәнәгать мәйданчыкларын барлык муниципалитетларда да оештырырга кирәк! Алай гына да түгел, алар конкрет нәтиҗәләргә – резидентлар санын күбәйтүгә һәм яңа эш урыннары булдыруга, сатудан һәм салым түләүдән алынган керемнәрнең артуына китерергә тиеш.**

**– Соңгы 5 ел авыл хуҗалыгы өчен җиңелләрдән булмады. Табигать шартларының начар булуы белән бергә, әлеге тармакның үсешендә авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең кредитларны күп алуы, хуҗалык итүнең кече формалары вәкилләренең кредитларга көче җитмәве җитди йогынты ясады.** Моннан тыш, эшкәртү куәтләре һәм логистика кытлыгы өстәмә кыйммәтнең зур күләмнәрен формалаштырырга мөмкинлек бирми. Тармакка җитди ярдәм күрсәтелүгә дә карамастан, якынча бер үк шартларда эшләүче авыл хуҗалыгы предприятиеләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеге бер-берсеннән нык аерыла.

**– АПК өлкәсендәге төп бурыч – әлеге тармакка кертелгән акчаның нәтиҗә китерүен арттыру.** Тулаем алганда, агросәнәгать комплексында бәя куюда катнашучылар арасында (авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләрдән алып сату челтәрләренә кадәр) җир, мөлкәт һәм институтциячел мөнәсәбәтләрне җайга салырга, чит ил товарларына чикләүләр кертелү шартларында үзебездә җитештерелгән продукцияне эшкәртү, саклау һәм сату мәсьәләләрен эшләргә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүчеләрен һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне файдалануны контрольдә тотуның нәтиҗәле системасын булдырырга кирәк.

– Эре инвестицияле проектларны тормышка ашырганда, республика җитештерү өлкәсендә эшләүчеләргә кытлык проблемасы белән очрашты. Башка төбәкләрдән һәм чит илләрдән югары квалификацияле белгечләрне җәлеп итү белән бергә, **әлеге белгечләрне үзебездә әзерләүгә дәүләт заказы булдыруга аеруча игътибар бирергә кирәк. Урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар киләчәктә эш белән тәэмин ителәчәкләрен тәгаен белсеннәр.**

**– Квалификацияле белгечләр әзерләүдә төп урынны ресурс үзәкләре алып тора.** Шундый биш үзәк инде эшли. Ел ахырына тагын тугызы – «Татнефть» компаниясе белән берлектә – Түбән Кама һәм Лениногорск шәһәрләрендә, «Челтәр компаниясе» белән берлектә – Зәйдә, Горький исемендәге завод һәм «Позис» заводлары белән берлектә – Яшел Үзән шәһәрендә, Казан халыкара аэропорты белән берлектә Лаешта ачылырга тиеш. Әтнә һәм Мамадыш районнарында – аграр юнәлештәге ике ресурс үзәге, Казан шәһәрендә автотранспорт юнәлешендәге ресурс үзәге эшләячәк.

– Тормыш өчен уңайлы мохит тудыруда гражданнарның торак шартларын, торакның сыйфатын яхшырту, аларның торак белән тәэмин ителешен кайгырту мөһим фактор-лар булып тора. Коммерциячел нигездә һәм шәхси йортлар төзүгә кызыксындыруны арттырырга кирәк. «Россия гаиләсе өчен торак» программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2017 елның 1 июленә эконом класслы 1,5 млн кв. метр торак кулланылышка кертелер, дип көтелә. **Төзелештә өлешле катнашу мәсьәләләре муниципаль берәмлекләр башлыклары җаваплылыгы зонасына керә. Әлеге өлкәдә муниципалитетлар ягыннан контроль булмау гражданнарның акчасы югалу куркынычын китереп чыгара.** Рәсми мәгълүматлар буенча гына да республикада аларның саны 557!

**– Бүгенге көндә республика буенча 23 мең кешене авария хәлендәге торак йортлардан күчерү таләп ителә. Әлеге мәсьәлә Казан, Яшел Үзән һәм Чистай шәһәрләрендә аеруча кискен тора. Хөкүмәт һәм муниципалитетлар әлеге программаны үтәүне тәэмин итәргә тиеш.** Авария хәлендәге йортлардан күчерүнең һәр очрагында әлеге мәсьәләгә шәхси якын килү таләп ителә. Кешеләргә аларның иминлеге бу очракта иң мөһиме икәнлеген аңлатырга кирәк.

**– Күп балалы гаиләләргә бүлеп биреләчәк җир кишәрлекләренең инфраструктура ягыннан тәэмин ителүе актуаль бурыч булып кала.** Кайбер районнар әлеге мәсьәләне хәл итүнең механизмнарын уйлап таба. Мисал өчен, Алабугада бу мәсьәлә Торакны ипотека нигезендә кредитка бирү агентлыгы программасы нигезендә хәл ителә. Башкалабыз җитәкчеләренә әлеге уңай тәҗрибәне исәпкә алырга киңәш итәм. Федераль һәм республика акчаларына өметләнеп, көтеп утырырга кирәкми.

– 2014 елда Парклар һәм скверлар елы кысаларында күп эш башкарылды. **Без паркларны һәм скверларны яңарту белән генә чикләнеп калмаячакбыз. Һәр объектның хуҗасы булуы мөһим.** Аларны карап торарга кирәк. Моннан тыш, биредә тормыш гөрләп торыр-







га тиеш. Бу – муниципалитетлар һәм бизнес вәкилләренең, социаль-мәдәни өлкә оешмаларының һәм иҗтимагый берләшмәләрнең уртак җаваплылык зонасы.

**– Татарстан киләчәктә дә халык өчен уңайлы җәмәгать урыннары булдыру буенча эшне су объектларын төзекләндерү рәвешендә дәвам итәчәк.** Республика территориясенең 6% ын сулыклар алып тора, яр буе зоналарының гомуми озынлыгы 30 мең км тәшкил итә. Халыкка әлеге уникаль байлыктан файдалануга һәм аның кулланылышына юл ачу бик мөһим. Киләсе елда без җирдән файдалануны тәртипкә салып кына калмыйча, яр буенда яңа рекреация зоналары эшләячәкбез. Киләчәктә без шәһәр урман-парклары, халыкның кышкы ялын оештыру объектларын төзекләндерү, җәяүлеләр һәм велосипедта йөрү өчен инфраструктура булдыру мәсьәләләрен һәм башка актуаль мәсьәләләрне җентекләп өйрәнүне планлаштырабыз.

**– Югары технологияле медицина үзәкләре төзү һәм клиникаларны заманча җиһазландыру белән беррәттән, авыруларны алдан кисәтү, диспансеризация уздыру, халыкка беренчел медицина ярдәме күрсәтү шәһәрдә дә, авылда да өстенлекле юнәлешләр булып кала.** Гомумтабиблык практикасы челтәрен үстерү, районара үзәкләрне ныклы лаборатория һәм диагностика базасы, квалификацияле белгечләр белән тәэмин итү, кыйммәтле технологияләрне һәм дистанцион консультация уздыруны да кертеп, заманча тикшеренүләр үткәрү буенча эшне дәвам итәргә кирәк.

– Республикада эре халыкара һәм Россия күләмендәге ярышларны уздыру сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга булышлык итә. Төзелгән спорт инфраструктурасының массакүләм спорт үсешенә хезмәт итүе бик мөһим. **Безнең бурыч – системалы рәвештә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүче халык санын арттыру. Шул максаттан чыгып, без яңа спорт объектларын, беренче чиратта, муниципаль районнарда универсаль мәйданчыклар төзүне дәвам итәчәкбез,** ГТО комплексын кертү һәм популярлаштыру эшен активлаштырачакбыз.

– Дәүләт һәм муниципаль идарәнең нәтиҗәлелеген күтәрү һәрвакыттагыча актуаль мәсьәлә булып кала. Беренче чиратта муниципалитетларның гамәлдән чыгарылган норматив-хокукый актлары күп булу борчу тудыра. Бу исә белгечләрнең хокукый белеме түбән дәрәҗәдә булуын күрсәтә. **Хөкүмәткә ел саен муниципаль берәмлекләр өчен хокукый белемле хезмәткәрләр әзерләү буенча максатчан төркемнәр булдыру һәм квалификация күтәрү буенча тиешле курслар оештырырга кирәк.**

– Кайбер министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләренең үз бурычларын республика дәрәҗәсендә эшчәнлекне координацияләүдә генә күрүләре тенденциясе саклана кала. Бу – принципиаль хата. **Дәүләт хакимиятенең башкарма органы функциональлек буенча профильле булган өлкәдә идарә итүнең гомуми җаваплылык үзәге булып тора. Хакимият органнарына системалы бәя биргәндә моны истә тотарга кирәк.** Әлеге бәя һәрбер хезмәткәргә, бер яктан, үз алдында торган бурычларны аңларга һәм аларны ничек хәл итәргә, икенче яктан, республика үсешенә керткән шәхси өлешен күрү мөмкинлеген бирә.














Нияз ӘХМӘДУЛЛИН тексты.
Андрей ТИТОВ фотолары.

# ТАТАРСТАН – үрнәк төбәк (Россия муниципаллары Казанга җыелды)

ӨЧ КӨНГӘ, 12–14 НОЯБРЬЛӘРДӘ, КАЗАН РОССИЯ МУНИЦИПАЛЬ БЕРГӘЛЕГЕ ӨЧЕН ТАРТЫМ ҮЗӘГЕНӘ ӘЙЛӘНДЕ. БУ КӨННӘРДӘ БАШКАЛАБЫЗДА ИЛНЕҢ БАРЛЫК ТӨБӘКЛӘРЕННӘН МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘР СОВЕТЛАРЫ ВӘКИЛЛӘРЕ ГОМУМРОССИЯ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘР КОНГРЕССЫ (ГМБК) ӘГЪЗАЛАРЫНЫҢ ГОМУМИ ҖЫЕЛЫШЫНДА КАТНАШУ ӨЧЕН ҖЫЕЛДЫ. МОНДЫЙ ВӘКИЛЛЕКЛЕ ФОРУМ ҮТКӘРҮ УРЫНЫ ИТЕП ТАТАРСТАН ОЧРАКЛЫ ГЫНА САЙЛАНМАГАН ИДЕ. РЕСПУБЛИКАНЫҢ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ СИСТЕМАСЫН ҮСТЕРҮДӘГЕ УҢАЙ ТӘҖРИБӘСЕ РОССИЯДӘ ЯХШЫ МӘГЪЛҮМ, Ә ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘР СОВЕТЫ ҮЗЕНЕҢ ДИСТӘ ЕЛЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕ ДӘВЕРЕНДӘ РЕСПУБЛИКА ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ҺӘМ КОНСТРУКТИВ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТҮДӘ ЗУР ТӘҖРИБӘ ТУПЛАГАН.

12 ноябрьдә Казанда ГМБК Президиумы утырышы булды, анда Конгрессның хәзерге һәм киләчәктәге эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр каралды. 13 ноябрьдә исә ГМБК әгъзаларының Гомуми җыелышы үткәрелде. «Корстон» кунакханә-сәүдә-күңел ачу комплексында РФ субъектлары муниципаль берәмлекләре төбәк Советларының 250ләп вәкиле, РФ Дәүләт Думасы депутатлары, федераль министрлык һәм ведомстволарның, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле аппаратының җаваплы хезмәткәрләре, ТР муниципаль берәмлекләре башлыклары, ТР министрлык һәм ведомстволары җитәкчеләре җыелган иде.

Форумның пленар утырышында Гомумроссия муниципаль берәмлекләр конгрессы президенты, РФ Дәүләт Думасының Федератив корылыш һәм җирле үзидарә мәсьәләләре комитеты рәисе Виктор Кидяев, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Муниципаль берәмлекләр Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров катнашты.

Көн тәртибенә кертелгән актуаль мәсьәләләр арасында ГМБК Уставына кертелгән үзгәрешләр (конгресс структурасын үзгәртеп коруга, финанслау механизмнарын корректировкалауга һ.б. бәйле), яңа әгъзалар кабул итү, Бөтенроссия җирле үзидарә Советы белән хезмәттәшлек турында килешүгә имзалау, Россия муниципаль берәмлекләренең хәзерге үсешенең кайбер проблемалары, ГМБК эшенең перспектив юнәлешләре бар иде.

Форумда катнашучыларны ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов сәламләде. Ул, республиканың уңышлы үсешенең төп









сере – Татарстанда хакимиятне беркайчан да федераль, республика һәм муниципальгә бүлмәүдә, дип билгеләп үтте. Хакимиятнең барлык тармак һәм дәрәҗәләре бер бурычны – гражданнарның яшәү шартларын яхшыртуны күздә тотып эшли. Президент әйтүенчә, Татарстанда утыздан артык социаль-икътисадый үсеш программасы гамәлдә, алар территорияләр үсешенең шактый проблемаларын хәл итәргә мөмкинлек бирә. Болар барысы да – муниципаль һәм дәүләт хакимияте органнарының бергә һәм килешеп эшләве нәтиҗәсе.

Рөстәм Миңнеханов агымдагы елның республика муниципалитетлары үсеше өчен бик мөһим булуын да искәртте. Сентябрьдә муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына депутатлар сайланды (барлыгы 7 634 депутат), шулар арасыннан муниципалитет башлыклары сайланды. Сайлауда халыкның күп катнашуы республика гражданнарының муниципаль хакимияткә ышанычы зур булуын дәлилли.

«Халыкның тулаем хакимият органнары системасына мөнәсәбәте җирле үзидарәне бәяләүдән чыгып формалаша. Шунлыктан җирле үзидарәне ныгыту, аның абруен һәм нәтиҗәлелеген күтәрү гомумдәүләт бурычына әйләнә», – дип басым ясады республика җитәкчесе һәм ГМБК ның Казандагы Гомуми җыелышында кабул ителгән карарлар Россиядә җирле үзидарәнең алга таба да камилләшүенә булышыр, дигән өметен белдерде. Аның әйтүенчә, җыелышта тикшерелгән мәсьәләләр, аерым алганда, җирле үзидарәнең хокукый нигезләрен үстерү, муниципалитетларның финанс тәэминаты һәм бюджетара көйләнүе, торак фонды белән идарә итү һ.б. һәрвакыт актуаль һәм кискен. Аларны хәл итү юлларын табу зарур. Президент шулай ук ТР Муниципаль берәмлекләре Советының төбәкара хезмәттәшлекне үстерү буенча мөһим эшчәнлеген дә билгеләп үтте, аның кысаларында Совет Татарстанны лаеклы тәкъдим итә.

ТР Дәүләт Советы спикеры Фәрит Мөхәммәтшин муниципалларны Җирле үзидарә турында Европа хартиясе кабул ителүенең 30 еллыгы һәм Хартиягә Россия Федерациясе кушылуның 2016 елда булачак 20 еллыгы белән тәбрикләде. Ул республикада җирле үзидарәне үстерү буенча алып барылган эш, Татарстанда хакимиятнең барлык баскычларының уңышлы хезмәттәшлеге уңай тәҗрибәсе турында мәгълүмат бирде. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, халыкның үз территорияләрен үстерү процессында актив катнашуы бик мөһим, үзара салым практикасы моның ачык мисалы булып тора һәм бүгенге күп кенә кискен проблемаларны хәл итәргә мөмкинлек бирә. Республика парламенты рәисе фикеренчә, мондый тәҗрибәне бөтен илгә тарату максатка ярашлы. Ул шулай ук Гомумроссия конгрессының Россия субъектлары муниципаль берәмлекләренең үзара хезмәттәшлеген көйләүдәге мөһим ролен һәм Конгрессның Татарстанда җирле үзидарәне үстерү буенча чараларны хуплавын билгеләп үтте.

Гомумроссия муниципаль берәмлекләр конгрессы президенты, РФ Дәүләт Думасының Федератив корылыш һәм җирле үзидарә мәсьәләләре комитеты рәисе Виктор Кидяев үз докладында Россиядә җирле үзидарә үстерүнең актуаль проблемаларын, ГМБК эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләрен җентекләп яктыртты. Ул басым ясаганча, муниципалитетларның дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлеге процессында төбәк муниципаль берәмлекләр советлары (МБС) ролен ныгыту ГМБКның иң төп бурычларыннан берсенә әйләнергә тиеш. Виктор Кидяев ил федераль округларында муниципаль берәмлекләр Советларының даими эшләүче Координация киңәшмәләрен, ГМБК химаясе астында Җирле үзидарә территориаль иҗтимагый советлары ассоциациясен төзергә, гомумроссия муниципаль конкурсларын яңадан торгызырга тәкъдим итте. Ул шулай ук ГМБКның ШОС, БРИКС, муниципалларны берләштерә торган халыкара ассоциацияләр кысаларында халыкара хезмәттәшлекне үстерү зарурлыгы турында фикерен җиткерде. ГМБК президенты Россиядә җирле үзидарәне үстерүдәге кайбер аеруча мөһим проблемаларны санап китте (алар арасында – вәкаләтләрнең җитәрлек булмавы, финанслар җитешмәү) һәм аларны әкренләп хәл итү механизмнарын тәкъдим итте. Ул күп кенә проблемаларны хәл итүдә Татарстанның уңай тәҗрибәсен билгеләп үтте һәм республикадагы муниципаль хакимият эшчәнлегенең яхшы тәҗрибәсен башкалар белән дә уртаклашырга кирәк, дигән фикерен белдерде. Комитет рәисе шулай ук төбәк муниципаль берәмлекләре советларына җирле үзидарәгә кагылышлы сораулар буенча закон чыгару хокукы бирергә тәкъдим итте һәм шуларга нигезләнгән федераль закон кабул итәргә өндәде. Төбәк советларының хәзерге эшчәнлеген кыенлаштырган финанс проблемаларын хәл итү максатыннан Виктор Кидяев советларга грантлар системасы булдыру зарур, дип саный, шулай ук МБС статусын социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешма, дип билгеләргә тәкъдим итә. ГМБК президенты конгрессның оешма структурасын үзгәртү һәм ГМБК Уставына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәрен дә җиткерде.





Бөтенроссия муниципаль форумында катнашучылар каршында ТР Муниципаль берәмлекләр Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров та чыгыш ясады, ул аларга Татарстанда җирле үзидарә системасын үстерү тәҗрибәсе, Совет эшчәнлеге турында тәфсилләп сөйләде һәм кайбер тәкъдимнәрен дә җиткерде.

Минсәгыйть Шакиров басым ясаганча, республикада җирле үзидарә торгызылу дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының тыгыз хезмәттәшлегендә барган. «Дәүләт һәм муниципаль хакимиятләрне капма-каршы куярга маташу уңышсыз. Әйе, безнең вәкаләтләребез, эш формабыз, норматив базабыз төрле. Әмма безне әһәмиятлерәк нәрсә берләштерә: ул да булса – халык мәнфәгатьләре. Барлык хакимият органнарын – федераль, төбәк, җирле – бер үк сайлаучылар сайлый һәм хакимият хокукы бирә. һәм аларга безнең үзара мөнәсәбәтләребез түгел, бәлки төгәл, килешеп эшләвебез мөһим», – дип искәртте рәис.

ТР МБС рәисе дәүләт хакимияте органнары һәм Советның бергәләшеп эшләү механизмнары турында сөйләде, аның хокукый нигезләре «Татарстан Республикасы дәүләт хакимия-



те органнарының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр Советы белән үзара хезмәттәшлеге турында» республика законына салынган. Муниципаллар мәнфәгатен кайгырткан барлык норматив актларның өйрәнү һәм тәкъдимнәр эшләү өчен башта Советка җибәрелүе хакында мәгълүматны да ГМБК әгъзалары игътибар белән тыңлады. Республика муниципаль бергәлегенең эшчәнлеге тагын бер мөһим документ нигезендә төзелә. Бу – Дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының уртак чаралар планы, ул ТР МБС съезды нәтиҗәләре буенча кабул ителә һәм Совет рәисе, ТР Премьер-министры имзалары белән беркетелә, ТР Президенты тарафыннан раслана. Шул рәвешле План республиканың барлык министрлык һәм ведомстволары, республикадагы федераль структуралар, җирле хакимият органнары өчен мәҗбүригә әйләнә.

Минсәгыйть Шакиров республиканың социаль-икътисадый үсешенә кагылышлы Президент программаларын (алар ТРның барлык муниципаль берәмлекләрен эченә ала), үзара салым, иң яхшы авыл җирлекләренә грант ярдәме күрсәтү программаларын гамәлгә кертүнең әһәмиятенә басым ясады. Мәсәлән, 2014 елда муниципаль берәмлекләр бюджетларына үзара салымнан 80 миллион сумнан артык акча кергән, шуларга республиканың 320 миллион сумнан артыграк акчасы кушылган. Ә быел беренче яртыеллыкта инде 100 миллион сум салым җыелган, республика бюджетыннан 400 миллион сум кушылган. ТР МБС рәисе әйтүенчә, халыкның референдумнар аша җирлекләр белән турыдан-туры идарәгә җәлеп ителүе бик мөһим.

Минсәгыйть Шакиров республикада территориаль иҗтимагый үзидарәләрен (ТИҮ) үстерү тәҗрибәсенә дә тукталды. Бүген Татарстанда 300 дән артык территориаль иҗтимагый үзидарәсе төзелгән. Министрлар Кабинеты карары нигезендә ТИҮ җитәкчеләре республиканың муниципалитетларга бирелә торган субсидияләреннән компенсация түләүләре ала. Быел республикада беренче тапкыр «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый идарәсе» бәйгесе үткәрелде. Җиңүчеләр һәм призерлар территорияләр проблемаларын хәл итүгә гомуми бәясе 50 миллион сумлык 120 грант алды.

Республика муниципаль бергәлеге җитәкчесе муниципалитетара хезмәттәшлек турында да сөйләде, ГМБКны әлеге эшне оештыруда активрак катнашырга өндәде. Ул шулай ук ил субъектларындагы Советларда тупланган уңай тәҗрибәләр турында мәгълүматның бердәм банкын төзергә, ГМБК еллык җыелышының дәрәҗәсен һәм әһәмиятен күтәрергә дә тәкъдим итте, бу исә аның эшендә ил җитәкчелеге катнашканда мөмкин хәл санала. Минсәгыйть Шакиров ГМБК эшчәнлеген финанслауга бәйле сорауларны да игътибарсыз калдырмады. Аның фикеренчә, РФ Дәүләт Думасына мөрәҗәгать әзерләү зарур – «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының Гомумроссия муниципаль берәмлекләр конгрессы белән үзара хезмәттәшлеге турында» федераль закон кабул ителсен, анда дәүләт бюджетыннан да финанслау күздә тотылсын. Мәсәлән, Иҗтимагый палата финансланган кебек, дип басым ясады ТР МБС рәисе. Шундый ук законнарны федерация субъектларында да кабул итү зарур.

Форум барышында ГМБК әгъзалары да, конгресс кунаклары да чыгыш ясады. Алар җирле үзидарә органнарының ТКХны реформалауда катнашуына, тузган һәм авария хәлендәге торакны карап тотуга, муниципаль берәмлекләр һәм аларның ассоциацияләренең үзара килешеп эшләвенә, муниципаль дәрәҗәгә тапшырылган вәкаләтләрне финанслауның җитәрлек булмавына, җирле бюджетларның балансларына бәйле мәсьәләләр һ.б. хакында сөйләде. ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның республикада муниципаль милиция төзү турында инициативасы залда хуплау тапты, ул илнең муниципаль берәмлекләрендә хокук тәртипләрен ныгытуга булышырга тиеш.

Форум эше нәтиҗәләре буенча Карелия, Кырым, Севастополь муниципаль берәмлекләре Советлары, шулай ук Себер






һәм Ерак Көнчыгыш шәһәрләре ассоциациясе ГМБКга яңа әгъза итеп алынды. Соңгысының җитәкчесе, Хабаровск шәһәре мэры Александр Соколов ГМБКның вице-президенты итеп сайланды.

ГМБК җитәкчелеге шулай ук кайбер муниципалларга бүләкләр тапшырды. ТР МБС рәисе Минсәгыйть Шакиров һәм Советның башкарма секретаре Александр Барышев «РФ законнары үсешенә керткән мөһим өлеш өчен» РФ Дәүләт Думасының мактау грамотасына лаек булдылар.

Гомуми җыелыш Уставка һәм ГМБКның яңа оешма структурасына төзәтмәләрне раслады: алты палата (РФ субъектлары үзәкләре булган шәһәрләр; шәһәр округлары; муниципаль районнар; шәһәр җирлекләре; авыл җирлекләре; шәһәр эчендәге муниципаль берәмлекләр палаталары) һәм алты комитет (закон чыгару, хокукый мәсьәләләр һәм муниципаль корылыш; бюджет-салым мәсьәләләре һәм социаль-икътисадый үсеш; мәгариф, сәламәтлек саклау һәм социаль мәсьәләләр; ТКХ мәсьәләләре; җирле дәрәҗәдә гражданлык җәмгыятен үстерү мәсьәләләре, иҗтимагый элемтәләр һәм яшәү мохите иминлеге; халыкара муниципаль хезмәттәшлек комитетлары) төзелде. ГМБК әгъзалары шулай ук комитетлар һәм палаталар җитәкчеләрен дә сайлады.

Форум ябылганда ГМБК президенты Виктор Кидяев республика җитәкчелегенә, ТР Президенты Рөстәм Миңнехановка, ТР МБС рәисе Минсәгыйть Шакировка эшне яхшы оештырулары һәм Татарстан тәҗрибәсе белән танышырга мөмкинлек биргәннәре өчен рәхмәтен җиткерде. Конгрессның гомуми җыелышларын төбәкләрдә үткәрү практикасын дәвам итәргә кирәк, дип искәртте. ГМБК әгъзалары чираттагы утырыш Санкт-Петербургта булыр, дип килештеләр.



# *Виктор КИДЯЕВ: «Бурыч – кешеләрнең тормышын уңайлырак, хакимиятне якынрак итү»*

АГЫМДАГЫ ЕЛНЫҢ НОЯБРЬ УРТАСЫНДА КАЗАНДА ГОМУМРОССИЯ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘР КОНГРЕССЫНЫҢ (ГМБК) КҮЧМӘ УТЫРЫШЫ БУЛЫП УЗДЫ. АНДА РОССИЯДӘ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ СИСТЕМАСЫН ҮСТЕРҮНЕҢ КӨНҮЗӘК ПРОБЛЕМАЛАРЫ, ШУЛАЙ УК КОНГРЕСС ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ АГЫМДАГЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ ХАКЫНДА ФИКЕР АЛЫШТЫЛАР. ӘЛЕГЕ УТЫРЫШКА БЕР КӨН КАЛА, РФ ФҖ ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫНЫҢ ФЕДЕРАТИВ КОРЫЛЫШ ҺӘМ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ КОМИТЕТЫ РӘИСЕ, ГМБК ПРЕЗИДЕНТЫ ВИКТОР КИДЯЕВ БЕЛӘН ОЧРАШЫП, ИЛЕБЕЗДӘ МУНИЦИПАЛИТЕТЛАРНЫ ҮСТЕРҮ, РОССИЯ МУНИЦИПАЛЬ ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕГЕ АЛДЫНДА ТОРГАН БУРЫЧЛАР ТУРЫНДА ӘҢГӘМӘ КОРДЫК.

**– Сез ГМБКн җитәкләргә быелның апрелендә керештегез. Конгресс эшчәнлеге тәҗрибәсенә нинди бәя бирәсез? Алга таба ГМБК алдында нинди мөһим бурычлар тора?**

– Гомумроссия Конгрессы, яки кыскартып әйткәндә ГМБК, илебезнең барлык муниципаль берәмлекләрен диярлек үз эченә алган берләшмә. Ул үзара киңәшләшү органы, төп бурычлары Россиядә җирле үзидарәне камилләштерү, урын-




нарда тормыш-көнкүрешне уңайлырак итү, хакимиятне халыкка якынайтудан гыйбарәт. Конгресс оешканнан алып ун елга якын вакыт эчендә аның мәйданчыкларында муниципалитетлар эшчәнлеген катлауландыручы, аның үсешенә комачаулаучы күпсанлы проблемаларны хәл итү насыйп булды. Арттырып әйтүем түгел, җирле үзидарә турындагы федераль канунны эшләү һәм аны гамәлгә ашыру билгеле бер дәрәҗәдә ГМБК әгъзаларының казанышы.

Киләчәк турында сүз алып барганда, алдыбызга берничә стратегик бурыч куябыз. Шуларның беренчесе: Конгресс составына керүче Муниципаль берәмлекләр Советларына методик, оештыру, консультация ярдәме күрсәтү. Төбәкләрнең үсеше күбесенчә урыннардагы Советларның көченә бәйле. Икенче бурыч: Конгресснның һәм аның әгъзаларының дәүләт хакимиятенең федераль һәм төбәк органнары белән үзара хезмәттәшлеген ныгыту, муниципаль проблемаларны төбәк һәм федераль дәрәҗәләрдә күтәреп чыгу. Өченчесе: бүгенге көн алдыбызга куйган сорауларга җавапларны бергәләп эзләү, җирле үзидарә алгарышын тәэмин итәрлек кануннар чыгару һәм норматив чишелешләр табу.

Муниципалитетларның финанс ягыннан тотрыклылыгын тәэмин итү, муниципаль кадрлар әзерләү, коррупциягә каршы тору, гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү системасын камилләштерү, ТКХ системасында катнашучыларның үзара мөнәсәбәтләрен көйләү – бүгенге көн үзәгендәге мәсьәләләр. Гадирәк әйткәндә, урыннарда көн саен туып торган проблемалар, аларны хәл итү өчен, хакимият органнарының барысының да тырышлыгын берләштерү.

**– Конгресс әгъзалары – федерация субъектларындагы муниципаль җәмәгатьчелек мәнфәгатьләрен чагылдыручы оешмалар арасында үзара хезмәттәшлек ни рәвешле гамәлгә ашырыла? Әлеге оешмаларның төбәкләрдә муниципаль хакимият үсешенә керткән өлешен, аларның ГМБК кысаларындагы активлыгын ничек бәялисез?**

– Конгресс – ул федераль мәйданчык, аңа барлык муниципаль берәмлекләр (шәһәрләр, авыллар, районнар) үз проблемалары, тәкъдимнәре белән аяк баса ала. Конгресс эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге, һичшиксез, Муниципаль берәмлекләр Советларын, муниципальара һәм төбәкара берләшмәләрне һәм ассоциацияләрне дә кертеп, аның бөтен әгъзаларының үзара хезмәттәшлеге сыйфатына, шулай ук проблемаларны хәл итүгә төбәк һәм дәүләт идарәсе системасында катнашучыларның барысының да ни дәрәҗәдә җәлеп ителүенә бәйле.

Бүгенге көндә федераль округларда Муниципаль берәм-

**Муниципалитетларның финанс ягыннан тотрыклылыгын тәэмин итү, муниципаль кадрлар әзерләү, коррупциягә каршы тору, гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү системасын камилләштерү, ТКХ системасында катнашучыларның үзара мөнәсәбәтләрен көйләү – бүгенге көн үзәгендәге мәсьәләләр. Гадирәк әйткәндә, урыннарда көн саен туып торган проблемалар, аларны хәл итү өчен хакимият органнарының барысының да тырышлыгын берләштерү.**

лекләр Советларының, җирле үзидарә һәм дәүләт хакимияте органнарының киңәшмәләрен оештырып һәм уздырып, әлеге хезмәттәшлекне яңа дәрәҗәгә күтәрәбез. Мондый утырышларның беренчесе (Үзәк федераль округ кысаларында) 2015 елның 3 сентябрендә РФ Президентының вәкаләтле вәкиле химаясендә Тамбов шәһәрендә уздырылды. Җыелып килгән мәсьәләләр буенча ачыктан-ачык фикер алышулар нәтиҗәсендә берничә карар кабул ителде. Әйтик, без ГМБК һәм төбәк Муниципаль берәмлекләр Советларының дәүләт хакимиятенең федераль һәм төбәк органнары белән, РФ Президентының ҮФОндагы вәкаләтле вәкиле каршындагы Советның җирле үзидарәне үстерү буенча эшче төркеме белән хезмәттәшлеген киңәйтү һәм камилләштерү хакында үзара килештек. Советлар ихтыяҗ туган очракларда Конгресснның РФ субъектлары җитәкчеләренә Муниципаль берәмлекләр Советларына кирәкле (беренче чиратта, оештыру-методик яктан) ярдәмне күрсәтүләрен һәм РФ субъектларының дәүләт хакимияте органнарында муниципаль берәмлекләрнең мәнфәгатьләрен яклау механизмнарын эшләүләрен сорап мөрәҗәгать итүен үтенделәр. Муниципаль кадрларны әзерләү һәм белемнәрен күтәрү институтын камилләштерү буенча тиешле чаралар күрү турында, РФнең ҮФОна кергән субъектларындагы Муниципаль берәмлекләр Советларының башкарма органнары җитәкчеләре катнашлыгында белем бирү һәм тематик семинарлар уздыруны Конгресс эшчәнлеге практикасына кертү хакында фикер алыштылар. Тамбовтагы киңәшмә киләчәккә планнар төзү

өчен бик файдалы чара булды. Мондый киңәшмәләрне быелгы елның азагына чаклы һәм 2016 елның беренче яртыеллыгында федераль округларның һәркайсында уздырачакбыз.
Конгресс әгъзаларының 2015 елның 12–14 ноябрендә Казанда уздырылучы гомуми җыелышы, үзара мөнәсәбәтләр кору системасы күзлегеннән караганда, бик мөһим вакыйга булыр, дип саныйм (әңгәмә әлеге чарага бер көн кала корылды. – Ред.). Бирелә киләчәктәге эшебезнең юнәлешен берничә елга алдан билгеләүче карарлар кабул ителәчәк. Аерып әйткәндә, сүз ГМБКның яңа структурасын кабул итү турында бара. Заманча яңалыкларның берсе – муниципаль берәмлекләр төре буенча палаталар оештыру. Шунысы ачык билгеле: палаталар эчендәге эшчәнлек игътибарны аерым бер төрдәге муниципаль берәмлекләргә хас проблемаларга юнәлдерергә мөмкинлек тудырачак. Шулай ук муниципаль берәмлекләр эшчәнлегенең юнәлешләре буенча комитетлар төзү дә күздә тотыла. Комитет составына керүче экспертлар килеп туган мәсьәләләрне хәл итүнең теге яки бу тармакка караган муниципаль структуралар өчен кулай юлларын табарга ярдәм итәр. Конгрессның яңа структур төзелеше нәрсә бирер? Ул, проблемаларның асылына җентекләп төшенеп, адреслы хәл итү мөмкинлеген тудырачак. Аның ничек эшләячәген аерым бер мисалда карап үтик. Әйтик, бер Муниципаль берәмлек Советы авыл җирлекләрендә торакны капиталь төзекләндерүнең альтернатив чыганагын эзләү тәкъдиме белән чыга. Әлеге мәсьәләне ТКХ юнәлешендә эшләүче комитет экспертлары өйрәнә. Аннан соң, комитет мәйданчыгындагы тәкъдимнәр авыл җирлекләре палатасына керә, һәм алар шундый типтагы муниципаль берәмлекләрнең үзенчәлеген истә тотып карала. Шул рәвешчә, мәсьәләне хәл итүнең нәтиҗәле һәм тормышка яраклы юлы барлыкка килә, ә аны инде канун чыгару дәрәҗәсендә карарга була.
Аңлашыла ки, әлеге система төбәкләрдәге Муниципаль берәмлекләр Советлар турыдан-туры катнашса, алар активлык күрсәтсә генә эшләячәк. Советларда нигездә җаваплы һәм битараф булмаган, җирле үзидарә проблемаларын яхшы аңлаган, аның мәнфәгатьләрен хакимиятнең барлык дәрәҗәләрендә, шул исәптән безнең Конгресс аша кайгырткан кешеләр эшли дисәм, ялган булмастыр. Шундый актив хезмәт уңай нәтиҗәләргә китерә. Муниципалитетлар һәм анда яшәүче кешеләр иртәгәсе көнгә ышаныч белән карасын өчен, замана проблемаларын һәм тышкы вазгыять куйган уңайсызлыкларны чишүдә акыллы, икътисадый яктан нигезле карарлар кабул итү сорала.

**– Муниципаль идарә органнарында шактый озак вакыт эшләү дәверендә сезгә, һичшиксез, ҖҮИ системасын үстерүгә бәйле авырлыкларга юлыгырга туры килгәндер. Илебездәге муниципаль хакимият үсешен тоткарлаучы проблемаларның кайсылары хәл ителде?**

– Җирле үзидарә проблемаларын хәл итү юнәлешендә



**Минемчә, җирле үзидарә эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген тәэмин итәрлек закон базасы формалашкан, әмма бу барлык иске проблемалар хәл ителде, дигән сүз түгел. Җирле үзидарә органнары вәкаләтләре өлкәсен тәртипкә салырга кирәк. Ә иң мөһиме: алдыбызда җирле хакимиятне тотрыклы финанслар белән тәэмин итү мәсьәләсе тора.**



РФ Президенты В.Путинның Бөтенроссия муниципаль берәмлекләре съездында катнашучылар белән очрашуы (2013 елның ноябре).

егерме елдан артыграк эшлим, муниципалитет башлыгы буларак та тәҗрибәм бар, тугыз ел элек РФ Дәүләт Думасы депутаты булып сайланганга күрә, канун чыгару дәрәҗәсендә дә шөгыльләнергә туры килә. Бүгенге көндә РФ Дәүләт Думасының Федератив корылыш һәм җирле үзидарә мәсьәләләре комитеты рәисе һәм ГМБК президенты буларак, үз тәҗрибәмә дә, хезмәттәшләремнекенә дә таянам. Муниципаль бергәлек алдында торган бөтен бурычларны гомумиләштерсәк, аларны икегә: вәкаләтләргә һәм аларны финанслау проблемасына бүлеп карап була. Соңгы елларда нәкъ менә шуларны хәл итү белән шөгыльләндек.
136-ФЗ – бинһая зур хезмәтебезнең төп нәтиҗәсе. Ул канун федерация субъектларының җирле үзидарәне көйләү процессындагы хокукларын киңәйтте. Күп кенә мәсьәләләрне хәл итү авыл җирлекләреннән алынып, районныкына тапшырылды. Шул ук вакытта, федерация субъектлары аягында нык басып торган авыллар өчен җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр исемлеген киңәйтергә дә мөмкин. Әлеге вәкаләтләрне үтәүгә каралган акчалары белән бергә, әлбәттә.
Комитетыбыз вәкаләтләр темасы белән даими шөгыльләнә. Әйтик, былтыр РФ Президенты без кабул иткән канунны имзалады, шуның нигезендә, хуҗасыз хайваннарны аулау һәм асрау вәкаләте федерация субъектларына беркетелә. Бер үк вакытта муниципаль берәмлекләр үз биләмәләрендәге хуҗасыз хайваннарны аулау һәм асрау вәкаләтенә бәйле мәсьәләләрне хәл итү хокукына ия булды.
Вәкаләтләрне яңадан бүлү мәсьәләсен киләчәктә дә игътибар белән күзәтеп барырга кирәк. Барлык муниципаль бергәлек эшчәнлегенең бик мөһим юнәлеше ул.
Тагын бер юнәлеш. Белгәнегезчә, әүвәле 131-ФЗ Канун муниципаль берәмлек башлыгын сайлауның өч төрле вариантын күздә тоткан иде. Безнең тарафтан кабул ителгән 8-ФЗ үз көченә кергәч, ул элеккеге барлык вариантларны гына саклап калмады, ә җирле хакимият белән идарә итәчәк муниципаль берәмлек башлыгын сайлауның тагын ике алымын: депутатлар арасыннан сайлап куюны яисә аны махсус бәйге узган кандидатлар арасыннан сайлауны күздә тота. Әлеге канун урыннарда сайлап куелган хакимиятнең дәрәҗәсен күтәрүгә һәм ике хакимлелектән котылуга йөз тоткан курсыбызның эзлекле дәвамы ул.

**– Җирле үзидарә турындагы федераль кануниятнең гадәттән тыш «хәрәкәтчән» булуына мөнәсәбәтегез ничек? 131-ФЗ гамәлгә ашырыла башлаганнан бирле, аңа йөзләгән төзәтмә кертелде. Муниципаль хокук кырын берөзлексез төзәтеп торуның мантыйгын билгеләүче бердәм юнәлешләр бармы?**

– Законнар базасы белән даими эш алып бару, гамәлдәге канунннарга төзәтмәләр кертү һәм яңаларын кабул итү – тормыш таләбе һәм аның аерылгысыз өлеше. Барлык төзәтмәләр практикага, урыннардагы тәҗрибәгә нигезләнә, идарә итү системасын камилләштерүгә, аны сыгылмалырак, заман таләбенә яраклырак итүгә хезмәт итәргә бурычлы.
Сүз дә юк, һәр төзәтмәнең билгеле бер мантыйгы бар. Шәхсән үзем муниципаль идарә системасын төзүне ике этапка бүләр идем. XX гасырның 80нче елларыннан башлап, 2003 елгача дәвам иткән беренче чорда җирле үзидарәләр үсеше каршылыклы булды. Ул чакта төбәк хакимиятенең роле шактый югары иде. Икенче этабы 2003 елда 131-ФЗ кабул ителүгә бәйле, ә ул хакимиятнең төрле дәрәҗәдәгеләре арасында вәкаләтләрне чикләүгә йөз тоткан административ реформаның бер өлешенә әверелде. Ун ел узды. Төбәк хакимиятенең үзгәрүен, аның өлгергәнлеккә һәм җаваплылыкка ирешүен күрәбез. Формаларның күп вариантлы булуы һәм күптөрлелеге файдасына бердәм оештыру калыбыннан читләшәбез. Шунысын да өстәп әйтә алам: минемчә, җирле үзидарә эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген тәэмин итәрлек закон базасы формалашкан, әмма бу барлык иске проблемалар хәл ителде, дигән сүз түгел. Җирле үзидарә органнары вәкаләтләре өлкәсен тәртипкә салырга кирәк. Ә иң мөһиме: алдыбызда җирле хакимиятне тотрыклы финанслар белән тәэмин итү мәсьәләсе тора.

**– Дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының үзара хезмәттәшлеге ни дәрәҗәдә уңышлы үсеш кичерә? Илнең төрле төбәкләре үзенчәлекле тәҗрибәгә ия, уңай мисаллар да бар, әмма каршылыклар да җитәрлек. Төбәкләр үсеше мәнфәгатьләрен кайгырту йөзеннән, әлеге хезмәттәшлекне нинди механизмнар тәэмин итәргә тиеш?**

– Дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының үзара тәэсире, нәтиҗәле диалог һәм үзара хезмәттәшлеге –





төп мәсъәләләр, РФ Дәүләт Думасының Федератив корылыш һәм җирле үзидарә мәсьәләләре комитеты шуларны хәл итү белән шөгыльләнә. Әлеге юнәлештә күп нәрсә эшләнде.

Киләчәкне күздә тотып планлаштыру – моның ачык мисалы. Әгәр ул эш хакимиятнең федераль һәм төбәк органнары арасында гына алып барылса, бүгенге көндә комитетның һәм Гомумроссия конгрессының бергәләп хезмәт куюы нәтиҗәсендә, ул муниципаль дәрәҗәне дә үз эченә ала, ягъни урыннардагы планнарны һәм тәҗрибәне дә исәпкә ала. Әлеге закон илебезнең, төбәкләрнең һәм муниципалитетларның, эреләренең генә түгел, уртача зурлыктагыларының һәм кечкенәләренең, социаль-икътисадый үсеше өчен яңа шартлар тудырыр, дип ышанам. Хәзер түбәннән алып югарыга чаклы бердәм үсеш стратегиясе системасын барлыкка китерү мөмкин булачак.

Муниципалитет стратегиянең буш формальлек кенә булмавын аңларга тиеш. Ул мәсьәләләрне хәл итүнең тормышчан чарасы, аеруча мөмкинлекләр җитәрлек булмаган, катлаулы социаль-икътисадый шартларда.

Муниципаль вакансияләр турындагы мәгълүматны Интернет челтәрендә урнаштыру турындагы без кабул иткән канун, гомумән алганда, җирле үзидарәне, шул исәптән муниципаль хезмәтне ныгытуга ярдәм итәргә тиеш. Бу безнең уртак казаныш. Беренче вакытларда федераль һәм төбәк вакансияләрен генә Интернетта урнаштыру хакында тәкъдимнәр керде. Әмма без моның гына җитәрлек булмавын дәлилләдек. Хәзер хакимият органнарының барлык дәрәҗәләре вакансияләренең гомуми базасы формалашачак.

Безнең тарафтан шулай ук, максатчан белем алганнан соң, муниципаль хезмәтне башкару бурычы турындагы канун кабул ителде. Ул киләчәге өметле яшь белгечләрне бу эшкә тарту мөмкинлеген тудыра. Әлеге кадрларны һөнәри әзерләү канун нигезләмәләре белән тәэмин ителә, ә алар исә яшь белгечләрне аерым бер вакытка үзләрен укырга җибәргән территорияләргә беркетүне күздә тота. Без күпмедер дәрәҗәдә вуз тәмамлаган яшь белгечләрне эшкә билгеләү гамәленә әйләнеп кайтабыз. Комитет әгъзалары фикеренчә, мондый кануннарны кабул итү кадрларны урыннарга җәлеп итү, ҖҮИ алдындагы бурычларны яхшырак үтәү мөмкинлеге тудырачак.

Комитетның муниципаль бергәлек белән тыгыз элемтәдә иҗат иткән законнарының тагын берсе – «Россия Федерациясендә дәүләти-шәхси һәм муниципаль-шәхси хезмәттәшлек турында». Хәтта аның атамасы үзе үк муниципаль бергәлекнең эш нәтиҗәсе: безне ишеттеләр һәм хезмәттәшлекнең дәүләти-шәхси генә түгел, муниципаль-шәхси дә булырга мөмкинлеге белән ризалаштылар. Өч яклы: «дәүләти-муниципаль-шәхси» килешү дә булырга мөмкин.

Бер үк вакытта гамәли тәҗрибә дә бик мөһим. Мин сынау рәвешендәге ике һәм өч яклы проектларны күздә тотам. Әлеге иң яхшы тәҗрибәнең башка төбәкләргә үрнәк булуы зарури.

Хезмәттәшлекнең эшкуарлык белән генә булуы мөһим түгел. Кайбер җитәкчеләр җирле үзидарә ул, барыннан да бигрәк, кешеләр, шунда яшәүче халык икәнлеген онытып җибәрә. Алар үз муниципалитетлары тормышында мөмкин кадәр күбрәк катнашырга тиеш. Бер яктан, халык арасыннан сайланган депутатларның саны күп булырга тиеш. Депутат халыкка якын, аңа игътибарлы булсын. Икенче яктан, халыкның үзидарә эшендә катнашуына җәмәгатьчелек контроле, җәмәгать палатасы, ҖҮИ органнары каршындагы төрле шуралар кебек механизмнар ярдәм итә ала. Аның төгәл формасы муниципаль берәмлекнең үзенчәлекләренә бәйле. Күргәнегезчә, муниципаль һәм дәүләти хакимият органнары арасындагы үзара хезмәттәшлек җайга салынган һәм сизелерлек нәтиҗәләргә ирешә.

**– Муниципалитетларга бирелгән кайбер вәкаләтләрнең финанс ягыннан тәэмин ителмәве – барыбызга да таныш мәсьәлә. Аны ни рәвешле хәл итеп була?**

– Хәзерге чор гади түгел, шунлыктан төбәкләрнең һәм муниципалитетларның финанс мәсьәләләрен хәл итү – төп һәм иң катлаулы мәсьәлә булып кала бирә. Монда гади исәп-хисап алып бару гына җитми, ә ҖҮИгә карата кызыксындыру уятучы бюджет-салым сәясәте кулланырга кирәк. Шуннан башка булмый. Муниципалитетлар үзләрен кеше җилкәсендә утыручылар итеп түгел, ә илнең социаль-икътисадый үсешендә актив катнашучылар, тулы хокукка ия хуҗалык итүче субъектлар итеп тоярга тиеш.

Беркадәр уңышлар бар, билгеле. 2013 һәм 2014 елларда аларга өстәмә керем чыганаклары бирелгән иде, шулар буенча җыемнар ун мәртәбә артты. Әйтик, физик зат-

лар мөлкәтенә яңа салым кертелә, ул милекнең базар бәясеннән чыгып салына башлаячак. Әмма алга барырга кирәк!

Президент юлларны күбрәк төзү бурычын куя. Бездә моны гамәлгә ашыру чарасы бар инде: муниципаль юл фондлары ул. Аларны тулыландырырга кирәк. Моның өчен ЯММ акцизлары гына җитми. Без әлеге фондларга физик затларның транспорт салымыннан кергән акчаларны юнәлтергә тәкъдим иттек. Җыемнар турында да уйлап карарга була. Сәүдәнекен түгел, ә җирлеләрен: гомум таралган файдалы казылмаларга, курортка, җирле символларга, территорияләрне карап тотуга җыемнар.

Җирле җыемнар турында илнең Төп канунында да әйтелгән, әмма әлегәчә файдаланылмыйлар. Былтыр җирле үзидарә системасының 150 еллыгын билгеләп үттек. Ә ул җирле җыемнарга һәм әлеге дә баягы эшкуарларның иганәчелек ярдәменә таянып аякка баскан. Әлеге акчаларга атаклы земство мәктәпләре һәм хастаханәләре, юллар төзелгән.

Болар – беренче адымнар, әлбәттә. Иң мөһиме – җирле үзидарә органнары территориянең социаль-икътисадый үсеше мәсьәләләрен хәл итүдән читтә калмаска тиеш. Салым базасын ныгытырга була: урта һәм кече эшкуарлыкның нәтиҗәле эшләве өчен шартлар тудырырга, эш хакларын вакытында түләүне контрольдә тотарга, кешеләрнең хезмәтенә түләүдә «соры» схемаларга юл куймаска кирәк. Муниципаль казнаны тулыландыру үзагымга җибәрелмәгән, мәсьәлә белән җитди һәм җентекләп шөгыльләнгән урыннарда финанс мөмкинлекләренең тормыш-көнкүрешне тәэмин итәргә җитәрлек булуыннан тыш, муниципалитетларның киләчәктәге үсешен кайгыртуга да өлеш чыгарылуына мисаллар булуын күрәбез.

**– Татарстан Муниципаль берәмлекләр Советының эш тәҗрибәсенә, гомумән алганда, республикабыздагы җирле үзидарә системасына нинди бәя бирәсез? Башка төбәкләрдәге коллегалар республика тәҗрибәсеннән нәрсәне үзләренә өлге итеп ала алыр иде?**

– Татарстан – федерациянең алдынгы һәм бик тиз үсеш кичерүче субъектларының берсе ул. Сездән бик күп нәрсәгә өйрәнергә була, шул исәптән җирле үзидарәне үстерү моделенә, төбәк һәм муниципаль хакимиятләрнең үзара хезмәттәшлегенең уңай тәҗрибәсенә. Бер үк вакытта, ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның җирле үзидарәгә ярдәме бик әһәмиятле роль уйный. Күбесенчә шуңа бәйле рәвештә, Татарстанда муниципалитетларны үсешкә ирештерүче күпсанлы программалар гамәлгә ашырыла, иң тырыш муниципалларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән бәйгеләр үткәрелә, авыл җирлекләрен үстерүгә, территориаль иҗтимагый үзидарәләргә хәерхаһлык күрсәтүгә тәгаенләнгән грантлар бүлеп бирелә. Соңгы берничә ел эчендә бәйгеләр кысаларында муниципалитетларга меңнән артык автомобиль бирелгән. Республика тормышында ҖҮИ органнары роленә җитди игътибар бирелүен расլый бу.

Татарстан Муниципаль берәмлекләре Советы ГМБКның иң актив әгъзаларының берсе, республикада аның абруе зур. Уңышлы эшләвенең нигезе югары һөнәрилеккә бәйле булуын ул үз эшчәнлеге белән раслый. Татарстан тәҗрибәсе муниципаль бергәлекнең республика дәүләт хакимияте органнары белән килешеп эшләве, тикшерү-күзәтчелек инстанцияләре белән проблемаларны хәл итә белүе ягыннан кызыклы. ТР Муниципаль берәмлекләре Советы юристларының авыл җирлекләренә ярдәм күрсәтү тәҗрибәсе дә бик әһәмиятле. Татарстанда җирле үзидарә өлкәсенә кагылышлы закон проектларының һәм норматив актларның ТР Муниципаль берәмлекләре Советында экспертиза үтүенең гамәлгә керүе игътибарга лаек. Татарстанда муниципаль кадрларны укытуга зур игътибар бирелә. Республика муниципаль бергәлегенең системалы һәм уңай эш тәҗрибәсе бик зур игътибарга һәм Россиянең башка төбәкләренә тарату өчен җентекләп өйрәнүгә лаек.

**Төбәкләрнең һәм муниципалитетларның финанс мәсьәләләрен хәл итү – төп һәм иң катлаулы мәсьәлә булып кала бирә. Монда гади исәп-хисап алып бару гына җитми, ә ҖҮИгә карата кызыксындыру уятучы бюджет-салым сәясәте кулланырга кирәк. Шуннан башка булмый. Муниципалитетлар үзләрен кеше җилкәсендә утыручылар итеп түгел, ә илнең социаль-икътисадый үсешендә актив катнашучылар, тулы хокукка ия хуҗалык итүче субъектлар итеп тоярга тиеш.**





Үзәк федераль округтагы киңәшмә (Тамбов, 2015 елның сентябре).

# РЕСПУБЛИКА саннарда




**191 млрд 320 млн сум 2015 елда республика бюджетының керем өлешен тәшкил итә.** Чыгымнар – 208 млрд 118 млн сум. Дефицит – 16 млрд 797 млн сум. Быелгы елга бюджетның керем өлеше 18,4 млрд сумга артты. Чыгым өлеше 17,5 млрд сумга үсте. Өстәмә акчалар авыл хуҗалыгына (1,3 млрд сум) һәм кече эшкуарлыкка (977 млн сум) дәүләт ярдәме күрсәтүгә, Яр Чаллы сәнәгать зонасында гомуми кулланыштагы юллар инфраструктурасын булдыруга, мәктәпкәчә белем бирүнең төбәк системаларын модернизацияләүгә һәм башка максатларга юнәлдерелгән.




**2,8% ка (90,5 млрд сумга кадәр) 2015 елның 9 ае эчендә Татарстанның дәүләт бурычы күләме кимеде.** Бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренә карата республика дәүләт бурычының нисбәте 55%ны тәшкил итә. Әлеге мәгълүматлар Россия субъектлары арасында бурыч йөкләмәләре буенча «Рейтинг РМА» төзегән рейтингта китерелә. 2015 елның гыйнвар – сентябрь айларында РФ төбәкләренең дәүләт бурычы 4%ка, ягъни 2,17 трлн сумга үскән. Әлеге чор өчен дәүләт бурычы күләме буенча лидерлар арасында – Мәскәү шәһәре (143 млрд сум) һәм Краснодар крае (139 млрд сум). 2014 ел йомгакларына карата РФ субъектларының дәүләт бурычлары уртача 25–30%ка артырга мөмкин, дип көтелә.



**3 нче урын – РФ төбәкләренең инновацияле үсеше рейтингында Татарстан әнә шул урынга лаек булды.** ТР төбәк инновацияле системасы характеристикасында технологик һәм технологик булмаган инновацияләрнең гамәлгә ашыручы оешмаларның чагыштырма авырлыгы, төяп озатылган товарлар һәм башкарылган эш күләмнәрендә технологик инновацияләргә чыгымнарның чагыштырма авырлыгы һ.б.лар регионның көчле яклары булуы билгеләнеп үтелә. ТРның йомшак яклары арасында түбәндәгеләр атала: рецензияләнә торган журналларда басылган, РИНЦта индексацияләнә торган мәкаләләрнең саны, ТТПнда югары технологияле продуктларның һәм фән сыйдырышлы тармакларның өлеше һ.б.



**38,5 млн сумлык хезмәт 2015 елның 9 ае эчендә Татарстанда электрон рәвештә күрсәтелгән.** Бу узган елның шул ук чорына карата 75 процентка күбрәк. Узган ел белән чагыштырганда дәүләт хезмәтләре порталы аша бирелгән гаризалар 55%ка арткан (1 млн 881 мең 745), теркәлгән шәхси кабинетлар саны 1 млн 460 мең 633кә кадәр җиткән, электрон чиратка язылучылар 1,5 тапкырга үскән (5 млн 718 мең 364), порталга керүчеләр 50%ка арткан (23 млн 264 мең 185).



**4 млрд 755 млн сум – агымдагы елның октябрь башына татарстанлыларның торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурычлары шул сумманы тәшкил итә.** Иң зур бурычлар Казанда (2 млрд 145 млн сумнан артык), Яр Чаллыда (658 млн сумнан артык), Түбән Кама (330,5 млн сум) һәм Әлмәт районнарында (384 млн сум) теркәлгән. Кайбыч районы халкы барыннан да азрак бурычка ия – 100 мең сумнан бераз гына артык.

**2,8%ка, яки якынча 2 млрд сумга 2015 елның 9 аенда бухгалтер исәбенең Россия стандартлары буенча «Татнефть»нең чиста табышы кимегән һәм 69,7 млрд сумны тәшкил иткән.** 2015 елның гыйнвар – сентябрь айларында компаниянең кереме, 12,5% ка (38,8 млрд сум) үсеп, 349,25 млрд сумга җиткән. Тулай табышы 16,2 млрд сумга арткан һәм 123,5 млрд сумга җиткән.




**100 млн доллар агросәнәгать комплексы үсешенең Татарстан – Кытай фондын финанслау өчен бүлеп биреләчәк.** Тулаем алганда, төзелеп килә торган Россия–Кытай фонды 3 млрд долларны тәшкил итәчәк. Хәзерге вакытта әлеге фонд акчалары бүленәчәк инвестицияле проектларның критерийлары эшләнә.



**152 проект (гомуми бәясе 764 млрд сум) ТР Инвестицияле үсеш агентлыгының инвестицияле проектлар базасына кертелгән.** Инвестицияләрнең иң зур күләме сәнәгатькә һәм авыл хуҗалыгына, һәм шулай ук төзелеш, медицина һ.б. тармакларга туры килә.



**12,6 млрд сум – «Алабуга» МИЗ территориясендә тормышка ашырыла торган яңа дүрт проектның гомуми бәясе әлеге сумманы тәшкил итә.** Бүген махсус икътисадый зонада 49 резидент теркәлгән. Барлык игълан ителгән проектларның гомуми күләме хәзер 154,9 млрд сум торачак.




**220 млрд сум – 2015 ел йомгаклары буенча Татарстанда авыл хуҗалыгында җитештерелгән тулай продукция күләме әнә шул суммада фаразлана.** 2014 елда тулай продукция күләме 189 млрд сумны тәшкил итте.





**АСКна караган 92% предприятие республикада табышлы дип исәпләнә. 8%ы зыянга эшли.** Быел авыл хуҗалыгы компанияләре кредитлар буенча бурычларның үсүенә юл куймыйлар. Татарстан АСК хезмәткәрләренең уртача хезмәт хакы 14%ка артып, 17 мең сумны тәшкил итте.



**3,5 млрд сумга ел башыннан «Татреспотребсоюз» бүлекчәләре республика халкыннан авыл хуҗалыгы продукциясе сатып алган (узган елның әлеге чорына карата үсеш – 111 процент).** Тулаем алганда, агымдагы ел нәтиҗәләре буенча ТР кулланучылар кооператорлары авыл хезмәтчәннәреннән 5 млрд сумлык авыл хуҗалыгы продукциясе сатып алырга планлаштыра, бу узган ел белән чагыштырганда күбрәк.




**50 млн АКШ доллары – Бөтендөнья үсеш банкы тарафыннан гамәлгә куелган «Кече шәһәрләргә зур инвестицияләр» конкурсы кысаларында Чистай шәһәре әнә шул суммалык грантка ия булачак.** 2016 елда әлеге акчаларга Чистайның тарихи өлешендә ремонт-реставрация эшләренең тулы комплексы проектланачак, 2017 елда реставрация эшләре башланачак.



**31 мең кешегә кадәр 2015 елда республикада хезмәт мигрантлары саны үсте (33%ка).** 27 меңнән артык мигрант үз хезмәт эшчәнлекләрен законлаштырды. Иң күп хезмәт патенты Казанда, Түбән Камада, Яр Чаллыда, Әлмәттә миграция исәбенә баскан чит ил кешеләренә бирелгән. Мигрантлар, нигездә, төзелештә, транспорт хезмәте күрсәтү тармагында, җәмәгать туклануы предприятиеләрендә эшлиләр. Ел башыннан Россия Федераль миграция хезмәтенең ТР буенча Идарәсендә 160 меңнән артык чит ил гражданы һәм гражданлыгы булмаган затлар миграция исәбенә бастырылды.



**2 млрд сумга якын акча 2015 елда Татарстанга федераль бюджеттан үсемлекчелекне үстерүгә бүлеп бирелгән.** Россия төбәкләренә әлеге максатлар өчен юнәлдерелгән федераль субсидияләрнең гомуми күләме 15,5 млрд сумга якын акчаны тәшкил итте. Акчалар федерациянең 79 субъекты бюджетларына бүленәчәк.

**2,5 млрд сумга Татарстан терлекчелек тармагын үстерүгә алачак.** Гомуми күләме 29,2 млрд сум булган акчалар 2016 елда федераль бюджеттан федерациянең 74 субъекты арасында бүленәчәк.



**5 млрд сумга якын акча – 2014 ел йомгаклары буенча татарстанлылар түләргә тиешле мөлкәткә салым күләме әнә шул сумманы тәшкил итә.** Төгәлрәк әйтсәк, салынган салым күләме 4 млрд 975 млн сумнан артыграк, шул исәптән 771 млн сум – мөлкәткә салым, 3 млрд 423 млн сум – транспорт салымы, 780 млн сум җир салымы буларак түләнергә тиеш.



**910 млн сум 2015 елда Казандагы паркларны һәм скверларны төзекләндерүгә кертелгән.** 310 млн сум республика бюджетыннан бүленгән, 600 млн сум – инвесторлар акчалары. Татарстан башкаласында 130 парк һәм сквер исәпләнә. Аларның гомуми мәйданы 300 гектарга җитә.



**271 млн нан артык хакер атакасы 2015 ел башыннан Татарстан Электрон хөкүмәте сегментына ясалган.** Барлык һөҗүмнәрнең 35%ы – Microsoft Windows операцион системасында ераклаштырылган эш өстәленә үтеп керү омтылышы. Закон бозуларның тагын 25%ы – файл системаларына пароль сайларга тырышуга, 15%ы җиһаз портлары һәм гамәли программа системаларының йомшак якларын сканлаштыруга карый.



**76 млн сум** 2015 елда республика программасы кысаларында 14 балаларны савыктыру лагерен капиталь төзекләндерүгә тотылган.



# «Кар өстендәге ИСЛАМ», яки Киләчәккә йөз тоткан традицияләр





Фото www.tatarstan.ru сайтыннан

Күптән түгел Татарстан җитәкчелеге Болгар шәһәрендә Болгар ислам академиясен төзү инициативасы белән чыкты, һәм октябрь башында бу проектны тормышка ашыра башладылар. Әлеге идея РФ Президенты Владимир Путин һәм илнең барлык төп мөселман оешмалары тарафыннан хупланды. Идел буе Болгарстанының борынгы башкаласы территориясендә узган «Мөселман дини тәгълиматы: милли, региональ һәм мәдәниятле үлчәнеш» дигән халыкара фәнни-гамәли конференциясендә ислам академиясенең нинди булырга тиешлеге, илдә һәм дөньяда исламның хәзерге хәле турында җитди сөйләшү алып барылды. Конференциядә Россия, Төркия, Мисыр, Сүрия, Гыйрак, Таҗикстан һәм Казахстанның дин галимнәре, фәнни һәм эксперт җәмәгатьчелеге вәкилләре, мөселман руханилары катнашты. Форумга ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Милли эшләр буенча федераль агентлык башлыгы Игорь Баринов, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Россия мөселманнары Үзәк диния нәзарәте рәисе Тәлгать Таҗетдин, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил Сәмигуллин, Россия мөфтиләре шурасы рәисе Равил Гайнетдин һәм Россиянең башка күп кенә абруйлы дәүләт һәм дин эшлеклеләре дә килгән иде.

Рөстәм Миңнеханов үзенең чыгышында болай диде: «Россия Президентына безне аңлавы һәм эшебезне хуплавы өчен без бик рәхмәтле. Хәзер алдыбызда бу проектны тормышка ашыру бурычы тора. Рухи тамырларыбызның нәкъ менә Болгарда булуын аңлаганлыктан, биредә без үзебезне бөек мөселман мәдәниятенең бер өлеше итеп тоябыз, шуңа күрә ислам академиясенең дә шушында төзелүе дөрес булачак. Болгар кабат бөтенроссия һәм халыкара әһәмияткә ия булган абруйлы үзәккә әйләнергә тиеш». РТ Президенты фикеренчә, академияне татарның бай дини мирасын өйрәнү һәм торгызу, толерант дини хокукый мәктәп буларак хәнәфи мәзһәбен популярлаштыру өчен җыелу урыны итәргә кирәк. «Академия төзелү тынычлык сөюче исламның, Россия дәүләтчелегенең аерылгысыз өлеше буларак, позициясен ныгытыр, дип ышанам», – диде Татарстан Президенты.

ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Россия һәм чит ил кунакларына Идел буе болгарларының 922 елда нәкъ менә биредә, Болгар җирендә, Россиянең хәзерге территориясендә беренче булып дәүләт дине сыйфатында үз ихтыярлары белән исламны кабул итүләре турында сөйләде. Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларын кичеп, уникаль күренеш – Идел буе татарлары исламы, Россия исламы, яки, Минтимер Шәймиев сүзләре белән әйтсәк, «кар өстендәге ислам» барлыкка килде.

«Шуңа күрә без бүген нәкъ менә Болгарда җыелдык та. Бу тарихи мизгелне болай аңларга кирәк: образлы итеп әйтсәк, без бүген кайчандыр халкыбыз һәм илебез язмышы кушуы буенча өзелгән вакыт җепләрен ялгыйбыз», – диде Минтимер Шәймиев.

Конференциядә чыгыш ясаган ислам динен өйрәнүчеләр, Россия мөселман оешмалары җитәкчеләре Болгар ислам академиясен төзү идеясен хупладылар, дин өйрәнүче татарларның бөтендөнья ислам мирасына гаять зур өлеш кертүләрен билгеләп үттеләр. Сүз дә юк, академияне оештыручылар алдында җитди һәм катлаулы бурычлар тора. Булачак проект турындагы шикләргә карата ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов бик ачык итеп әйтте: «Без гади мәсьәләләрне чишәргә алынмыйбыз. Гади булса, аны башка кешеләр чишәр иде… Билгеле, хәзергә академиянең нинди булачагын төгәл генә әйтү кыен, әмма бу проект тормышка аша алмый дигән сүз түгел. Җимешләрен бүтәннәр җыяр, әмма башта кемдер орлыгын да чәчәргә тиеш».




Сәясәт фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Идарә, икътисад һәм финанс институтының дәүләт һәм муниципаль идарә кафедрасы доценты, КФУ Югары дәүләт һәм муниципаль идарә мәктәбенең экспертлар советы рәисе Любовь ГУСЕВА тексты.

# *ҖИРЛЕ үзидарә: чит илләр тәҗрибәсе*

ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ДӘҮЛӘТНЕҢ МИЛЛӘТЛӘР БУЕНЧА (ФЕДЕРАЦИЯДӘ – ТӨБӘКЛӘР БУЕНЧА) ТЕРРИТОРИАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ҮЗИДАРӘСЕН ТӘШКИЛ ИТӘ. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ТУРЫНДАГЫ ЕВРОПА ХАРТИЯСЕНДӘ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ «ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ, ЗАКОН КЫСАЛАРЫНДА ЭШ ИТЕП, ДӘҮЛӘТ ЭШЛӘРЕНЕҢ КҮП ӨЛЕШЕН ҮЗ ҖАВАПЛЫЛЫГЫНА АЛЫП ҺӘМ ҖИРЛЕ ХАЛЫК МӘНФӘГАТЬЛӘРЕН КАЙГЫРТЫП РЕГЛАМЕНТЛАШТЫРУ ҺӘМ АҢА ИДАРӘ ИТҮ ХОКУКЫ ҺӘМ МОНЫ ЧЫННАН ДА БАШКАРА АЛУЫ» БУЛАРАК АҢЛАШЫЛА.

«Җирле үзидарә» төшенчәсе тәүге тапкыр Бөек француз революциясе чорында кулланылган. Термин буларак барлыкка килү тарихы Пруссия министры һәм дәүләт идарәсе теоретигы Лоренц фон Штейн исеме белән бәйле. Үзидарәне ул дәүләт эшләре белән идарә итүдә гражданнарның җирле дәрәҗәдә катнашуы формасы итеп кенә түгел, ә кешеләрдә бер бергәлеккә карау хисен уяту чарасы буларак та күргән.

Бүген барлык демократик дәүләтләрдә җирле үзидарәгә җәмгыять идарәсенең мөһим бер өлеше, үзәктән идарәгә зарур өстәмә һәм аңа каршы як, җәмгыятьнең демократик төзеклеген күрсәтә торган шарт итеп карыйлар.

Алдынгы демократик илләрдә, аларның милли үзенчәлекләре нинди булуга карамастан, җирле үзидарәгә түбәндәге уртак яклар хас:

– күмәк вәкиллекле органны төзегән җирле дәрәҗәдә сайлап куелган вәкилләргә демократик контроль бар;

– юридик зат статусы бирелгән;

– җирле салымнар билгеләү хокукына ия;

– вәкаләтләрнең киң кырын башкарырга хокук бирә торган күпфункцияле компетенция өлкәсе бар.

Җирле үзидарәнең Европа хартиясенә нигез итеп өч принцип алынган: җирле үзидарәгә хокук, гомуми компетенция хакимияте һәм субсидиарлык принцибы.

Җирле үзидарәгә хокук шушы халәтне конституция системасы кысаларында законнар белән беркетүдә күренә. Җирле хакимиятнең милли конституцияләр яки төп закон белән гарантияләнгән аерым бер статусы бар. Әйтик, федераль дәүләтләрдә (аерым алганда, АКШта) бу хокук федерация субъектлары конституцияләрендә беркетелгән булырга мөмкин.

Җирле хакимиятләрнең хокуклары, мәсәлән, алардагы җәмгыятьләрнең эшләрен кайгыртудан (Дания) яки үзенең эшчәнлегенә идарә итүдән һәм аны җайга салудан (Германия) гыйбарәт.

Гомуми компетенция хакимияте җирле үзидарә органнарына, үзендәге җәмгыятьләрнең мәнфәгатьләрен күз алдында тотып, ил законнары белән тыелмаган теләсә нинди гамәл кылу мөмкинлеген бирә.

Көнбатыш Европа илләренең күбесендә хакимиятнең җирле органнары хакимлек итүче гомуми компетенциядәге вәкаләтләргә ия, ягъни алар, җирле җәмгыять мәнфәгатьләрен уйлап, аларга махсус беркетелмәгән теләсә нинди чара күрергә хокуклы. Монда нигез күрсәткеч хакимлек итүнең махсус вәкаләтләре һәм бурычлары җыелмасы булудан түгел, ә илкүләм әһәмиятле бурычлар өстәлә торган киң спектрлы хакимият булудан гыйбарәт. Практикада, әлбәттә, җирле хакимиятләр эшчәнлегенең саллы өлешен үз йөкләмәләренә туры килә торган хезмәтләр күрсәтү алып тора.

Субсидиарлык принцибы тегеяки бу эшчәнлек өлкәсендәге компетенциянең идарәнең мөмкин булган кадәр халыкка иң якын гади дәрәҗәсендә булу шартын тәэмин итүне күз алдында тота.

Субсидиарлык принцибы – демократик дәүләтчелекнең төп принципларыннан һәм хакимиятләр бүленеше принцибын алга таба үстерү принципларыннан берсе.

Җирле үзидарәнең Европа хартиясе Европа Советының җирле хакимиятләр һәм региональ хакимиятләр Конгрессы тарафыннан кабул ителгән һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нигез принципларын билгели торган иң мөһим күпкырлы документ булып тора.

Демократик җәмгыятьнең сәяси системасында җирле үзидарәнең тоткан урыны аның функцияләренә һәм структурасына да нык бәйле. Җирле үзидарәнең структурасын сайлаганда тегеяисә бу структурага өстенлек бирүгә берничә фактор йогынты ясый. Менә кайберләре:

– функцияләрнең асылы, җитәкчелек итү таләп ителгән хезмәтләрнең үзенчәлеге, шулай ук җирле үзидарә органнары алдына куелган идарә бурычларының төп нигезе;

– сайлап куелган вәкилләрнең эшне сыйфатлы башкарубашкармаулары һәм түрәләрнең һөнәри һәм шәхси сыйфатлары дәрәҗәсе;

– ил дәрәҗәсендә (идарәнең парламент яки президент формасы) башкарма хакимиятнең өстенлеге һәм лидерга карата социаль-мәдәни мөнәсәбәтләр тәҗрибәсе;

– үзәктән җитәкчелекнең нинди дәрәҗәдә булуы (үзәкләшү дәрәҗәсе) һәм таләп ителгән контроль дәрәҗәсе.

Теләсә кайсы җирле үзидарә системасында һәркемнең турыдан-туры тавыш бирүе нәтиҗәсендә сайлап куела торган җирле советның нинди урын алып торуына әһәмият бирелә. Советларның эшчәнлегенә, гомумиләштереп караганда, төп өч сыйфат хас:

– җирле үзидарә органнарының һәм төп стратегик үзәкләрнең әлеге дәрәҗәдәге компетенциянең һәр өлкәсендә гомуми сәясәтен билгели торган карарлар кабул итү;

– хакимиятнең башкарма органнары тарафыннан кабул ителә торган төп карарларны хуплау һәм раслау;

– башкарма органнарның гамәлләренә гомуми контроль.

Төрле илләрдә җирле үзидарә системасының мәҗбүри һәм үзәк өлешен тәшкил итүче, җирле демократиянең үзәге һәм символы булып торучы советлар чынлыкта төрлечә хакимлек итәләр, әлеге хакимлек, аларның сәяси эшчәнлегендәге үзенчәлекләр кебек үк, бер яктан, тегеяки бу илдәге җирле үзидарәнең гомуми статусы белән билгеләнсә, икенче яктан, алар белән башкарма хакимият органнары арасында функцияләрнең чынлыкта ничек бүленүенә бәйле.

Җирле үзидарәнең үсеше хакимиятнең җирле органнары эшчәнлеген оештыруның өч моделе барлыгын күрсәтә:

– иерархия буенча оештыру;

**«Җирле үзидарә» төшенчәсе тәүге тапкыр Бөек француз революциясе чорында кулланылган. Термин буларак барлыкка килү тарихы Пруссия министры һәм дәүләт идарәсе теоретигы Лоренц фон Штейн исеме белән бәйле. Үзидарәгә ул дәүләт эшләре белән идарә итүдә гражданнарның җирле дәрәҗәдә катнашуы формасы итеп кенә түгел, ә кешеләрдә бер бергәлеккә карау хисен уяту чарасы буларак та караган.**



**Алдынгы демократик илләрдә, аларның милли үзенчәлекләре нинди булуга карамастан, җирле үзидарәгә түбәндәге уртак яклар хас: күмәк вәкиллекле органны төзегән җирле дәрәҗәдә сайлап куелган вәкилләргә демократик контроль бар; юридик зат статусы бирелгән; җирле салымнар билгеләү хокукы бар; вәкаләтләрнең киң кырын башкарырга хокук бирә торган күпфункцияле компетенция өлкәсе бар.**




– базар механизмнарын күз алдында тоту;

– төрле социаль, сәяси һәм икътисадый кызыксынулардан чыгып координацияләү.

Иерархия моделенә йөкләмәне күпсанлы процессларга бүлү һәм буйсынучыларның үз функцияләрен йөкләмәнең тулаем үтәлешенә ирешерлек итеп башкаруын тәэмин итү өчен контроль системасын билгеләү хас. Ул контроль һәм буйсыну системасы белән тоташкан бурыч-йөкләмәләр чылбырын тәшкил итә. Һәр өлешнең үзенә билгеләнгән урыны, махсус бурычы һәм үз бурычын хәл итүдә билгеле бер мөстәкыйльлеге бар. Контроль кагыйдәләр һәм процедуралар системасы аркылы башкарыла, ә аны үткәрә торган кешеләрнең теләге буенча түгел.

Иерархия, төрле яктан чыгып караганда, күп кенә Көнбатыш илләрендә сугыштан соңгы чорда җирле үзидарә органнарын оештыруның төп принцибы булып торган. Хакимиятнең җирле органнары дәүләт үткәрә торган үзәктән билгеләнгән сәясәтне тормышка ашыручылар буларак эш иткәннәр һәм үз эшләрен махсус функциональ, эшчәнлекләре иерархия буенча тикшерелә торган департаментлар аркылы оештырганнар.

Вазгыять 1970 нче еллар уртасында үзгәрә башлый, бу чорда берничә илдә киеренкелек куера һәм каршылыклар арта. Җирле хакимиятләр үзәкнең абруена шик белән карый башлый, аңа ризасызлык белдерә. Хәзер без иерархия, үсеш алган демократиянең күп кенә дәүләтләре өчен әйдәүче принцип буларак, көчсезләнә бара дип әйтә алабыз. Ләкин сайлап куела торган мэр вазыйфасы булган җирдә мэр еш кына элеккечә төп зат булып кала.

Җирле үзидарәне оештыруның базар моделе билгеле бер сәясәтне тормышка ашыру юлы булып тора. Бу очракта төп шартлар – хезмәт күрсәтүчеләр арасында конкуренция булдыру, хезмәт күрсәтүләрне һәм кулланучыларга хезмәт күрсәтүләрнең кайсына өстенлек бирүләрен белдерергә һәм тәкъдим ителгән хезмәт күрсәтүләрдән үзенә кирәген сайлап алырга мөмкинлек бирә торган механизмнар булдыруны тәэмин итүчеләр өчен базар мохитен тудыру.

Базар моделе җәмәгатьчелек белән хакимиятнең җирле органнары арасындагы мөнәсәбәтләрне түбәндәгеләргә бәйле аңлата. Бер яктан, җәмәгатьчелек үзе тарафыннан кертелгән акчаларның нәтиҗәле файдаланылуына өметләнә торган ниндидер акционер буларак карала, икенче яктан, ул – хезмәт күрсәтүләрне сайлап алу һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатына һәм рәвешенә билгеле бер контроль ясау мөмкинлеге булырга тиешле кулланучы.

Челтәр моделе сәясәтнең нәтиҗәле гамәлгә ашырылуын төрле оешмаларның уртак тырышлыгы һәм төрле мәнфәгатьләрне исәпкә алып эш итү нәтиҗәсе буларак карый. Хезмәттәшлеккә ирешү өчен теләктәшлеккә, лояльлеккә, ышанычка һәм ике якның да кызыксынулы булуына нигезләнгән мөнәсәбәтләр урнаштырырга һәм, шуларга ук нигезләнеп, аларны саклап калырга кирәк. Челтәр



**Теләсә кайсы җирле үзидарә системасында һәркемнең турыдан-туры тавыш бирүе нәтиҗәсендә сайлап куела торган җирле советның нинди урын алып торуына әһәмият бирелә. Советларның эшчәнлегенә, гомумиләштереп караганда, төп өч сыйфат хас: җирле үзидарә органнарының һәм төп стратегик үзәкләрнең әлеге дәрәҗәдәге компетенциянең һәр өлкәсендә гомуми сәясәтен билгели торган карарлар кабул итү; хакимиятнең башкарма органнары тарафыннан кабул ителә торган төп карарларны хуплау һәм раслау; башкарма органнарның гамәлләренә гомуми контроль.**



**Субсидиарлык принцибы теге яки бу эшчәнлек өлкәсендәге компетенциянең идарәнең мөмкин булган кадәр халыкка иң якын гади дәрәҗәсендә булу шартын тәэмин итүне күз алдында тота. Субсидиарлык принцибы – демократик дәүләтчелекнең төп принципларыннан һәм хакимиятләр бүленеше принцибын алга таба үстерү принципларыннан берсе.**

моделе шартларында оешмалар, дискуссияләр, сөйләшүләр һәм ачык коммуникация аркылы үзләренең үзара бәйләнештә булуларын танып, шулай ук уртак белемнәрен һәм тәҗрибәләрен үстереп, хезмәттәшлек итәргә өйрәнәләр, бу исә үз чиратында бер-берсе алдында озак вакытка исәпләнгән йөкләмәләрнең барлыкка килүенә этәргеч бирә.

Җирле үзидарәне оештыруның мондый юлы хакимиятнең җирле органнарында чагыштырмача куәтле җирле финанслау чыганагы булуны күз алдында тота. Әлеге модель күзлегеннән караганда, структура һәм функцияләр уйланган дәрәҗәдә мөһим түгел, чөнки төп урынны оешмалар арасындагы нәтиҗәле эшчәнлекне тәэмин итә торган һәм көтелгән нәтиҗәләр бирә торган мөнәсәбәтләр алып тора.

Челтәр моделе җәмәгатьчелеккә гражданнар итеп карый. Бер яктан, алар җирле җәмгыятьнең ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү өчен җаваплы булырга тиеш (бу бигрәк тә бай яши торган кешеләргә кагыла). Икенче яктан, гражданнар хакимият органнары вәкилләренә консультацияләр бирергә һәм сәяси процесста катнашырга хокуклы.

Җирле үзидарәнең хәзерге системаларын өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин.

Беренче төркемгә җирле үзидарә системалары керә, монда җирле үзидарә органнарының конституция белән каралган статусы бар, әмма хезмәт күрсәтү барышында алар гадәттә ярдәмнең булу-булмавына һәм җирле бүлекләре булган деконцентрацияләнгән үзәк агентлыкларның күрсәтмәләренә бәйле була. Җирле үзидарә органнарының эшчәнлегендә һәм гомумән гамәлдә булуында, административ асылга караганда, иң элек сәяси мәгънә бар: җирле үзидарә барыннан да бигрәк җирле җәмгыятьнең үзенчәлегенә, аның үзаңына кагылышлы була.

Конституция күзлегеннән чыгып караганда, бер төрле статустагы хакимиятнең барлык җирле органнары «уртак югары башлык» – үзәк хакимиятләр исеменнән берничә җирле үзидарә берәмлеген берләштерүче милләтләр буенча бердәйләштерелгән административ территориянең бөтен эшчәнлегенә рәсми контроль башкаручы префект канаты астында яшиләр. Мондый тәҗрибә Италиядә, Бельгиядә, Испаниядә, Португалиядә һәм тагы берничә дәүләттә күзәтелә.

Җирле үзидарә системаларының икенче төркеменә җирле хакимият органнарының конституциядә каралган статуслары булмау хас (һәрхәлдә – милли дәрәҗәдә). Җирле хакимият органнары гадәттә илнең югары вәкиллекле органы (парламент) тарафыннан кабул ителгән тиешле закон актына нигезләнеп төзелә. Шулай итеп, көндәлек эшчәнлек турында сүз барганда, җирле хакимиятләр үзәккә караганда күпкә мөстәкыйльрәк (Ирландия, Канада, Австралия, Яңа Зеландия һәм башка берничә дәүләт).

Өченче модельне шартлы рәвештә күбесенчә Төньяк һәм Үзәк Европа дәүләтләренә хас җирле үзидарә моделе дип билгеләп була. Җирле үзидарә органнары гадәттә закон актлары белән гарантияләнгән үзенчәлекле хакимлек вәкаләтләреннән югарырак гомуми функциональ компетенция алалар. Мондый вариантта җирле үзидарәнең ныклы конституциячел статусы һәм чагыштырмача югары дәрәҗәдә автономиясе һәм карарлар кабул итү мөмкинлеге, шулай ук финанс бәйсезлеге була. Мондый модель алга киткән демократияләрнең иң зур төркеменә хас, Норвегия, Швеция, Дания, Австралия, Германия, Нидерландлар һәм Япония – әнә шундыйлардан. Моннан бигрәк, Көнчыгыш Европа илләре җирле үзидарәне нәкъ шул юнәлештә үстерәләр.

Шулай итеп, демократик дәүләтләрдә җирле үзидарәнең заманча системаларының күбесенә түбәндәге төп үзенчәлекләр хас:

– хакимлек вәкаләтләрен гарантияли торган һәм хакимият органнары буларак урыннарын ачык билгели торган ил конституцияләрендә җирле хакимият органнарының статусын беркетү;

– җәмгыятьләрнең җәмәгать эшләре торышы өчен җаваплылыкны җаваплы җирле ассамблеяләргә яки советларга тапшыруы;

– ассамблеяләрнең һәм советларның административ-территориаль берәмлекләрне артык эре берәмлекләргә берләштерү аркасында җирле җәмгыятьләр белән тыгыз элемтәләрен югалтырга теләмәве;

– җирле үзидарә органнары функцияләренең киң спектры (гомуми билгеләнештәге җирле үзидарә органнары үзләрендәге җәмгыятьләр турында һәр яктан кайгырталар);

– җирле үзидарә органнарының илдәге хөкүмәт һәм административ структураларга нык керешүе, иҗтимагый идарәнең төрле баскычлары арасында үзара бәйлелек һәм аңлашу; җирле хакимият органнарына кызыксынулы барлык яклар белән консультацияләр барышында билгеләнә торган гомуммилли сәясәтне үткәрүчеләр буларак карау тенденциясе;

– җирле хакимиятләрнең үзләренең ассоциацияләре һәм сәяси партияләр аркылы югары баскычтагы органнарга көчле сәяси йогынты ясавы;

– гомуммилли вәкиллекле органнар әгъзаларына (аларның күбесе җирле хакимият органнары белән тыгыз элемтәдә тора, шулай ук күпчелегендә җирле идарәдә зур тәҗрибәләре бар) җирле ярдәм күрсәтелүне күз алдында тоту.

# Барыр ЮЛЛАР



ПРОЕЗД
ОТКРЫТ
ТРАНСПОРТНАЯ
РАЗВЯЗКА км 115
АВТОДОРОГА А-295

# киң булсын



Фото www.tatarstan.ru сайтыннан

Октябрь азагында республикада юл инфраструктурасының күптән көтелгән объектын – Йошкар-Ола – Яшел Үзән автомобиль юлының 115нче километрындагы транспорт чишелешен ачу тантанасы булды. Биредә төзелеш соңгы ике ел дәвамында барды һәм якынча 680 миллион сумга төште. Алга таба бу юл чишелеше 35–40 мең автомобиль хәрәкәтен тәэмин итәргә мөмкин. Тантанада дәрәҗәле кунакларның – Федераль юл агентлыгы җитәкчесе Роман Старовойт, ТР Премьер-министры Илдар Халиков, ТР транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Ленар Сафин, төзелеш оешмалары җитәкчеләренең катнашуы да яңа чишелешнең никадәр мөһим икәнлеген раслый.

Роман Старовойт, юл төзүчеләрне тәбрик итеп: «Бүген юл төзүчеләр өчен чын бәйрәм – Татарстан территориясендә икенче объектны файдалануга тапшырабыз. Әлеге объект республиканың җирле подрядчысы тарафыннан төзелде. Бу чишелешнең федераль юл өчен әһәмияте зур, чөнки түгәрәк ясап хәрәкәт итү уңайсыз, һәлакәт куркынычы да юк түгел, шулай ук вакытны да күп ала иде», – диде.

Илдар Халиков үз чиратында Татарстанда республика өчен генә түгел, бөтен илгә кирәкле юл объектларын төзү мөмкинлеге бирелүе өчен Федераль юл агентлыгы җитәкчесенә рәхмәт әйтте. Шулай ук юл төзүчеләренә дә рәхмәтен җиткерде: «Мин бу участокта төзелешнең барлык этапларында да булдым, теләсә нинди һава шартларында да сезнең тырыш хезмәтегезне күрдем. Бу Татарстан халкы өчен дә, республикабыз аша узып йөрүчеләр өчен дә сөенеч», – диде ул.

Мәгълүмат өчен: Федераль юл агентлыгы җитәкчесе Роман Старовойт журналистларга болай диде: «Татарстан территориясеннән узучы барлык федераль юллар федераль максатчан һәм адреслы инвестицион программаларга кертелгән. Киләсе елда, бюджетны оптимальләштерү буенча чыгарылган карарларга карамастан, файдалануга тапшырылырга тиешле барлык юл объектлары буенча эш алып барылачак. 2016 елда Татарстан территориясендә федераль юллар төзү якынча 6 млрд сумга төшәчәк. Төп юнәлеш – «Волга» М7 юлын реконструкцияләү.



# БАРЫСЫН да кадрлар хәл итә

Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ тексты.
Автор фотолары.

МОННАН БЕР ЕЛ ЭЛЕК ТУГАННАН ТУГАНЫМ АЛДЫНДА: «МӘКТӘПНЕ ТӘМАМЛАГАННАН СОҢ УКУЫН КАЙДА ДӘВАМ ИТӘРГӘ?» – ДИГӘН СОРАУ КИЛЕП БАСКАННАН СОҢ, ЫШАНЫЧЛЫ ЭШ УРЫНЫ ТАБАРГА ҖИҢЕЛ БУЛСЫН ӨЧЕН, МИН АНЫ ӘҮВӘЛЕ, БЕРӘР КОЛЛЕДЖГА ЯКИ ТЕХНИКУМГА КЕРЕП, ЭШЧЕ ҺӨНӘРЕ ҮЗЛӘШТЕРЕРГӘ БИК ОЗАК ҮГЕТЛӘДЕМ. ӘММА УЛ КАЗАННЫҢ БЕР КОММЕРЦИЯЛЕ ВУЗЫНА ӨСТЕНЛЕК БИРДЕ, БҮГЕНГЕ КӨНДӘ ШУНДА ТАМОЖНЯ ЭШЕ СЕРЛӘРЕНӘ ТӨШЕНӘ.

Кызганычка, факт үзгәрешсез кала: югары квалификацияле эшчеләр һәм инженерлар кирәк булган мәлдә, Татарстан абитуриентларының күпчелеге юрист һәм икътисадчы һөнәрен сайлый.

Экспертлар фикеренчә, төбәк хезмәт базарында мондый вазгыять тагын ике ел чамасы саклаearlyачак. Әлеге чорда республикада төрле белгечлекләрдәге 107 мең чамасы эшче кирәк булачак.

### ТЕХНАРЬ ӨЧЕН РЕЗЮМЕ

Бүгенге көндә республикада кадрлар кытлыгы шәһәр хуҗалыгы һәм транспорт, хезмәт күрсәтү, төзелеш һәм агросәнәгать тармаклары предприятиеләрендә һәм оешмаларында кискен тора. Икътисадыбызда төзүче, балта остасы, түбә ябучы, токарь, слесарь, эретеп ябыштыручы, шәһәр электр транспортын йөртүче, электр монтажчысы һәм тракторчыларга ихтыяҗ аеруча зур. ТРның Хезмәт һәм мәшгульлек министрлыгы фаразларына караганда, якындагы елларда урта һөнәри белемлеләр арасында акушерлар, шәфкать туташлары, монтажчылар, юлчылар, тәрбиячеләр һәм башлангыч сыйныф укытучылары, урманчылар, социаль-мәдәни өлкә хезмәткәрләре кирәк булачак. Ә югары белемлеләргә килгәндә, транспорт технологияләре, архитектура һәм дизайн, төзелеш, мәгълүмати иминлек, машина төзү, металлургия тармаклары белгечләре, җылылык энергетикасы һәм җылылык техниклары, педагогик белем сыйфаты белән идарә итүчеләр, дәвалау эше белгечләре җитми. ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Рәзил Вәлиев үзе җитәкләгән комитетның июнь ае башында Алабугада уздырылган күчмә утырышында:

– Соңгы унъеллыкларда эшче һөнәренең дәрәҗәсе төште, моның сәбәпләре күптөрле, – дип сөйләде. – Югары һөнәри белем ягына авышу күзәтелде, түләүлесендә укып булса да, хыялдагы дипломны алу өчен, барысы да вузларга ашкынды. Ә аннан соң шактый күп белгечләр эш таба алмый. Шуның өстенә, әлеге яшьләрнең күбесе урта һөнәри белем алган булса, күптәннән тормышта үз урынын тапкан булыр иде инде. Табигать оста куллы итеп яраткан кешеләр бар бит,

## Абитуриент колагына

**Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, илдәге һәр икенче эшсезнең кулында икътисадчы яки юрист һөнәре буенча вуз дипломы бар.**




Сарман аграр колледжы директорының укыту-тәрбия эшләре буенча урынбасары Николай Сахуриев.



Сарман аграр колледжы студентлары Фирдар Гыйләҗев һәм Руслан Харрасов (сулдан уңга).

**Бүгенге көндә республикада кадрлар кытлыгы шәһәр хуҗалыгы һәм транспорт, хезмәт күрсәтү, төзелеш һәм агросәнәгать тармакларында кискен тора. Икътисадыбызда төзүче, балта остасы, түбә ябучы, токарь, слесарь, эретеп ябыштыручы, шәһәр электр транспортын йөртүче, электр монтажчысы һәм тракторчыларга ихтыяҗ аеруча зур. ТРның Хезмәт һәм мәшгульлек министрлыгы фаразларына караганда, якындагы елларда урта һөнәри белемлеләр арасында акушерлар, шәфкать туташлары, монтажчылар, юлчылар, тәрбиячеләр һәм башлангыч сыйныф укытучылары, урманчылар, социаль-мәдәни өлкә хезмәткәрләре кирәк булачак.**

тормышыбыздагы бик күп нәрсә әлеге осталыктан һәм һөнәрилектән тора.

Республика мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Андрей Поминов әлеге киңәшмәдә бүгенге көндә Татарстанның 82 меңнән артык студентының урта һөнәри белем бирү программасы буенча укуы хакында сөйләде. Әмма экспертлар фикеренчә, бу программалар, еш кына, үзләренә кирәкле белгечне өчәр-дүртәр ел көтәргә әзер булмаган эш бирүчеләр ихтыяҗын җитәрлек дәрәҗәдә канәгатьләндерми. Һөнәри белем бирү системасының сыйфатлы үсешенә җәмгыятьтә шуңа йөз тотарлык анык кыйммәтләрнең булмавы, техникум һәм һТУларның матди-техник базасы ярлылыгы комачаулый. Нәтиҗәдә, яңа гына укып чыккан эшче һәм мастерны эшкә урнаштырганда, кагыйдә буларак, аннан бу елларда нәрсәгә өйрәткәннәрнең барысын да онытуын үтенәләр.

«2014–2020 елларда ТРнда мәгарифне һәм фәнне үстерү»нең былтыр расланган дәүләт программасы әлеге мәсьәләләрне хәл итүне максат итеп куя. Программаның бер өлеше (подпрограммасы) әлеге чорда һөнәри белем бирүне һәм бу өлкәгә караган хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрүне үз эченә ала. Ә ул исә 2020 елга кадәр Татарстанда республика икътисадының әйдәп баручы тармаклары өчен эшче кадрлар әзерләүче, яхшы җиһазланган заманча 25 ресурс үзәге оештыруны, училище һәм техникумнарның матди-техник һәм лабораторияләр базасын яңартуны, һөнәри белем бирүне мәгълүматлаштыруны максат итеп куя. Моннан тыш, методика белән тәэмин ителүнең бердәм системасын формалаштыруны, кадрларның квалификациясен күтәрү һәм составын яңартуны, эшче һөнәрләрен таныту һәм дәрәҗәсен күтәрүне дә күздә тота.

Гамәлдәге һөнәри белем бирү учреждениеләре базасында, тармакның әйдәп баручы эш бирүчеләре белән берлектә, республикада ресурс үзәкләрен оештыру эше башланды инде. Әйтик, былтыр Чаллыда автомобиль төзелеше өлкәсенә караган ресурс үзәге булдырылды. Алабуга политехник колледжы базасында, «Алабуга» МИЗнда гамәли квалификацияләр буенча хезмәт куячак эшче кадрлар һәм белгечләр әзерләүгә тәгаенләнгән күпфункцияле ресурс үзәге барлыкка килде. Казанда Горбунов исемендәге КАҖБнә һәм Казан вертолет заводына кадрлар әзерләүче авиация-техника колледжы әлеге статуска ия булды. Түбән Кама нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы базасында оешкан ресурс үзәге нефть химиясе тармагы предприятиеләре өчен эшче кадрлар әзерләүнең сыйфатын яхшырту белән шөгыльләнә.

## АЛДАГЫ КӨНГӘ ЙӨЗ ТОТЫП УКУ

2014 ел башында Сарман аграр колледжы Татарстан авыл хуҗалыгы комплексы өчен урта звено белгечләре һәм квалификацияле эшчеләр әзерләүче ресурс үзәге статусына ия булды. Республиканың бик күптәнге колледжы бүгенге көндә танымаслык булып үзгәрде. Бирердә 63 миллион сумлык төзекләндерү-үзгәртеп кору эшләре башкарылды, 50 миллион сумлык белем бирү җиһазлары сатып алынды. «Чаллы-Бройлер» компаниясе финанс мөмкинлекләрен кулланып, колледжда кошчылык лабораториясе оештырылды. Моннан тыш, спортны үстерүгә тәгаенләнгән Президент программасы нигезендә, спорт залы төзелешенә 25 миллион сум акча тотылды, моңарчы колледжның спорт залы юк иде.



Сарман аграр колледжына килгәч, студент тормышының башкала университетларында гына түгел, ә авылдагы белем йортында да кайнап тора алуын күрәсең. Ул монда килүчеләрне, беренче чиратта, үзенең мәйданнары белән шаккатыра. Әле күптән түгел биредәге белем бирү процессы берьюлы дүрт җирдә: өчесе – Сарманда, берсе Җәлил бистәсендә алып барыла иде. Бу уку елыннан башлап, Бөгелмә аграр колледжының Мөслим филиалы да сарманлылар канаты астына керде.

Агымдагы елның мартында колледж базасында WorldSkills Russia һөнәри осталык чемпионатының «Тракторчы-механизатор» компетенциясе буенча төбәк сайлап алу туры булып узды, анда Татарстанның 25 районыннан килгән колледж һәм техникум студентлары катнашты. Ә ике айдан соң, республиканың 25 урта һөнәри уку йортында белем алучылар бирегә «һөнәре буенча иң яхшы – 2015» республика олимпиадасына килде. Октябрь ахырында яшь комбайнчылар арасында авыл яшьләренең һөнәри үсешенә, аграр һөнәрләрнең дәрәҗәсен күтәрүгә этәргеч бирүне максат итеп куйган «Хезмәт кешесен данлыйбыз» 7нче республика телевизион бәйгесенең финал туры уздырылды.

Бүгенге көндә Сарман аграр колледжында иң яхшы белем бирү технологияләре кулланыла. Төрле эш коралларының, транспорт чараларының, агрегат узелларының ничек эшләвен тулысынча шуларга охшатып башкаручы интерактив тренажерлар коллективның аерым бер горурлыгы, әлбәттә. Әйтик, менә эретеп ябыштыручының виртуаль тренажеры – «Раскат», «Эретеп ябыштыру остаханәсе» юнәлешендә белем бирүгә тәгаенләнгән электрлаштырылган һәм электр ярдәмендә механикалаштырылган стендлар. Күрше кабинетта «КАМАЗ» двигателенә ягулык бирүче аккумулятор системасына диагностика уздыра торган стенд-тренажер, янәшәсендә – МТЗ-1221 тракторының руле белән идарә итүгә диагноз куючы стенд-тренажер һәм «Cummins» йөк машинасының чын, эшкә яраклы двигателе урнаштырылган. Көтелмәгән кыен хәлләр килеп туганда, «КАМАЗ» автомобилен бәла-казасыз йөртүгә йөз тоткан заманча тренажер турында әйтеп торасы да юк, анда, әйтик, юлда барганда көпчәк тишелү кебек төрле очракларны модельләштереп була.

Колледжның укыту-җитештерү базасы биләмәләрендәге тулысынча үзгәртеп корылган ашлык саклау корылмасы үзенең заманча тышкы күренеше белән игътибарны җәлеп итә. Бу җылы, якты, иркен бинада, авыл хуҗалыгы машиналары һәм кошчылык лабораторияләреннән тыш, практик белем бирү өчен автомобильләргә техник күзәтү үткәрү станциясе, заманча аграр техника залы җиһазланган. Янәшәсендә – юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү өчен автодром һәм трактодром, дистәләгән берәмлек техника һәм күптөрле тагылма агрегатлар сыйдырышлы машина куюрыны.

Сарман аграр колледжы директорының укыту-тәрбия эшләре буенча урынбасары Николай Сахуриев:

– Җиһазлану дәрәҗәсе, укыту программалары һәм технологияләре, белем бирүчеләр составының квалификациясе ягыннан, бүгенге көндә республика агросәнәгать хуҗалыгының бөтен тармаклары өчен замана таләбе дәрәҗәсендәге белгечләр әзерләү стандартларына тулысынча туры киләбез, – дип сөйли. – Безгә 9 һәм 11 сыйныфтан соң укырга керергә була. Ике очракта да абитуриентларга күптөрле белгечлекләр тәкъдим ителә. Без киң профильле тракторчы-машинистлар, авыл хуҗалыгы машиналары техниклары, аш-су әзерләүчеләр, җәмәгать туклануы технологлары, электр монтажчылары, электр-газ белән эретеп ябыштыручылар, ЭВМ операторлары, B, C, D һәм E категорияләрендәге машина йөртүчеләр, экскаваторчылар, бульдозерчылар әзерлибез. Бюджет урыннарыннан тыш, түләүле кечке курслар да тәкъдим итәбез.

Бүгенге көндә колледжның 27 төркемендә Сарман, Азнакай, Әлмәт, Әгерҗе, Зәй, Тукай, Мөслим районнарыннан, Чаллыдан килгән 598 студент эшче һөнәрләренең нигезен үзләштерә. Уку йортын тәмамлап чыгучылар арасында эшкә урнашу җәһәтеннән авырлык тумый, чөнки алган белемнәре гамәли яктан да ныгытыла. Колледжның 800 гектардан артык мәйданда үз тәҗрибә участогы бар, анда ел саен бөртеклеләрдән шактый мул уңыш җыела. Колледжда укучылар анда җитештерү практикасы үтә, шуның өстенә, җәйге каникулларда республиканың авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә һәм фермерлык хуҗалыкларында беркадәр акча эшләп алалар, укуны тәмамлап чыккач, Сарман һәм башка районнарның агрофирмаларына эшкә урнашу мөмкинлегенә ия булалар.

– Шунысы куанычлы: безнең уку йортын тәмамлаучылар эш эзләп интекми, – ди Николай Иванович. – Моннан тыш, теләге булганнар, нибары бер имтихан биреп, кыскартылган программалар буенча укуларын Казан дәүләт аграр университетында дәвам итә ала. Шуның өстенә, бюджет нигезендә, киләчәктә эш бирүчедән һәм ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан саллы стипендияләр алып укыйлар.

Яңа танышларым Фирдар Гыйләҗев белән Руслан Харрасов, 2016 елда колледжны тәмамлаганнан соң, КДАХУна керергә ниятлиләр. Бүгенге көндә бу егетләр икенче һөнәр үзләштерә, моңарчы тракторчы-машинист дипломын алган булсалар, хәзер техник-механиклыкка укыйлар.

– Лабораторияләрдә техник стендлар урнаштырылганнан соң, белем алуы күпкә уңайлырак һәм кызыклырак, – дип сөйли Сарман районының Иске Имән авылында туып-үскән Руслан Харрасов. – Әйтик, менә гидравли-





Сарман аграр колледжындагы уку стенд-тренажерлары.

ка стендында кырык дүрт төрле лаборатор эш башкарып була. Стенд безгә, техниканың үзен кулланмыйча гына, тикшереп карау мөмкинлеген тудыра. Бу – кичәге көн түгел инде, ә яңа, заманча технологияләр.

Руслан үзенең туган авылындагы «Нөркәй» агрофирмасында бүгеннән үк кирәкле хезмәткәр. Комбайнчы ярдәмчесе буларак, ике еллык эш тәҗрибәсе бар инде аның. Быел бу хуҗалыкта егеткә әүвәле «Нью-Холланд» ашлык уру комбайнын ышанып тапшыралар, ә ул анда 20 мең центнер иген суктырып алган, студентның тырышлыгын, заманча яңа техника белән кызыксынуын һәм аны әйбәт белүен чамалап алгач, аны өр-яңа Challenger тракторына күчереп утырткannar. Әмма егет монда да сынатмаган. Аның өчен җирдә хезмәт кую күңеленә якын шөгыль, яраткан эш бит. Ә аннан беркайчан да туймыйсың, ул көч бирә, тормышны максатчан, тулыканлы һәм гармонияле итә.

## ЭШЧЕ КУЛЛАР ОЛИМПИАДАСЫ

Быел, моңарчы тиңе булмаган укыту-методик, кадрлар һәм матди-техник мөмкинлекләр бергә тупланган, заманча җитештерү технологияләренә, югары квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр әзерләүгә йөз тоткан шуңа охшашлы белем бирү учреждениеләре республиканың тагын берничә муниципаль берәмлегендә пәйда булачак. Киләчәктә әлеге ресурс үзәкләре бер үк вакытта кыска программалар буенча квалификацияле эшчеләр әзерләүче гамәли квалификация үзәкләре дә булып хезмәт итәр, дип планлаштыралар.

Шуның белән бәррәттән, узган елдан башлап, республикада һөнәри юнәлеш бирү эшен яңартырга-камилләштерергә, бердәм һөнәри киңлек тудырырга керештеләр. Моннан тыш, республикада һөнәри юнәлеш бирүнең нәтиҗәле үрнәкләре банкын булдыру максатыннан, һөнәри юнәлеш бирүдә үз моделен барлыкка китерүче муниципаль районнар һәм мәгариф оешмалары өчен грант булдырылды. Әлеге максатларга 20 миллион сум бүлеп бирү каралган.

2014 елда, республикада беренчеләрдән булып, Түбән Камада мәктәп укучылары арасында хезмәт кешесенең дәрәҗәсен күтәрүгә йөз тоткан үз муниципаль программаларын гамәлгә ашырырга керештеләр. «Һөнәргә керәш» дип аталган проект 9 сыйныф укучыларына тәгаенләнгән. Бары тик быел гына да анда 1,5 мең үсмер катнашачак. Проектның беренче этабында укучылар, Түбән Каманың урта махсус һөнәри уку йортларында булып, киләчәктә үзләре үзләштерергә теләгән һөнәрләрен ачыкладылар. Икенче этапта, өч ай дәвамында, атнасына өч мәртәбә колледжга йөреп, үзләре сайлаган белгечлекне үзләштерәчәкләр. Һөнәри белем алудан соң, укучыларга аерым бер квалификацияне үзләштерүләре хакында таныклык тапшырылачак, ә алган белемнәре уку йортына авырлыксыз гына керергә ярдәм итәчәк.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: соңгы арада республиканың кайбер эре предприятиеләре дә укучылар арасында һөнәри юнәлеш бирү эшен актив рәвештә җәелдерде. Яшел Үзәндәге «ПОЗИС» АҖ эшчәнлеге – моның ачык мисалы: ул 2012 елдан башлап мәктәп балалары өчен уникаль проект – «Киләчәк инженерлары» дигән махсус машина төзелеше класслары оештырды һәм аңа ярдәм итә. Проектта Татарстан һәм Мари Эл мәктәп һәм лицейларының 11сыйныф укучылары катнаша. «Киләчәк инженерлары» Россия яшьләре арасында техник белемнәрне актуальләштерүгә һәм абруен күтәрүгә юнәлдерелгән. Бу класслар кысаларында 10–11сыйныфта укучыларны техник һәм башка фәннәр буенча бердәм дәүләт имтиханнарына өстәмә рәвештә әзерләү дә гамәлгә ашырыла. Әлеге бушлай укытылучы курслар математика, физика, сызым геометриясе, инженерлык һәм компьютер графикасы фәннәре буенча тирәнәйтелгән белем бирә. Шул ук вакытта машина төзелеше классларында укучылар компания алдында берничек тә бурычлы булып калмый, проект әлеге җәһәттән үзенә өстәмә кызыксыну арттыра. Бүгенге көн статистикасыннан күренгәнчә, әлеге классларны тәмамлаучыларның яртысыннан артыгы илебезнең техник вузларына укырга керә.

2019 елда Казанда уздырылачак World Skills Competition дөньякүләм һөнәри осталык чемпионаты татарстанлыларның эшче белгечлекләренә игътибарын арттырырга һәм бүген хезмәт куючы эшчеләрнең квалификациясен күтәрергә ярдәм итәргә тиеш. Эшче куллар Олимпиадасы World Skills International халыкара хәрәкәте тарафыннан оештырыла, Татарстан аңа моннан ике ел элек кушылган иде һәм ул шуның иң актив әгъзаларының берсе. Быел май ае ахырында Казанда WorldSkills стандартлары буенча III Милли һөнәри осталык чемпионаты булып узды. Татарстан җыелма командасы, узган елдагы кебек, быел да ярышларның гомумкоманда исәбендә беренче урынны яулады. Финалда Россиянең 46 төбәгеннән һәм 5 биш чит илдән: Марокко, Израиль, Финляндия, Белоруссия, Казахстаннан 519 конкурсант катнашты. «Казан ярминкәсе» күргәзмәләр үзәге биләмәләрендә оештырылган бәйге мәйданчыкларында 57 компетенция буенча көч сынаштылар, шуларның 42се – төп, 15е тәкъдим итү рәвешендә иде.

Республика гомумбелем мәктәпләренең 7–10 сыйныф укучылары арасында һөнәрләргә багышлап уздырылган «Киләчәккә билет» иншалар бәйгесенең нәтиҗәләре шушы арада билгеле булачак. Бәйге «Хезмәт кешесе. Һөнәрем – карьерам», «Хезмәт династиясе», шигырь рәвешендә язылган «Киләчәк һөнәре» номинацияләре буенча сентябрь аенда башланып китте.





Быел май ае ахырында Казанда WorldSkills стандартлары буенча III Милли һөнәри осталык чемпионаты булып узды.

# Туган йорт ишекләре һәрчак ачык



Ноябрь башында ТР Дәүләт Советы Рәисе, ТР Президенты каршындагы Ватандашлар эшләре буенча республика координация советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин V Бөтендөнья ватандашлар конгрессы ачылышында чыгыш ясады. Конгрессны РФ чит ил эшләре министры Сергей Лавров ачты. Форумда катнашучыларга мөрәҗәгать итеп, ул Ватандашлар эшләре буенча хөкүмәт комиссиясенең рус халкының гына түгел, татар, яһүд һәм Россиядә яшәүче башка халыкларның да гореф-гадәтләрен саклауга даими игътибар күрсәтүен әйтте: «Аерым алганда, Россиядәге һәм чит илләрдәге күп миллионлы татар җәмгыятьләре вәкилләрен берләштерүче Бөтендөнья татар конгрессы белән бергә, Бөекбританиядә Европа Сабан туен үткәрү планлаштырыла. Хөкүмәт комиссиясе ярдәме белән «Европа татарлары альянсы» оештырылды, аның икенче утырышы узган айны Парижда үтте. Киләсе елга Казанда инде җиденче тапкыр Татар яшьләренең бөтендөнья форумы уздырылачак».

РФ ФҖ Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенко да Татарстанның ролен аерым билгеләп үтәргә онытмады. Аның әйтүенчә, күп кенә төбәкләрдә чит ил диаспоралары белән ныклы элемтә урнаштырылган – монда сүз гуманитар хезмәттәшлек турында да, кыен хәлдә калган ватандашларга ярдәм итү турында да бара. Бу юнәлештә Мәскәү һәм Санкт-Петербург, Татарстан Республикасы, Башкортостан Республикасы, Якутия һәм башка төбәкләр аеруча зур тырышлык куя.

Үзенең чыгышында Фәрит Мөхәммәтшин Татарстанның ватандашлар белән үзара элемтәләрне ныгыту буенча алып бара торган эше турында сөйләде. Ул бөтен дөньяга таралган 7,5 миллион татар халкының бары тик 2 миллионнан артыгы гына Татарстанда яшәвен ассызыклады. Республикабыздан читтә яшәүче татарларның күбесе тарихи ватаннары белән рухи һәм мәдәни элемтәләрне югалтмаска тырыша, дип билгеләп үтте.

Татарстан парламенты башлыгы якын араларда яңа Иннополис шәһәре базасында инновацияләр, фән, югары технологияләр белән шөгыльләнүче ватандашларның Бөтендөнья фәнни-гамәли конференциясен үткәрү мөмкинлеге турындагы тәкъдимен кертте – анда катнашучылар алга таба Россия төбәкләренең инновацион үсеше юллары турында сөйләшә алырлар иде. «Татарстанда төрле министрлыклар һәм ведомстволарның үзара хезмәттәшлеге ярдәмендә тупланган ватандашлар белән эшләү тәҗрибәсен Россия Федерациясенең башка субъектларында да файдаланырга мөмкин», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Көннең икенче яртысында конгресста катнашучылар алдында РФ Президенты Владимир Путин чыгыш ясады. «Ватандашлар белән элемтәне ныгыту өлкәсендәге кызыклы проектларны төрле төбәкләр тормышка ашыра, алар үзләренә эшкуарларны, фән, мәдәният өлкәсе вәкилләрен, яшьләрне җәлеп итә», – диде ул һәм Казанда Татар яшьләренең бөтендөнья форумын үткәрү практикасын бер мисал итеп китерде.

Динә Аляутдинова фотосы





Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ тексты.
Фотолар автордан, һәм шулай ук «Татмелиоводхоз» Идарәсе» ФДБУнән алынды.

# КЫРДАГЫ *һава торышы*

КЛИМАТ КӨЙСЕЗЛЕКЛӘРЕ ТАТАРСТАН ӨЧЕН ТОРГАН САЕН ЕШРАК ТАБИГАТЬ ХӘВЕФЛӘРЕНӘ ӘЙЛӘНӘ, Ә КОРЫ ҖӘЙ ИГЕНЧЕЛӘРЕБЕЗ ӨЧЕН ИНДЕ АНОМАЛИЯ ТҮГЕЛ, БӘЛКИ ЗАКОНЧАЛЫК КЕБЕК. АГЫМДАГЫ ЕЛДА, МӘСӘЛӘН, КОРЫ ҖИЛ, АТМОСФЕРА ҺӘМ ТУФРАКТАГЫ КОРЫЛЫК РЕСПУБЛИКАНЫҢ 27 МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘГЕ БАСУЛАРНЫ АЯМАДЫ.

Нәтиҗә буларак, Татарстанда бөртеклеләрнең тулаем җыемы 3,5 миллион тоннаны тәшкил итте, уңай килгән елларда исә бу күрсәткеч 5 һәм тагын да күбрәк миллион тоннага җитә иде, агросәнәгать комплексы бөртеклеләр буенча гына да якынча 10 миллиард сумны алып бетермәде. Авыл хезмәтчәннәренең быелгы сезонда корылык аркасындагы гомуми югалтулары, республика Авыл хуҗалыгы министрлыгы белгечләре бәяләмәләренә караганда, якынча 20 миллиард сумны тәшкил итәчәк.

Өстәвенә, аграрийларга чыгымнарны турыдан-туры беркем дә капларга җыенмый. ТР вице-премьеры – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов фикеренчә, Россия агроиминиятләштерү системасына артык өметләр багларга да ярамый. Әлеге моментка Татарстанда чәчүлек мәйданнарының 45 проценты иминиятләштерелгән булуына да карамастан, авыл хуҗалыгы предприятиесенең берсенә дә иминият очрагы буенча тиешле акчалар түләнмәде.

## ДЫМ ФАКТОРЫ

Марат Әхмәтов сүзләренә караганда, агробизнеста калырга гына түгел, бәлки алга таба үсәргә җыенганнар өчен сугару системаларын куллану котылу чарасына әвереләчәк.

Сугарулы җирләрне үстерүнең стратегик әһәмиятен элек тә яхшы аңлаганнар. Гидромелиорациянең чәчәк аткан елларында (1980–1990 еллар) Татарстандагы магистраль һәм бүлү торбаүткәргечләренең озынлыгы – 3,5 мең километрны, сугару каналлары 250 километрны тәшкил иткән, 360 капиталь буа төзелгән, 3 мең насос станциясе эшләгән, алар 250 мең гектардагы авыл хуҗалыгы җирләрен су белән тәэмин иткән.

Үзгәртеп кору һәм аннан соңгы еллардагы икътисадның җимерелүен мелиораторлар аянычлы хисләр белән искә төшерәләр. Нәкъ шул вакытта сугару эшләренең күләме шактый кимегән

**40,6 миллиард сум** **Татарстанда 2006 елдан 2014 елга кадәр мелиорациягә, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне һәм агроландшафтларны саклау һәм торгызуга тиешле федераль һәм республика программалары кысаларында инвестицияләнгән. Күрсәтелгән чыгымнарның өчтән ике өлешен төбәк һәм җирле авыл хуҗалыгы бюджетлары тәшкил иткән.**

# ДӨНЬЯДАН КАЛЫШАБЫЗ

**Сугарулы җирләр, млн га**

| | |
|---|---|
| Кытай | 65 |
| Һиндстан | 60 |
| АКШ | 22 |
| Россия | 4,3 |

**Чыганак: Водстрой**

# СУГАРУ ФАРАЗЫ

**2020 елга җирләрне сугаруга кертү, мең га**

| | |
|---|---|
| Үзәк | 40 |
| Төньяк-Көнбатыш | 1,2 |
| Идел буе | 207 |
| Көньяк | 73 |
| Төньяк Кавказ | 70 |
| Ерак Көнчыгыш | 8,2 |
| Себер | 53 |
| Урал | 14,3 |

**Чыганак: Авыл хуҗалыгы министрлыгы**



Соңгы өч елда Татарстанда 226 буа һәм гидрокорылма реконструкцияләнгән.



бит, бу тармакны финанслауның кыскартылуына яисә аның бөтенләй булмавына бәйле иде. Нәтиҗәсе буларак сугарулы җирләрнең халәте һәм гидротехник корылмаларның торышы кинәт начарайды, алар кулланышка яраксыз әйләнде, ә кырдагы сугару җайланмалары сүтелеп ташылып бетерелде.

Хәзерге вакытта Татарстанның мелиорация системасы икенче яңарышын кичерә. 2010 елгы гадәттән тыш корылыктан соң, шактый кыска вакыт аралыгында «2011–2012 елларда Татарстан Республикасында мелиорация комплексын модернизацияләү һәм энергетик нәтиҗәле технологик яңарыш» республика программасы уңышлы гамәлгә ашырылды. Нәтиҗәдә кырларда 240 замanча яңгыр яудыру машинасы һәм 169 насос станциясе эшли башлады, 140 километрдан артык магистраль суүткәргеч торба сузылды. Бу 10 мең гектардан артык сугарулы җирне торгызырга һәм, шулай итеп, республиканың бәрәңгегә һәм яшелчәләргә булган ихтыяҗын тулысынча тәэмин итәргә мөмкинлек бирде.

«Татмелиорация» траст компаниясенең генераль директоры Әнвәр Залаков хәбәр иткәнчә, бүген республикада «2012–2017 елларга Татарстан Республикасында гидротехник корылмаларны торгызу буенча мелиорация эшләре» төбәк максатчан программасы уңышлы тормышка ашырыла, аның кысаларында 300 дән артык плотинаны торгызу күз уңында тотыла. Агымдагы елда 172 мелиорация объектында төзелеш һәм ремонт-торгызу эшләре алып барыла, аларның 70 проценты инде кулланышка тапшырылган. Ел ахырына өч мең гектарга кадәр сугарулы җирне авыл хуҗалыгы әйләнешенә кертү планлаштырыла.

– Бөтен дөньяда сугарулы җирләр авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдәге тотрыклылыкның төп факторларының берсе һәм азык-төлек куркынычсызлыгының нигезе булып тора, – дип сөйли «Татмелиоводхоз» Идарәсе» ФДБУ директоры Марс Хисмәтуллин. – Татарстан мелиорацияне үстерү буенча Россиянең иң алдынгы төбәкләренең берсе санала. «2014–2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә мелиорацияне үстерү» федераль максатчан программасы кысаларында бездә шундый ук төбәк максатчан программасы эшләнде һәм гамәлгә ашырыла. Ул 2020 елга 35 мең гектардагы сугарулы җирне кулланышка кертүне күз уңында тота.

Моның өчен федераль казна биргән 1 сумга республика үз бюджетыннан 5 сум һәм бюджеттан тыш чыганаклардан 7 сум җәлеп итә. Нәтиҗә күренеп тора – соңгы өч елда Татарстанда 20 мең гектардан артык сугарулы җир торгызылган, 226 буа һәм гидрокорылма реконструкцияләнгән. Узган елны 7,3 мең гектардан артык сугарулы җир кулланышка кертелгән, 152 мелиорация объекты төзелгән һәм реконструкцияләнгән, шул исәптән 70 тән артык плотина һәм буа.

Мәсәлән, бер Кайбыч районында гына да Татарстан мелиораторлары көче белән югарыда аталган вакыт эчендә җиде буа һәм гидротехник корылма ремонтланган, 200 гектардан артык сугарулы җир әйләнешкә кертелгән. Шуның 128 гектары җирле «Подберезье» агрофирмасы өлешенә туры килә, әлеге агрофирма агымдагы елда шактый зур бәрәңге уңышы җыеп алган: гектарыннан 250 центнер. Сугарулы җирләрнең су белән тәэмин ителешен арттыру өчен, авыл хуҗалыгы предприятиесе тагын бер буа төзелешен тәгәлләп килә.

### КОРЫЛЫКТАН КОТЫЛУ

Республикада гына түгел, бөтен ил күләмендә сугару эшләренә әре акчалар инвестицияләүче иң яхшы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең берсе – Алабуга районының ««Нократ таңнары» Агрофирмасы» ҖЧҖ.

Соңгы өч елда хуҗалык тарафыннан 800 гектардан артык сугарулы җир кулланышка кертелгән, шуларның 550 гектарында бәрәңге, кәбестә, чөгендер, кишер үстерелә. Быел әлеге авыл хуҗалыгы предприятиесендә инде 20 мең тоннадан артык яшелчә җыеп алынган. «Нократ таңнары» агрофирмасы директоры Сергей Полынкин сүзләренә караганда, даими сугару аркасында корылык яшелчә уңышына йогынты ясамаган диярлек. Эшчәнлекләрендә мелиорация буенча федераль максатчан программа зур ярдәм булган, аның булышлыгы белән агрофирма яңа сиптерү җайланмалары һәм башка кирәкле җиһазлар сатып ала алган.

Киләсе елга сугарулы җир мәйданнарын бирeдә тагын 860 гектарга арт-



«Татмелиоводхоз» Идарәсе» ФДБУ директоры Марс Хисмәтуллин, сугарулы җирләрдә җиләк-җимеш һәм яшелчәләрдән генә түгел, бөртекле культуралардан да мул уңыш алып була, дип саный.



«Бөреле» ЯАҖ генераль директоры Алмаз Миңнекәев фикеренчә, шактый зур өстәмә уңыш рәвешендә кире кайткан чыгымнар үзләрен аклый.



«Хузангай» ҖЧҖ җитәкчесе Евгений Чугунов сүзләренә караганда, хуҗалыкта сугаруның заманча системаларын кертүне тормыш үзе таләп иткән – быелгы эсселек бөтен икмәкне яндырган.




тырырга һәм яшелчәләрнең тулаем җыемын 35 мең тоннага кадәр җиткерергә планлаштыралар. Шулай ук өч буа төзү ниятләнелә, алар сугару өчен су чыганагы булып торачак. Мәсьәләнең бәясе аз түгел – 120 миллион сум, ләкин эшләр төгәлләнгәннән соң чыгымнарның яртысы федераль казна тарафыннан кайтарылачак.

Шунысы да мөһим: яңа мәйданнар республикада җитештерелгән яңгыр яудыру машиналары белән тәэмин ителәчәк. Күптән түгел генә Биектауда сугару техникасын җитештерү заводы төзелеше башланды. Яңа предприятиене киләсе елны язын кулланышка тапшыру планлаштырыла һәм инде киләсе сезонга монда беренче 20–25 яңгыр яудыру машинасын ясап чыгарырга тиешләр, алар читтән кертелгән аналогларыннан бәяләрымга арзанрак булырга тиеш.

«Нократ таңнары» Агрофирмасы яшелчәләрне беренчел эшкәртү һәм саклау буенча алга киткән инфраструктурага ия. Ике ел эчендә предприятиедә 8500 тонналык ике бәрәңге саклау урыны төзелгән, кишер (2000 тонналык) һәм кәбестә (2200 тонналык) саклау өчен суыткычлар урнаштырылган. һәм шулай ук монда җәен яшелчәләрне сату өчен җитештерү цехы да бар. Тәрелгән һәм юылган яшелчәләргә ихтыяҗның торган саен үсә баруын, ә җирле продукциянең Кама аръягындагы кибетләрнең барысында да диярлек сатылуын исәпкә алып, быел хуҗалыкта бәрәңге һәм кишер тәрү буенча яңа линияләр эшләтеп җибәргәннәр. Җиһазларга кертелгән инвестицияләрнең гомуми күләме 130 миллион сумнан артып киткән, шул исәптән 50 миллион сумын агрофирманың үз акчалары тәшкил иткән, 80 миллион сумы – «Россельхозбанк» кредиты.

2016–2017 елларда агрофирмада кишер һәм кәбестә саклау өчен гомуми сыйдырышлылыгы 6500 тонна булган тагын бер суыткыч, һәм шулай ук 4000 тонналык бәрәңге саклагычы куярга ниятлиләр.

«Нократ таңнары» ҖЧҖнең сугарулы җирләрне үстерү өлкәсендәге уңышлары күптән түгел генә Мәскәүдә уздырылган «Алтын көз» Бөтенроссия агросәнәгать күргәзмәсендә лаеклы бәяләнгән: агрофирма «Мелиорацияне үстерүдә югары күрсәткечләргә ирешкән өчен» тармак конкурсында «Мелиорациягә инвестицияләр кертүче иң яхшы авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүче» номинациясендә көмеш медальгә лаек булган. Конкурс Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгының Мелиорация департаменты башлангычы белән икенче ел рәттән күргәзмә кысаларында уздырыла.

## ЮГАРЫ УҢЫШ ГАРАНТЫ

Республиканың башка муниципаль берәмлекләрендә дә, табигать шартларына ышанып тормыйча, ясалма сугару ярдәмендә продукция җитештерергә тырышалар. Мисал өчен, Арча районында да мелиорация аркасында бүген кайчандыр онытылган авыл хуҗалыгы культураларын игү эше торгызыла. Алар арасында – суган, кәбестә, аш чөгендере һәм кишер. Мелиорацияне үстерүнең федераль һәм республика программалары аркасында соңгы ике елда районда сугару мәйданнары 1300 гектардан артык җирдә барлыкка килә. Әлеге максатларда 19,2 километрга сузылган магистраль торбалар салына, 17 комплект заманча яңгыр яудыру машинасы сатып алына һәм урнаштырыла, 12 насос станциясе, өч яңа сулык төзелә һәм икесе ремонтлана.

Бүген Арча төбәгендә мелиорация өлкәсендә «Кырлай» агрофирмасы (хуҗалыкның инвесторы – «Сервис Агро» ҖЧҖ) лидер булып тора. 2014 елда сугарулы кырларда җирле яшелчәчеләр бер




әйләнәгә 450 центнердан алып 650 центнерга кадәр бәрәңге җыеп ала. «Сервис Агро» җитәкчесе Габделхәй Кәримов сүзләренә караганда, ясалма сугарусыз әлеге күрсәткечләр өч тапкырга түбәнрәк булыр иде: хәтта иң уңай килгән җәйге чорда да бәрәңге уңышы гектарыннан 150–160 центнердан артып китми. Шуңа күрә быел хуҗалыкта «икенче икмәк» өчен сугарулы җир мәйданын өчтән бергә арттырып, 930 гектарга җиткерәләр: өстәмә 330 гектар җир гидротехник корылмалы яңа плотина төзелгән Үтнә елгасына якын урнашкан.

Агрофирмада бәрәңгедән тыш шикәр һәм аш чөгендере, кишер игәләр. Әлеге яшелчәләр ел саен җирле игенчеләрне яхшы уңышлар белән куандыралар. Әйтик, узган елны гына биредә сугарулы җирләрнең һәр гектарыннан 800әр центнер баллы тамыразык, 250шәр центнер аш чөгендере һәм 500әр центнер кишер алына.

Агрофирманың үз бәрәңге һәм яшелчә саклагычы бар, аның сыйдырышлылыгы 12 мең тонна. Перспективада авыл хуҗалыгы предприятиесе сугару җирләрен киңәйтергә планлаштыра, һәм бүген үк биредә яшелчәләрне эшкәртү буенча яңа цех төзелеше бара.

Мелиорация белән җитди шөгыльләнә торган республика хуҗалыклары арасында шулай ук Арча районының «Сигнал» агрофирмасын, Алексеевск районының Гомәров КФХ, Әлкидән Тяминов КФХ, Лаештан «Хәерби» ҖЧҖ һәм Түбән Кама районыннан «Якташлар» КХ атап була.

Сугарулы җирләрнең өстенлекләре турында Биектау районының «Бөреле» ЯАҖндә дә яхшы беләләр. Хуҗалыкның мелиорация комплексы үз эченә ун «Фрегат» яңгыр яудыру машинасын, өч «Bauer» яңгыр яудыру машинасын, дүрт барабан тибындагы яңгыр яудыру машинасын, тугыз насос станциясен, гомуми озынлыгы 15 чакрымга сузылган торбаларны һәм өч сулыкны ала.

«Бөреле» ЯАҖ генераль директоры Алмаз Миңнекәев сүзләренә караганда, хуҗалыкта мелиорация сорауларына соңгы дүрт елда аерым игътибар күрсәтә башлаганнар. Бу вакыт эчендә үз мелиорация системасын реконструкцияләүгә предприятие 13 миллион сумнан артык акча сарыф иткән. Бу сугарулы җирләрнең мәйданын 376 гектардан 576 гектарга кадәр киңәйтергә, һәм шулай ук су сиптерү агрегатларының җитештерүчәнлеген өч мәртәбәгә арттырырга мөмкинлек биргән. Шул ук вакытта сугару аркасында ирешелгән еллык чыгымнар экономиясе 3 миллион сумга якын.

– Соңгы еллардагы корылык республикада сугарудан башка яшелчә культураларын үстерү кыен булачак дип өйрәтә, – дип искәртә Алмаз Габдуллаҗанович. – Миллионлаган сумнарга техника яки орлык сатып алырга (быел гына да «Бөреле» ЯАҖ яшелчә орлыкларын сатып алуга 3 миллион сум акча тотыла. – Авт.), югары квалификацияле белгечләр ялларга була, әмма, әгәр үсемлекләр вегетация чорында тиешле күләмдәге дым алып өлгермәсә, яхшы уңышка исәп тотып булмый. Әйе, мелиорация – арзан гамәл түгел, һәм бөтен хуҗалыкларның һәм фермерларның акча янчыгы җитеп бетми. Ләкин шактый зур өстәмә уңыш рәвешендә кире кайткан чыгымнар үзләрен аклый. Өстәвенә, дәүләт авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең сугару системаларын төзү һәм яңартуга киткән чыгымнарының шактый өлешен субсидияли.

Хуҗалыкта ясалма сугару ярдәмендә бәрәңге орлыгы җитештерәләр. Быел бер әйләнәгә 250 центнердан алып 400 центнерга кадәр бәрәңге алалар, һәм шулай ук кәбестә, аш чөгендере һәм кишер җыела. Кишернең уртача уңышы гектарыннан 500 центнердан артыкны тәшкил итә.

Быел «Бөреле»дә кәбестә дә уңа. Әлеге культура өчен хуҗалыкта 60 гектар сугару мәйданы бирелә. Хуҗалыкның яшелчәчелек буенча баш агрономы Рушан Кәримов сүзләре буенча, кәбестәнең иң беренче уңышы кибет киштәләренә инде июль башында ук озатылган. Кәбестәнең озак сакланырга тиешле соң өлгерә торган сортлары бик яхшы уңыш бирә.

Сүз уңаеннан, Татарстанда ясалма сугару ярдәмендә җиләк-җимеш һәм яшелчәләр генә түгел, бөртекле культуралар да игелә. Әйтик, Әлки районының «Хузангай» ҖЧҖндә бөртеклеләрне сугару технологиясе буенча кукуруз үстерелә. Әгәр узган елны яңгыр сиптерү 120 гектарда кулланылса, быелгы сезонда әлеге мәйдан алты мәртәбәгә арттырыла. Барлыгы үз сугару системасын үстерүгә биредә инде 40 миллион сумга кадәр акча салына. Россия программасына ярашлы рәвештә, хузангайлыларга әлеге сумманың яртысы субсидия сыйфатында кире кайтарыла.

Авыл хуҗалыгы предприятиесе җитәкчесе Евгений Чугунов аңлатканча, хуҗалыкта сугаруның заманча системаларын кертүне тормыш үзе таләп итә – быелның июнь һәм июль айларындагы эсселек хузангайлылар утырткан бөтен икмәкне яндырган. Үсемлекләргә яфрак тукландыруы кертү дә артык булышмый. Шуңа күрә биредә кукуруз һәм көнбагыш плантацияләренә зур өметләр баглыйлар.

– Кукуруз – су сиптерүне ярата һәм сугарган очракта һәр гектардан 80 центнердан да ким булмаган күләмдә уңыш алырга мөмкин, – ди Евгений Михайлович. – Су сиптермәгән очракта бу күрсәткеч ике тапкырга ким булачак. Иң якынча исәпләүләргә караганда да, кукурузның тулаем җыемы 50 мең тоннадан да түбән булмаска тиеш. Безгә көнбагыш та булышыр дип уйлыйм, гектарыннан 25 центнердан да ким булмаган уңыш алырга ниятлибез. Иң мөһиме – вакытында һәм югалтуларсыз җыеп алу.

Шушы көннәрдә генә 600 баш савым сыерына исәпләнгән эре терлекчелек комплексы куллануга тапшырылачак хуҗалыкта алга таба әлеге техник культураларга чәчүлек мәйданнарының иң зур өлешен бирергә планлаштыралар, бөртеклеләрне бары тик чәчү әйләнешен саклау өчен генә калдырырга уйлыйлар. Евгений Чугунов сүзләренә караганда, әлеге чара авыл хуҗалыгы предприятиесенә рентабельлелеген саклап калырга, һәм шулай ук, өлешчә генә булса да, сөрүлекләр кытлыгы проблемасын чишәргә ярдәм итәчәк. «Хузангай» ҖЧҖнә бүгенге көндә, ким дигәндә, өстәмә рәвештә 15 мең гектар җир таләп ителә.



Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ тексты.
Автор фотолары.

# ШӘХСИ хуҗалыкта – дәүләт мәнфәгате

РОССИЯДӘ ШӘХСИ ЯРДӘМЧЕ ХУҖАЛЫКЛАРДАГЫ ТЕРЛЕКЛӘРНЕҢ ҺӘМ КОШ-КОРТЛАРНЫҢ БАШ САНЫН КРЕСТЬЯННЫҢ МАЛ АСРЫЙ ТОРГАН ҖИР МӘЙДАНЫНА «БЕРКЕТЕП» КУЯ ТОРГАН НОРМАНЫ ЗАКОН БЕЛӘН НЫГЫТЫРГА МӨМКИННӘР. УЛ ОЧРАКТА АВЫЛ ХАЛКЫ ЙОРТ ХАЙВАННАРЫН САНИТАРИЯ КАГЫЙДӘЛӘРЕНӘ КАРШЫ КИЛӘ ТОРГАН ШАРТЛАРДА ТОТА АЛМАЯЧАК, ДИП ЫШАНДЫРА ЧИНОВНИКЛАР. ШӘХСИ ХУҖАЛЫКЛАРДАГЫ ТЕРЛЕКЛӘР САНЫН ЧИКЛӘҮНЕ ТӨБӘКЛӘР КАРАМАГЫНА ТАПШЫРУ ТУРЫНДАГЫ ЗАКОН ПРОЕКТЫ РОССИЯ ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫНА КЕРТЕЛДЕ ИНДЕ.

Аның инициаторлары – Ставрополь крае парламентарийлары. Документ авторлары кайбер хуҗалыкларның үзләренең күпмедер җирләрендә эре товарлыклы производство җәелдерүләре (600ләп дуңгыз, 100ләп сарык, 2000 баш кош асраулары) хакында белдерә. Җир һәм милек өчен салымны дача тотучылар кадәр генә түләгәнгә, шәхси ярдәмче хуҗалыклар эшчәнлегеннән бюджетка бернинди дә файда юк диярлек, ә менә аларның күршеләре санитария кагыйдәләре үтәлмәвеннән, чүпчардан һәм яман истән интегә.

Шәхси хуҗалыкларга бәя бирү өчен төгәл критерийлар эшләү һәм «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында»гы Федераль законга тиешле үзгәрешләр кертү кирәклеге турында Россия Хөкүмәтендә август башында узган селектор киңәшмәсендә Ставрополье губернаторы Владимир Владимиров белдерде. Алай гына да түгел, Россиянең көньягындагы эре терлекчелек регионнарының берсенең башлыгы хуҗалыклар асрый торган мөгезле эре терлекләрнең саны биш баштан, сарыклар саны егермедән артмаска тиеш, дигән фикер әйтте.

Экспертларның бер өлеше мондый тәкъдим белән килешми, чөнки, бер яктан, бүген шәхси хуҗалыклар авыл халкының күпчелеге өчен бердәнбер табыш чыганагы булып тора, икенчедән, хәзергә илдә импортны алыштыру һәм Россия базарын үз продукциябез белән тәэмин итү проблемасы хәл ителмәгән әле. Бу мәсьәләне

**Экспертларның бер өлеше мондый тәкъдим белән килешми, чөнки, бер яктан, бүген шәхси хуҗалыклар авыл халкының күпчелеге өчен бердәнбер табыш чыганагы булып тора, икенчедән, хәзергә илдә импортны алыштыру һәм Россия базарын үз продукциябез белән тәэмин итү проблемасы хәл ителмәгән әле. Бу мәсьәләне хуҗалык итүнең кече формаларыннан башка хәл итү шактый авыр булачак.**



КФХ һәм ШЯХ республика тулаем авыл хуҗалыгы продукциясенең яртысыннан артыгын тәэмин итәләр. Фотода: Әлки районының Татар Мулла Иле авылы фермеры Рамил Гыйматдинов.

хуҗалык итүнең кече формаларыннан башка хәл итү шактый авыр булачак.

Әлеге закон проекты тарафдарларының бу өлкәдә үз аңлатмалары бар. Алар чикләү кертү авыл хезмәтчәннәрен фермер яисә шәхси эшмәкәр булырга этәрәчәк, һәм алар төбәк бюджетларын тутыра башлаячак, дип ышандыралар. Ставропольлеләр инициативасын Россиянең баш ветеринария табибы, Россия Авыл хуҗалыгы күзәтчелеге җитәкчесе урынбасары Николай Власов та хуплый. Шәхси ярдәмче хуҗалыклардагы терлек санын чикләүгә омтылышны ул «бу өлкәдә тәртип кертергә ярдәм итәчәк» «законлы дөрес инициатива» дип атый.

Ставрополье хуҗалыкларында сарыкларның һәм кәҗәләрнең гомуми саны, 1990 ел белән чагыштырганда, ике тапкырга арткан – 900 меңнән 1,9 миллион башка җиткән, һәм биредәге җитәкчеләрнең аларны киметү идеясен федераль дәрәҗәдә беренче генә ел күтәреп чыгулары түгел инде. Моңа охшаш закон проектын беренче мәртәбә край парламенты депутатлары илнең Дәүләт Думасына инде 2009 елда ук керткәннәр иде, ләкин закон кабул ителми калды. Алты ел элек ставропольлеләр тәкъдимен СССР Хөкүмәтенең Никита Хрущев заманындагы сәясәте белән чагыштырдылар. Ул заманнарда шәһәрләрдә һәм эшче поселокларда яшәүчеләргә хайван асрауны тыйдылар, ә авыл халкыннан терлекне дәүләт файдасына мәҗбүри түстә сатып алдылар. Терлекләрне һәм кош-кортларны күпләп суя башлау аларның баш санын бик нык киметүгә һәм крестьяннарның хәлен начарайтуга китерде, һәм 1960нчы еллар башында ил ачлык бусагасында калды.

Авылдагы тормыш рәвешен саклап Татарстанда, киресенчә, төрле төбәк программаларын тормышка ашыра барып, авыл халкын терлек һәм кош-корт асраугa тартырга тырышалар, фермерлыкка ярдәм итү өчен төрле чаралар күрәләр. Республика ставропольлеләрнең революцион идеяләрен хупларга җыенмый. Алай гына да түгел, 2016 елда Татарстанда «ТР территориясендәге шәхси ярдәмче хуҗалыкларга дәүләт ярдәме турында»гы закон үз көченә керергә тиеш. Ул, экспертлар фикеренчә, авыл халкына дәүләттән гарантияле ярдәм алырга мөмкинлек тудырачак һәм шәхси хуҗалыклар үсешенә этәргеч бирәчәк.

Татарстан парламентарийлары тарафыннан, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән берлектә, шәхси хуҗалык ияләренә ярдәм механизмы эшләнде һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан хупланды. Документта бу ярдәмнең 10нан артык төре күрсәтелә, крестьяннарга төрле терлек сатып алуга, сыерларны ясалма аталандыру хезмәтенә түләү, теплица төзелеше, шулай ук башка юнәлешләргә субсидия бирү формалары телгә алына.

Бүген Татарстанда 4706 крестьян (фермер) һәм 400 меңнән артык шәхси ярдәмче хуҗалык исәпләнә. Алар республикада җитештерелә торган тулаем авыл хуҗалыгы продукциясенең яртысыннан күбрәген бирә. 2014 елда гына да бу хуҗалыклар 101 миллиард сумлык продукция җитештерде. Ә күп кенә районнарыбызда крестьян-фермер хуҗалыклары һәм шәхси хуҗалыклар җирле авыл хуҗалыгы продукциясенең 60–70 процентына кадәр тәэмин итә. Дәүләт авылларда хуҗалык итүнең кече формаларына да актив булыша. Тулаем алганда, 2014 елда республикада алар үсешенә төрле юнәлешләр буенча 2,1 миллиард сум акча бүлеп бирелде. Чагыштыру өчен: 2013 елда бу сан 1,8 миллиард тәшкил итте. Республиканың аерым муниципаль районнары бюджетында фермер һәм шәхси хуҗалыклар үсешенә бирелгән чыгымнарның үз маддәләре бар. Татарстанда ике ведомство программасы – «Яңа эш башлаучы фермер» һәм «Гаилә фермасы» – уңышлы эшләп килә, шулай ук чыгымнарның бер өлеше федераль бюджеттан каплана. Программалар кысаларында соңгы дүрт ел эчендә 565 крестьян-фермер хуҗалыгы гомуми суммасы 1 миллиард сум тирәсе булган грант отты.

Республикада 2010 елдан зур күтәренкелек белән төрле юнәлештәге гаилә фермалары төзелә башлады. Бүген аларның саны – 1100. Ферма хуҗалары 144 мең гектарда җир эшкәртә, өч меңгә якын кешене эш белән тәэмин итә. Моңа өстәп, тагын 100 терлекчелек объекты төзелеп ята.

– Авыл халкына ярдәм күрсәтүнең төп төре – аларны ташламалы кредит белән тәэмин итү, – ди ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының икътисад һәм аграр үзгәртеп корулар буенча урынбасары Ришат Хәбипов. – 2006 елдан 2014 елга кадәр татарстанлыларга 37,9 миллиард сумлык 145 мең ташламалы кредит бирелде. Аны республиканың һәр дүртенче авыл гаиләсе алды. Өстәвенә, процент ставкасын очсызландыруга 2,8 миллиард сум кучерелде. Агымдагы елның беренче яртысында крестьян-фермер хуҗалыкларына һәм шәхси хуҗалыкларга банклар тарафыннан 230 миллион сумнан күбрәк 850дән артык кредит бирелде.

Моның белән бергә ттән, республика берничә ел рәттән терлек азыгы сатып алу өчен бер сыерга 2 мең

**Татарстанда, киресенчә, төрле төбәк программаларын тормышка ашыра барып, авыл халкын терлек һәм кош-корт асрауга тартырга тырышалар, фермерлыкка ярдәм итү өчен төрле чаралар күрәләр. Республика ставропольлеләрнең революцион идеяләрен хупларга җыенмый. Алай гына да түгел, 2016 елда Татарстанда «ТР територириясендәге шәхси ярдәмче хуҗалыкларга дәүләт ярдәме турында»гы закон үз көченә керергә тиеш. Ул, экспертлар фикеренчә, авыл халкына дәүләттән гарантияле ярдәм алырга мөмкинлек тудырачак һәм шәхси хуҗалыклар үсешенә этәргеч бирәчәк.**



Әлки районының Түбән Колчура авылыннан элек төзелештә эшләгән Сергей Брыжков фермерлык белән өч ел элек шөгыльләнә башлаган.

сум исәбеннән субсидия бүлеп бирә, шуның белән халыкның савым сыерлары асрауга киткән чыгымнарының бер өлешен каплый. Бу максатларга республика бюджетыннан барлыгы 1,6 миллиард сум акча тотылган, шуның 222 миллион сумы 2014 елда бирелгән. Ярдәм итүнең әлеге ысулы быел да сакланды: һәр сыерга Хөкүмәт хәзер 3әр мең сум акча бүлеп бирә. Хуҗалыкларында кәҗә асраучылар да игътибарсыз калмады: бу ел башыннан терлек азыгы сатып алу өчен бер кәҗәгә берәр мең сум исәбеннән акча бүлеп бирелә.

Моннан тыш, быелдан башлап, бер башмак тана сатып алганда бер терлек башына 15 мең сум исәбеннән авыл халкына чыгымнарының бер өлеше кире кайтарыла. Мондый ярдәм хисабына бер хуҗалык биш танага кадәр сатып алырга мөмкин, ә субсидия күләме сатып алынган терлек бәясенең яртысыннан артмаска тиеш. Төп шарт – ул терлекне биш ел дәвамында саклау. Бер үк вакытта быел республикада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе буенча хуҗалыкларында өч һәм аннан артык савым сыеры асраучы гаиләләргә ярдәм итү программасы эшләнде. Мондый хуҗалыкларга кече сөт фермалары төзү өчен бер тапкыр бирелә торган дәүләт субсидиясенең күләме 200 мең сум тәшкил итә. Ул хуҗалыклар ике ел эчендә савым сыерларының санын 8 башка җиткерергә тиеш.

## ХУҖАЛЫК БИЗНЕСЫ

Саба районының Иске Икшермә авылында яшәүче Шакировлар гаиләсен дәүләт ярдәменең яңа төре нык кызыксындырган. Бүген аларның хуҗалыгында 6 сыер исәпләнә, шуңа күрә гаилә башлыгы республика программасына зур өметләр баглый.

Соңгы вакытта, бюджет ярдәменең төрле формалары ярдәмендә Иске Икшермә халкы арасында терлек асрау һәм аның баш санын арттыруга кызыксыну арта. Бүген авылда барлыгы 366 баш мөгезле эре терлек исәпләнә, шуның 109ы – сыерлар. Бирегә Шакировлардан башка күп сыер асраучы башка гаиләләр дә бар. Кайберәүләр – ике-өч, кайберләре исә дүрт сыер тота.

Крестьян-фермер хуҗалыгы башлыгы Зөфәр Мөхәммәтшин авылдашларын яхшы хезмәт хакы түләнә торган эш белән тәэмин итә. Аның җитәкчелегендә бүген 65 кеше эшли, 2014 елда хуҗалык буенча уртача хезмәт хакы 17300 сум тирәсе тәшкил иткән. 2013 елдан башлап, территориясендә 260 сыерга исәпләнгән югары технологияле роботлашкан сөт комбинаты эшләп килә торган әлеге крестьян-фермер хуҗалыгының җитештерү күрсәткечләре дә начар түгел. Узган ел хуҗалыкта бер әйләнәгә 36,6 центнер исәбеннән 30 444 центнер икмәк җыеп алынган, 33756 центнер сөт һәм 2076 центнер ит җитештерелгән. Үз көчләре белән 250 башка исәпләнгән бозау абзары корганнар, ферма идәненә бетон плитә җәйгәннәр.

Хуҗалыкларында күп терлек асраучы тырыш кешеләр бүген Әлки районында да җитәрлек. Агымдагы елның башыннан җирле хуҗалыкларда сыерлар саны 130 башка арткан, ә август башында шәхси ярдәмче хуҗалыкларда савым сыерларның гомуми баш саны – 2730га, кәҗәләр ярты меңгә җиткән.

Агымдагы елда райондагы 16 гаилә 8 сыерга исәпләнгән кече сөт фермалары төзү буенча яңа программада катнашырга теләк белдергән, ә 30дан артык кеше ташламалы бәягә башмак тана сатып алырга дәгъва кыла. Шушы көннәрдә әлкилеләр терлек азыгы сатып алу өчен барлыгы 8,7 миллион сумга субсидия алган.

– Бездә барлыгы 35 крестьян-фермер хуҗалыгы эшли, – дип сөйли Әлки районының авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Роберт Гадиев. – Гаилә фермаларына килгәндә, моңа кадәр алар барлыгы 26 иде. Быел аларга тагын икәү кушылды. Берсе Иске Чаллы авылында яшәүче Фәннур Галиәхмәтовныкы. Ул сөт терлекчелеге буенча махсуслашты һәм «Яңа эш башлаучы фермер» программасы кысаларында 1,2 миллион сумлык грант отты. Ә Чуваш Кичүе җирлеге составына керүче Татар Әхмәте авылыннан тәҗрибәле фермер Әсгать Вилданов «Гаилә фермасы» программасы буенча 2,2 миллион сум күләмендәге грантка ия булды. Бу акча 40 баш терлеккә исәпләнгән югары технологияле сыер абзары төзелешенә тотылды. Хуҗалыкта күп сөт бирә торган сыерларга исәп тоталар. Быел Әсгать Рәхимович Киров өлкәсеннән 10 нәселле буаз тана кайтартты, аларның кайберләре үрчем бирә башлады инде. Фермер өчен сөт төп керем чыганагы булып тора, ә аннан кергән акча җитештерүнең алга таба үсешенә һәм машина-трактор паркын яңартуга китә – фермерның әле тагын 150 гектар сөрүлек җире бар, аның төп өлешендә бөртекле культуралар үстерелә.

Гаилә эшен алып барырга Әсгать Вилдановка өч яллы эшче, шулай ук хатыны һәм балалары булыша. Кече улы Айнур – фермерның уң кулы. 2012 елда Казан дәүләт аграр университетын тәмамлагач, егет туган авылына әйләнеп кайткан.

– Эш, билгеле, бал түгел, аеруча җәй айларында – иртә таңнан алып кояш батканчыга кадәр аяк өстендә, – ди ул. – Әмма һич тә монда кайтканы-



Әлки районы Татар Мулла Иле авылыннан Фәрит Гыйматдинов туган нигезен саклау өчен авылына әйләнеп кайткан.

**Тулаем алганда, 2014 елда республикада алар үсешенә төрле юнәлешләр буенча 2,1 миллиард сум акча бүлеп бирелде. Чагыштыру өчен: 2013 елда бу сан 1,8 миллиард тәшкил итте. Республиканың аерым муниципаль районнары бюджетында фермер һәм шәхси хуҗалыклар үсешенә бирелгән чыгымнарның үз маддәләре бар.**

ма үкенмим. Каян көч табасыз, дисезме? Үзебезгә эшлибез бит, чит кешегә түгел.

Чуваш Кичүе авылында Вилдановлардан башка да фермерлар бар. Әмир Гыйзетдинов белән Фәнис Бакиров та, мәсәлән, нәтиҗәле эшли. Фәнис гаиләсенең ат фермасында бүген 160 баш ат исәпләнә.

Авыл җирлегендә мөгезле эре терлекнең гомуми саны – 750 баш, шуларның 250 дән артыгы – сыерлар. Агымдагы елның җиде ае эчендә генә дә шәхси ярдәмче хуҗалыклар 340 тонна сөт саткан һәм шуның белән 5 миллион сумга якын акча эшләгән. Ленар Хәйруллин, Рәис Бакиров, Рәмис Вәлиуллин, Рәмис Гатауллин, Рәүф Низамов шулар исәбенә керә – алар һәркайсы ел башыннан 12шәр тонна һәм аннан да күбрәк сөт саткан.

Хуҗалыгында терлек асрамасаң, авыл тормышында нидер җитмәгәндәй тоела. Сыер гаиләне сыйфатлы сөт продуктлары белән тәэмин итә, өстәмә акча эшләү мөмкинлеге бирә. Халыктан сөт җыю яхшы оештырылган очракта, билгеле. Әлки районында сөт җыю белән ике фирма шөгыльләнә – «Молпром» ААҖ һәм «Шәйхетдинов Дамир» ШЭ, алар клиентлар белән исәп-хисапны вакытында ясап кына калмыйлар, техника, терлек сатып алганда яисә ферма төзелеше өчен бурычка процентсыз шактый гына акча да биреп торалар. Соңгы ике ел эчендә үз хисапларына 100 индивидуаль саву җайланмасы сатып алганнар һәм аларны хуҗалыкларында өч баштан артык сыерлары булган сөт тапшыручыларга өләшкәннәр.

Мондый җайланма Түбән Колчурада Сергей Брыжковның гаилә фермасында да ышанычлы хезмәт итә. Элек төзелештә эшләгән Сергей фермерлыкны өч ел элек башлап җибәргән, хуҗалыгында башта 12 сыерга исәпләнгән абзар төзеп куйган. Быел улы Виталий белән бергәләп, авыл кырыенда 100 башка исәпләнгән яңа ферма төзи башлаган. Шәхси крестьян хуҗалыгын киңәйтү хыялын Сергей Витальевич эшмәкәр Дамир Шәйхетдиновның финанс ярдәме белән якынайткан.

– Без – фермерлар өчен Шәйхетдинов чын терәк булып тора, – ди Сергей Брыжков. – 5 миллион сумга төшә торган яңа сыер абзары төзү өчен авылда акчаны каян таба алган булыр идем мин? Ә абзар миңа бик кирәк, минем 20 сыерга иске ферма кысанрак хәзер. Шуңа күрә дә бурычка кердем, аны сөт белән түләячәкмен. Тора-бара чыгымнарның бер өлешен 100 башка исәпләнгән сөт фермаларын реконструкцияләү буенча республика программасы исәбенә капларга уйлыйм. Шуңа кергә алсам, бик әйбәт була инде.

Җир мәсьәләсе генә хәзергә хәл ителмәгән: фермерның сөйләвенә караганда, терлек азыгы хәзерләү өчен аның бер гектар да чәчүлек җире юк, азыкны ул сатып алырга мәҗбүр. Күптән түгел генә кыш чыгар өчен 200 мең сумлык печән әзерләгән. Бөртекле азык сатып алу өчен дә акча кирәк.

Татар Мулла Иле авылыннан Фәрит Гыйматдинов та бүген шундыйрак каршылыкка очраган. Үзенең 12 сыеры өчен азыкны ул 30 гектар җирдә үстерә, ул җирнең 12 гектарын авылдашларыннан арендага алып тора.

– Пай җирләрен алар теләсә кайсы вакытта кире алырга мөмкиннәр, – дип борчыла Фәрит абый. – Аннары бетте диген инде. Ә мин әле киңәергә уйлап торам, шул ук Дамир Шәйхетдинов ярдәме белән Киров өлкәсеннән күп сөт бирә торган 10 баш буаз тана алып кайттым. Минем сыерларның нәтиҗәсе түбән, тәүлеклек савым 50 литрга төште.

Фәрит Галләмович савым сыерларын яңарту бурычлардан котылырга, шулай ук кайбер авыл хуҗалыгы техникасы сатып алырга мөмкинлек бирер, дип ниятли.

Кыенлыкларга карамастан, әңгәмәдәшемнең авылдашлары – Рамил Гыйматдинов, Тәлгать Фәттахов, Рафис Әсәдуллин да алдагы көнгә зур өметләр баглый. Алар, Фәрит Гыйматдинов кебек үк, гаилә фермалары төзергә өлгергәннәр һәм, «перспективасыз» авыл Татарстан картасыннан юкка чыкмасын өчен, бөтен көчләрен куялар. Ата-аналарының эшләрен дәвам итәчәк балалары да үсеп килә. Күптән түгел авылга керү өчен әйбәт юл да салып куйганнар.

– Билгеле, мәшәкате күп инде. Кемгә җиңел соң ул? – ди сарык үрчетү белән шөгыльләнүче Рафис Әсәдуллин. – Без бит авыл кешеләре, авыр эшкә кечкенәдән күнегеп үскән. Минем зур акчалар артыннан каядыр читкә китү теләгем беркайчан да булмады, бу җиргә без кендегебез белән береккән. Ә анда эшләү күп көч сорый. Кемдер авылны саклап калырга тиеш бит инде...




Вероника КӘЛИМУЛЛИНА тексты.
Автор фотосы.

# ТИҮ: куллану буенча күрсәтмә

ТЕРРИТОРИАЛЬ ИҖТИМАГЫЙ ҮЗИДАРӘЛӘР НИГӘ КИРӘК? ГАДӘТТӘ КЕШЕЛӘР КИРӘГЕ ЧЫККАНЧЫ: ЮЛ ВАТЫЛГАНЧЫ ЯКИ ТОРБА ТИШЕЛГӘНЧЕГӘ КАДӘР ӘЛЕГЕ СОРАУГА ҖАВАП ЭЗЛӘП МАТАШМЫЙ. НӘКЪ ШУЛ ВАКЫТТА ТЕРРИТОРИАЛЬ ИҖТИМАГЫЙ ҮЗИДАРӘ СОВЕТЛАРЫ ЯРДӘМГӘ КИЛӘ ДӘ ИНДЕ. ЧИСТАЙДА РӘСМИ РӘВЕШТӘ СИГЕЗ ТИҮ УСТАВЫ ТЕРКӘЛГӘН. БЕЗНЕҢ ШӘҺӘРДӘ ӘЛЕГЕ ОЕШМАЛАР ТР ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЫ ВИКТОР СМЫКОВ ИНИЦИАТИВАСЫ БУЕНЧА ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННЫҢ ЭЛЕККЕГЕ БАШЛЫГЫ ИЛДУС ӘХМӘТҖАНОВ ЯРДӘМЕ БЕЛӘН ОЕШТЫРЫЛДЫ.

Узган елның ноябрендә Чистайда ТР территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләре өчен үткәрелгән күчмә семинарда ТР Муниципаль берәмлекләр Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров пленар утырышны түбәндәге сүзләр белән башлады: «Сүз ниндидер яңа идея турында бармый, ТИҮләр – ул халыкның җирле үзидарәдә катнашуының яхшы ук оныталган концепциясен дәвам итү», – диде. Чыннан да, ТИҮләр ноухау түгел, безнең ил гражданнарында шәхси яки гомуми мәсьәләләрне чишү өчен берләшү гадәте күптән бар. Профсоюз оешмаларын, халык дружиналарын, гараж кооперативларын, торак комитетларын гына искә төшерик... Әмма ТИҮләр, һичшиксез, иҗтимагый эшчәнлекне рәсми дәрәҗәгә «күтәрү» мөмкинлеге барлыкка китерә торган яңа дәрәҗә.

Чистайдагы күп кенә ТИҮләр ел саен уздырыла торган республикакүләм бәйгеләрдә катнаша, грантлар ота. Бик озак вакыт эшләмәсәләр дә, Чистай шәһәре ТИҮләре республика рейтингында югары позиция яулый алды. Бүген безнең яшь, әмма шактый тәҗрибәгә ия булган иҗтимагый оешмалар – «Вектор» радиокомпаниясе» һәм «Кирпичный» микрорайоннарындагы ТИҮләр турында сөйлисебез килә.

### ЫШАНЫЧКА ЮЛ

Су торбалары сузу, балалар мәйданчыгы ясау һәм хәтта эшкә урнаштыру – Дмитрий Забегаев өчен мондый мәсьәләләрне чишү – гадәти эш. 50 елдан артык ул «Вектор» радиокомпаниясендә баш энергетик булып эшләгән, ә бүген «Вектор» радиокомпаниясе» микрорайонындагы территориаль иҗтимагый үзидарәне җитәкли. ТИҮ территориясендә 1080гә якын шәхси һәм 18 күпфатирлы йорт урнашкан.

«Вектор» радиокомпаниясе» микрорайонындагы 5нче номерлы ТИҮ үз эшчәнлеген 2012 елның сентябрендә «Вектор» радиокомпаниясенең генераль директоры Виктор Классенның актив ярдәме белән башлап җибәрде. Ул 320 гектар мәйданны били торган иң зур ТИҮләрнең берсе булып тора. Әмма Виктор Иванович әлеге микрорайон урынында ташландык җир булуын хәтерли әле. 1986 елда, Чистайда «Вектор» дип аталган конструкторлык-технология бюросына нигез салу белән бергә, шәһәр тарихында яңа чор башланып китә. Оешма хезмәткәрләре өчен беренче йортлар төзелә, сууткәргечнең беренче тармагы, электр линияләре үткәрелә.

Хәзер дә радиокомпания җирле үзидарәне үстерүдә мөһим роль уй-



Су торбалары сузу, балалар мәйданчыгы ясау һәм хәтта эшкә урнаштыру — Дмитрий Забегаев өчен мондый мәсьәләләрне чишү — гадәти эш. 50 елдан артык ул «Вектор» радиокомпаниясендә баш энергетик булып эшләгән, ә бүген «Вектор» радиокомпаниясе» микрорайонындагы ТИҮне җитәкли.

**ТИҮләр ноу-хау түгел, безнең ил гражданнарында шәхси яки гомуми мәсьәләләрне чишү өчен берләшү гадәте күптән бар. Профсоюз оешмаларын, халык дружиналарын, гараж кооперативларын, торак комитетларын гына искә төшерик... Әмма ТИҮләр, һичшиксез, иҗтимагый эшчәнлекне рәсми дәрәҗәгә «күтәрү» мөмкинлеге барлыкка китерә торган яңа дәрәҗә.**

ный. Ул ТИҮгә телефон һәм мебель белән җиһазландырылган 108 квадрат метр мәйданлы бинаны бушлай файдалануга биргән. Иркен залда рәссамнар күргәзмәләре, гражданнар җыеннары, шәһәр администрациясе вәкилләре белән очрашулар һәм ял итү чаралары уза. Шулай ук биредә көн саен бик күп төрле мәсьәләләрне: халыкны эш белән тәэмин итү, әйләнә-тирәне төзекләндерү һәм яшелләндерү, коммуналь хезмәтләр өчен түләү, иҗтимагый иминлек, агымдагы капиталь ремонтны оештыру һәм башкаларны хәл итәргә туры килгән ТИҮ җитәкчесе өчен кабинет та бар.

– ТИҮ белән зур тәҗрибәгә ия, кешеләргә карата яхшы мөгамәләле, аларның хәленә керә белә торган, микрорайон проблемаларыннан хәбәрдар кеше җитәкчелек итәргә тиеш, – ди Дмитрий Забегаев. – Читтән килгән кеше әлеге мәсьәләләрне башкарып чыга алмаячак. Халыкның ничек яшәвен белергә кирәк, әгәр син үзең шул районнан икән, аны алга җибәрү буенча көч кую формаль булмаячак. Менә, мәсәлән, күптән түгел халык миңа мондый мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итте: электр линиясен тарттырып торучы калын тимерчыбыкны кисканнәр, багана торак йорт өстенә аварга мөмкин. Ашыгыч рәвештә диспетчерлык пунктына шалтыратырга туры килде, оператив рәвештә эшләделәр – карадылар, фотога төшерделәр, хәтта администрациягә мөрәҗәгать итмәдек, мәсьәләне электр челтәрләре оешмасы белән турыдан-туры хәл иттек.

Халык мөрәҗәгатьләре белән эш өзлексез рәвештә алып барыла, моның өчен махсус журнал ачылган. Нигездә, олы яшьтәге кешеләр мөрәҗәгать итә, аларны йорт тирәләрен һәм балалар







«Вектор» радиокомпаниясе» микрорайонындагы 5нче номерлы ТИУ үз эшчәнлеген 2012 елның сентябрендә башлап җибәрә.

өчен мәйданчыкларны төзекләндерү, су белән тәэмин итү, мәдәни-күңел ачу чараларын оештыру кебек көнкүреш мәсьәләләре борчый.

Әлбәттә, эшләве авыр, әмма, икенче яктан, шәхси хуҗалык тотучылар яши торган микрорайоннар яшәүчеләрнең мөстәкыйльлеге белән аерылып торалар. Учхоз бистәсе халкы инициативасы, ТР Дәүләт Советы депутаты Виктор Смыковның һәм шәһәр администрациясенең ярдәме белән 1000 метр озынлыктагы сүүткәргеч торба салынган. Әлеге мәсьәләне чишүдә ТИУ дә үз өлешен керткән, аерым алганда, аның хезмәткәрләре тарафыннан барлык кирәкле документация әзерләнгән.

– ТИУ җитәкчесе, һичшиксез, юридик яктан әзерлекле һәм белемле булырга тиеш, – дип саный Дмитрий Забегаев. һәм бу дөрес тә, чөнки җир хокукы, коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр, иҗтимагый иминлеккә кагылган мәсьәләләр чыгып кына тора. Уку елы тәмамлангач, ТИҮгә балаларын шәһәр уку йортларына урнаштыру мәсьәләсе белән кызыксынган ата-аналар мөрәҗәгать итә башлый. Бу мәсьәләдә дә ТИУ үз кул астында эшләүчеләренә ярдәм итәргә тырыша, әмма бар нәрсә дә җәмәгатьчеләр көченнән килерлек түгел шул. Әлеге хәлне аңлау яхшы җитәкченең көндәлек эшен тәшкил иткән фактларның берсе булып тора.

– һәр аерым очракта кешене тыңларга һәм ярдәм итәргә кирәк. Ләкин әгәр булдыра алмыйсың икән, өметләндермәскә, алдамаска кирәк, ә хәлнең ничек булуын ачыктан-ачык әйтеп бирү мөһим, – дип дәвам итә әңгәмәдәшем.

5нче номерлы ТИУ эшчәнлегендәге мөһим юнәлеш булып халыкның социаль яктан яклауга мохтаҗ катламына ярдәм итү тора. Ел саен «Мәктәпкә җыенырга булыш!» хәйрия акциясе, Өлкән кешеләр көне оештырыла, раштуа кичәләре үткәрелә. Социаль яклау бүлеге хезмәткәрләре һәм районның участковыйлары белән берлектә имин булмаган гаиләләргә рейдлар оештырыла.

Үз чиратында, халык та активлык күрсәтә һәм рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләрне ачыклау буенча рейдларда, территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча өмәләрдә катнаша. Әйтик, мәсәлән, микрорайонда яшәүчеләр хисабына 270ләп агач сатып алынган һәм утыртылган. Актив һәм



ТИҮ ярдәме белән яңа спорт һәм балалар мәйданчыгы барлыкка килгәч, шикләнүләр юкка чыга, халык микрорайон тормышында барлыкка килгән яңа күренешкә җитди карый башлый.

инициативалы кешеләргә ТИҮ бүләкләр һәм рәхмәт хатлары тапшыра. Хәзерге вакытта «Йорт тирәсен иң шәп итеп бизәү» бәйгесе уза, җиңүчегә бүләк – газон чапкыч.

Дмитрий Забегаев ТИҮ ирешкән төп уңыш дип кешеләр ышанычын яулауны саный. «Суүткәргеч сузу, электр линияләрен төзәтү – болар барысы да көндәлек мәсьәләләр, иң мөһиме – кешеләр безгә килә башлады. Халык өчен администрациягә караганда ТИҮгә мөрәҗәгать итү уңайлырак. Үтеп барган чакта үзләрен борчыган мәсьәлә искә төшсә, керәләр яисә шалтыратталар. Ышаналар, димәк, без – дөрес юлда».

## 3D ФОРМАТЫ

2013 елда радиокомпания базасында, Россиядә яшьләрнең инновацион иҗаты үзәкләрен үстерү программасы буенча «3D-Вектор» дип аталган цифрлы җитештерү лабораториясе ачыла. Ул балалар һәм яшьләрне инновацияле иҗади эшчәнлеккә җәлеп итә.

3D-үзәк хезмәткәре инженер-уйлап табучысы Сергей Матросов безнең өчен экскурсия үткәрде һәм җиһазларның мөмкинлекләрен күрсәтте. Үзәк кыска гына вакыт эчендә теләсә нинди катлаулылыктагы объектларның 3D форматлы макетларын алу мөмкинлеге бирә торган 3D-принтерлар, лазерлы принтерлар, фрезерлы машиналар һәм 3D-сканерлар белән җиһазландырылган. Үзәктә өлкән сыйныф укучылар белем ала. Лекцияләр курсын тыңлаганнан соң алар шәхси проектларын әзерләүгә керешә. Белем алуның бу өлеше укучыларны бигрәк тә үзенә тартып тора.

Мәктәп укучыларыннан тыш, 3D-үзәктә олылар да укый ала. Заманча җиһазларда эшләргә өйрәнгәннән соң, алар, мәсәлән, сувенир продукциясе җитештерү буенча үз эшен ачып җибәрергә мөмкиннәр.

Заманча җиһазлар ярдәмендә уенчыклар, сыннар, открыткалар, магнитлар эшләп чыгарырга, кружкаларга рәсем төшерергә мөмкин... 3D-үзәктәге стеллаж һәм киштәләр төрледән-төрле статуэткалар белән тулган: монда шәһәр символикалары төшерелгән кружкалар да, магнитлар да бар, биредә шулай ук Эйфель башнясын һәм хәтта пилотсыз очу аппараты моделен дә күрергә мөмкин. Җитештерелгән продукция тик ятмый – аны җирле музейдагы сувенир салоны сатып ала. Әмма төп максат, әлбәттә, сәүдә итү түгел, ә өйрәтү.

## ЭШ ИНИЦИАТИВАДАН ГЫНА ТОРМАС

2013 елның августында «Кирпичный» микрорайонының территориаль иҗтимагый үзидарәсе оештырыла. Аның җитәкчесе итеп Андрей Сашин сайлана. Андрей Владимирович әлеге микрорайонда туып-үскән, ә соңыннан биредә эшли башлаган, шуңа күрә аны биредә барысы да белә һәм хөрмәт итә.

Яңа ТИҮ барлыкка килүне микрорайонда яшәүчеләр төрлечә кабул итә: кайберәүләр бу яңалыкта район өчен яңа мөмкинлекләр күрә, ә икенчеләре, пессимистик караштагылары, исә аны чираттагы формаль оешма буларак кабул итә. Әмма вакытлар узып, ТИҮ ярдәме белән яңа спорт һәм балалар мәйданчыгы барлыкка килгәч, шикләнүләр юкка чыга, халык микрорайон тормышында барлыкка килгән яңа күренешкә җитди карый башлый.

Чыннан да, спорт һәм балалар мәйданчыгы барлыкка килү мондагы халык өчен зур әһәмияткә ия. Кешеләр нигездә шәхси йортлар белән тора, ә яшьләргә спорт белән шөгыльләнү өчен урын юк. ТИҮ барлыкка килү белән, алар өчен футбол, волейбол, өстәл теннисы, авыр атлетика һәм армрестлинг белән шөгыльләнү мөмкинлеге туа. Ә нәниләр исә балалар шәһәрчегенең уен мәйданчыкларында рәхәтләнеп уйный ала.

Быел биредә дарухәнә ачылган. «Кирпичный» микрорайоны – иң еракта урнашкан һәм аерымланган район, шуңа күрә биредә яшәүчеләргә, бигрәк тә өлкән яшьтәгеләргә, дару алырга шәһәрнең икенче читенә бару уңайсыз булган. ТИҮ җитәкчесе тырышлыгы һәм шәһәр администрациясе ярдәме белән туры килерлек бина һәм яңа филиал ачарга әзер булган эшмәкәр эзләп табылган.

ТИҮ белән бер түбә астында китапханә урнашкан. Ул үз вакытында элеккеге кирпеч заводының администрация бинасында урын алган булган, әмма соңгы елларда шактый таушалган. ТИҮ бинасына күчү бик вакытлы булган һәм мәдәният учреждениесен саклап калырга ярдәм иткән. Бүгенгә көндә китапханәгә ихтыяҗ бар, аңа төрле яшьтәге китап сөючеләр килә, китап фонды әкренләп яңартыла, биредә төрле уртак чаралар, балалар өчен бәйгеләр үткәрелә. Димәк, ТИҮ китапханәгә яңа тормыш өрде дип әйтергә тулы хокук бар.

Күптән түгел ТИҮ бинасында керәшен татарлары өчен гыйбадәт кылу бүлмәсе ачылган.

– Бервакыт танышым җирле дин оешмасы өчен гыйбадәт кылу бүлмәсе ачу үтенече белән мөрәҗәгать итте, – дип искә ала Андрей Сашин. – Безнең шәһәрдә, аерым алганда, «Кирпичный» микрорайонында керәшен татарлары күп яши. Үзем дә дини кеше буларак, мин аларга ярдәм итүдән баш тарта алмадым.

Шулай итеп, ТИҮ микрорайонның үзенә күрә мәдәни үзәгенә әверелгән – бер түбә астында иҗтимагый, спорт һәм дини эшчәнлек тормышка ашырыла.




«Кирпичный» микрорайонында ТИҮ үзенә күрә бер мәдәни үзәккә әверелә – бер түбә астында иҗтимагый, спорт һәм дини эшчәнлек тормышка ашырыла. (Фотода: Андрей Сашин.)

– Тырышлыкларыбызны берләштерә алганга без бик шат, – ди рәис. – Китапханә белән гыйбадәт кылу бүлмәсе хезмәткәрләре рухыбызны үстерүгә, тарихны, динне өйрәнүгә юнәледерелгән уртак чаралар оештыра.

Микрорайонда яшәүчеләрнең күпчелек өлеше – олы яшьтәге кешеләр, аларга үзенә бертөрле ярдәм һәм игътибар кирәк. ТИҮ советы, шәһәрнең иҗтимагый оешмалары белән берлектә, аларга һәрьяклап булышырга тырыша.

– Кешеләрнең үз инициативасыннан башка булмый, – ди Андрей Сашин.

Бәхеткә, шәхси эшкуарлар һәм җирле депутатлар өмәләр, ремонт эшләре үткәрү өчен чаралар һәм техника бүлеп бирә, ә шәһәр кешеләре чараларда актив рәвештә катнаша. Соңгы вакытта ТИҮ һәм хокук тәртибен саклау буенча иҗтимагый пунктлар белән уртак эш алып бару тәҗрибәсе гамәлгә кертелгән. Бу җәһәттән 8нче номерлы ТИҮ бинасында махсус бүлмә бүлеп бирелгән – биредә атнага ике мәртәбә полиция участковые гражданнарны кабул итә.

Җәйге каникуллар вакытында ТИҮ бинасында балалар өчен түгәрәкләр оештырыла, тәҗрибәле педагог-укытучы Любовь Степанова балалар белән иҗат дәресләре үткәрә. Ә олылар микрорайон территориясендә урнашкан «Аксакал» дип аталган танылган чишмә янында ял итәргә ярата. Әлеге чишмәнең шифалы көче турында бик күп төрле риваятьләр йөри, дини оешмалар бирегә гыйбадәт кылу өчен килә, ә шәһәр халкы «Чәй бәйрәменә» җыела.

8 августта, Шәһәр көненә багышлап, биредә чираттагы «Чәй бәйрәме» уздырыла. Әлеге чара бигрәк тә үзенчәлекле була, чөнки 8нче ТИҮ «ТРның иң яхшы ел территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсында катнашып, икенче дәрәҗә дипломга лаек була, 500 мең сум премия дә бирелә. Акчалар бәйрәмдә Андрей Сашинга тапшырыла.

**ТИҮ белән бер түбә астында китапханә урнашкан. Ул үз вакытында элеккеге кирпеч заводының администрация бинасында урын алган булган, әмма соңгы елларда шактый таушалган, ТИҮ бинасына күчү бик вакытлы булган һәм мәдәният учреждениесен саклап калырга ярдәм иткән. Бүгенге көндә китапханәгә ихтыяҗ бар, аңа төрле яшьтәге китап сөючеләр килә, китап фонды әкренләп яңартыла.**

Уку елы алдыннан хәйриячеләр беренче сыйныф һәм авыр тормыш хәлләренә юлыккан гаилә балаларына портфельләр тапшырганнар. Җирле эшкуар, киемнәр дизайнеры Гөлия Гыймадиева балаларга яңа чалбарлар һәм үз ательесында тегелгән мәктәп формаларына сертификатлар бүләк иткән. Хәйриячеләрнең берсе – Халит Гарифуллин чишмәне төзекләндерү өчен акча бирергә вәгъдә итә. Чишмә чокырлы урында урнашкан. Шуңа күрә чишмәгә юл ясау бик яхшы булыр иде. Әлеге изге эштә уңышлар телик.

Шулай да соңгы соравымны бирми китә алмыйм: «Андрей Владимирович, сезнеңчә, заманча ТИҮгә ни җитми?»

– Минемчә, уңайлы һәм нәтиҗәле эш алып бару өчен безгә юридик зат статусы җитми. Мондый статус безгә коммерция эшчәнлеге белән шөгыльләнү, халыкка хезмәт күрсәтү өчен кирәк. Ул безгә, бер яктан, беренчел ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен акча эшләргә, ә икенче яктан, халык өчен эш урыннары булдырырга мөмкинлек бирәчәк. Безнең киләчәк – шунда, – дип уйлый Андрей Сашин.




Уку елы алдыннан хәйриячеләр беренче сыйныф һәм авыр тормыш хәлләренә юлыккан гаилә балаларына портфельләр тапшырганнар. Җирле эшкуар, киемнәр дизайнеры Гөлия Гыймадиева балаларга яңа чалбарлар һәм үз ательесында тегелгән мәктәп формаларына сертификатлар бүләк иткән.



### АҢЛАТМА

**Виктор КЛАССЕН, «Вектор» радиокомпаниясенең генераль директоры:**

*– Бүгенге көндә Чистай кебек кече шәһәрләрдән яшьләрнең күпләп китүе күзәтелә. Бу, иң беренче чиратта, эре шәһәрләрдә кешенең үсеше өчен җәлеп итәрлек һәм җайлы шартлар тудырылу белән бәйле. Мин Чистайга килгән генә чакта, биредә 67 мең кеше яши иде. Хәзер бу сан 55 меңгә кадәр кимеде һәм алга таба да киму тенденциясе саклана. Яшь чистайлыларны үзебездә калдыру өчен безгә кызыклы эш шартлары булдырырга кирәк. Ә яшьләргә нәрсә кызык? Әлбәттә, прогресс, заманча инженерия эшләнмәләре. Җирле үзидарә тарафыннан ярдәм һәрвакыт җитештерү тармагы белән бергә бара. Бүген инде халыкка һәм яшьләргә ярдәм итүнең җәмгыятьнең үсеше һәм чәчәк атуы өчен өстенлекле бурыч булып торуы беркемдә дә шик тудырмый. Шуңа күрә үз микрорайоныбызның территориаль иҗтимагый үзидарәсенә булышырга тиеш булуыбызда бер вакытта да шикләнеп тормадык.*



**Людмила КАРТАШОВА тексты.**
**Фотолар автордан һәм М.Х. Зариповның архивыннан алынды.**

– ӘНӘ ОЧУЧЫ БУЛЫРГА ҖЫЕНГАН, – ДИП, ЗАМАНЫНДА БИК ПОПУЛЯР, ӘММА АВЫЛ ЕГЕТЕ ӨЧЕН КӨТЕЛМӘГӘН ҺӨНӘР САЙЛАГАН УЛЫ ХАКЫНДА ИРЕНӘ ЖАЛУ БИРӘ НАТАЛЬЯ ПЕТРОВНА, КҮЗЛӘРЕНӘ БӨЯЛГӘН ЯШЕН ЯУЛЫК ЧИТЕ БЕЛӘН СЫПЫРА-СЫПЫРА. – КҮЗ КҮРМӘГӘН ЯКЛАРГА КИТЕП ЮГАЛЫР МАРАТЫБЫЗ. КАРТАЙМЫШ КӨНЕБЕЗДӘ ЯРДӘМЧЕСЕЗ КАЛЫП ТИЛМЕРЕШЕРБЕЗ. ӘЙ, АННАН НИНДИ ОЧУЧЫ ЧЫКСЫН СОҢ...

# *БӘХЕТЕН туган җирендә тапкан*

Бу вакытта чаңгыларга ныгыткычлар беркетү белән мәшгуль Габделхәй Зарипович, эшен бер читкә куеп, улын «келәм»гә чакыра. Шулчакта фронтовик әтисе улына ниләр сөйләп, нинди дәлилләр китергәндер – бу хакта гоманларга гына кала. Әмма әлеге сөйләшүдән соң, Балтач егете Марат Зарипов үзенең хыялын үзгәртә, соңрак ачыкланганча, унөч буын ата-бабалары тир түккән туган җирдән аерылмаска карар кыла. «Кайда туган, шунда яраган» дигән әйтем нәкъ менә аның хакындадыр.

Атасы йортына кайтып төпләнгәнче, Марат армиядә хезмәт итә, соңрак Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. Хезмәте ни җитте урында түгел, ә Мурманск өлкәсендәге данлыклы Североморскида, диңгез авиациясендә. Барыбер – күк, хыял канатлары тарткан очучылык...

– Армия бөтен яктан файдалы, шулкадәр көчле мәктәп ул, анда алынган тормыш тәҗрибәсе өчен бүгенгәчә язмышыма рәхмәт укыйм, – дип искә ала Марат Хәйевич. – Сүз дә юк, армия – ял йорты түгел, авырлыклар җитәрлек булды, анда ныклы тәртип хөкем сөрә, чыдамлык, сабырлык, ныклы сәламәтлек таләп ителә. Әмма минем барысы да әйбәт килеп чыкты, чөнки омтимист һәм аек карашлы кеше мин. Чаңгыда әйбәт йөри торган әтидән үрнәк алып, балачактан ук спорт белән мавыкканга күрә, физик әзерлегем белән тәртип иде. Чаңгы буенча уңышларымда физкультура укытучыбыз Тәварис Гарифович Садыйковның да өлеше зур, армиягә беренче разрядлы чаңгычы булып киттем. Берничә мәртәбә үзебезнең частьнең данын якларга туры килде, чаңгыда узышу буенча Төньяк флотның җыелма командасына керә идем. Әле дә исемдә, бервакыт Төньяк бәйрәменә атаклы спортчылар Вячеслав Веденин, Галина Кулакова, Раиса Сметанина килде һәм чаңгы ярышларында катнашты. Мин дә алар белән чабышу бәхетенә ирештем...

Армиядән кайтуга, документларын авыл хуҗалыгы институтына илтеп биреп, Марат әти-әнисен нык сөендерә. Вузда да чаңгы спорты белән шөгыльләнергә иренми, 70нче еллар башында республика җыелмасы составына керә, эстафета ярышларында Татарстан чемпионы була.

Кыш җитеп, җиргә кар ятуга, Марат Хәйевич хәзер дә келәттән чаңгыларын ала, битенә бәргән салкынча җил белән хозурланып, юлга кузгала. Ун чакрым араны 40 минутта үтә. Сүз дә юк, яшь чак түгел, ул вакыттагы рекордларны кабатлап булмый: күптән түгел Зариповка 65 яшь тулды. Әмма дәрт-дәрман әле җитәрлек. Вахтанг Кикабидзе җырлаганча: елларым – байлыгым минем. Монысы, һичшиксез, хактыр!

Студент еллары күңелле һәм көчле ташкындай бик тиз уза. Яшь белгеч – терлекчелек тармагын механикалаштыру буенча инженер Марат Зарипов Балтачта, Ленин исемендәге колхоз фермасындагы җиһазларны күздән кичерә. Хуҗалык рәисе



Биш елга якын гомерен Марат Зарипов (фотода сулдан беренче) Балтач районы Ленин исемендәге колхозга бирә (1976 елның көзе).

## БЕЛЕШМӘ

**Зарипов Марат Хәйевич,** *1950 елның 2 ноябрендә ТАССРның Балтач районы Балтач авылында туган. Армиядә хезмәт иткәннән һәм Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаганнан соң, 1976–1980 елларда ТАССРның Балтач районы Ленин исемендәге колхозда механикалаштыру буенча инженер, баш инженер булып эшли. 1980–1985 елларда – Балтач районы Калинин исемендәге колхозда инженер-механик, колхоз рәисе. 1985–1987 – КПССның Балтач райкомы икенче секретаре. 1987–1991 – Балтач район Советы башкарма комитеты рәисе. 1991–1999 – Балтач районы хакимияте башлыгының беренче урынбасары. 1999 –2012 – ТРның Балтач районы хакимияте башлыгы. 2000–2004 һәм 2012 –2014 – ТР Дәүләт Советы депутаты, 2014 елдан башлап бүгенгәчә – ТР Газлаштыру, энергия саклау технологияләре һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды генераль директоры киңәшчесе.*

**Фронтовик әтисе улына ниләр сөйләп, нинди дәлилләр китергәндер – бу хакта гоманларга гына кала. Әмма әлеге сөйләшүдән соң, Балтач егете Марат Зарипов үзенең хыялын үзгәртә, соңрак ачыкланганча, унөч буын ата-бабалары тир түккән туган җирдән аерылмаска карар кыла. «Кайда туган, шунда яраган» дигән әйтем нәкъ менә аның хакындадыр.**

Нәфыйк Әхәт улы Әхәтов аның янәшәсендә атлый – киңәшләрен биреп бара. Марат, сизәм, киләчәктә сиңа, тимерләр боргалаудан тыш, терлекләр белән дә эш итәргә, кешеләр белән дә идарә итәргә туры киләчәк әле, янәсе. Ә кадрлар белән эшләү – нәзберек мәсьәлә, барысын да алар хәл итүен онытма. Кешене җаваплы вазыйфага билгеләгәнче, аның нәсел-нәсәбе нинди булганлыгын тикшер.

– Нәфыйк Әхәтовичтан күп нәрсәгә өйрәндем, аның кул астында әйбәт мәктәп уздым, – дип сөйли Марат Зарипов. – Ул мине кешеләр белән эшләргә өйрәтте, җитештерү серләренә төшендерде.

Маратны тиз арада баш инженер дәрәҗәсенә күтәрәләр, институт тәмамлавына дүрт ел узгач, Калинин исемендәге колхозга рәис итеп куялар. Ул үзенең җитәкче вазыйфасындагы беренче эш көнен әлегәчә яхшы хәтерли. Элеккеге рәис Филсур Хәкимов белән, машинага утырып, фермалар, басуларга кагылалар: берсе эшен тапшыра, икенчесе кабул итә. Август ае, кызу урак өсте, эшнең бик тыгыз мәле. Марат Хәйевич барысын да күңеленә сеңдереп бара, районда уртакул саналган бу хуҗалыкның бөтен «авырткан җирләре», проблемалары аңа болай да билгеле. Ә менә аны ни рәвешле алдынгылыкка чыгарырга, яңача эшләргә ничек мәҗбүр итәргә, бу җәһәттән Зариповның башында уй-фикерләр күптәннән бөтерелә. Рәис кәнәфиенә утыргач, шуларны гамәлгә ашыру мөмкинлеге туа.

Марат Хәйевич эшкә баштанаяк чума, хәтта әлеге кызу август аенда үзенә беренче баласы – улын бүләк иткән сөекле хатыны – Фәйрүзәсе янына бала тудыру йортына хәл белергә дә нибары бер генә мәртәбә барырга өлгерә. Фәйрүзә Фаиловна ул чакта Маратның урып-җыюны, терлек азыгы җитмәүне һәм башка шундый нәрсәләрне сылтау итеп аклануын бүген дә



«Районның социаль проблемаларын хәл итүдә бик максатчан эшләдек», – дип искә төшерә Марат Зарипов.



Халыклар Дуслыгы орденын Марат Зарипов Минтимер Шәймиев кулыннан 2008 елда ала.



Марат Зарипов өч мәртәбә — 2003, 2007 һәм 2010 елларда — Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек була.

**Хуҗалык рәисе Нәфыйк Әхәт улы Әхәтов аның янәшәсендә атлый – киңәшләрен биреп бара. Марат, сизәм, киләчәктә синә, тимерләр боргалаудан тыш, терлекләр белән дә эш итәргә, кешеләр белән дә идарә итәргә туры киләчәк әле, янәсе. Ә кадрлар белән эшләү – нәзберек мәсьәлә, барысын да алар хәл итүен онытма. Кешене җаваплы вазыйфага билгеләгәнче, аның нәсел-нәсәбе нинди булганлыгын тикшер.**

елмаеп искә төшерә. Ә улын кулына алгач, сөенечтән иренең күзләре балкый. Айрат көчле, баһадир егет булып үсә. Хәзер ул эшмәкәр, Казан янәшәсендәге Чабакса бистәсендә яши. Марат Хәйевич улының уңышларына сөенеп яши, гаиләләре өчен традицион булган чаңгыны яраттыра алмавына гына көенә әзрәк. Аның каравы Айрат бодибилдинг белән шөгыльләнә һәм яхшы уңышларга ирешә. Марат Зариповның Алия исемле кызы һәм дүрт оныгы да бар. Балтачтагы төп йортка барысы да кайтып төшкәч, өйдә күңелле ыгы-зыгы башлана, бергәләп шау-гөр киләләр.

Марат Зарипов Калинин исемендәге колхозга биш ел рәислек итә, аннан соң да бирелә намуслы хезмәт куяр иде әле ул, мөгаен. Әмма 1985 елда аны Балтач райкомының икенче секретаре итеп сайлыйлар, ә беренчесе – бүгенге вице-премьер, ТРның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Готыф улы Әхмәтов була. 1978 елда ук, Казан ветеринария институтын тәмамлап ике ел узуга, Әхмәтов Балтач районының «Алга» колхозында рәислек итә башлый. Ул үзен бик оста оештыручы, талантлы җитәкче итеп күрсәтә. Зарипов, күрше колхозларның рәисләре булып эшләгән чагында, юлларының даими рәвештә кисешеп торуын искә төшерә. Икесе дә физик яктан көчле, чыдам, азу ярган спортчылар. Әхмәтов көрәш белән мавыга, хәтта Балтач районы батыры була. Шунлыктан яшь рәисләрнең уртак сүзләре күп була, уңышка ирешү юллары буенча да серләре килешә. Авыр хәлләр килеп туганда ярдәмләшәләр, гаиләләре үзара бик дус була, бәйрәмнәрне бергәләп үткәрәләр. Әхмәтов теләсә кайсы коллективның сөйкемле сөяге, аның белән аралашу һәрвакытта җиңел һәм рәхәт була.

– Яшьлегебезнең кайнап торган чагында, якты киләчәк хакында хыялландык. Адашым ул чакта ук үз өстендә эшли белүе белән таң калдыра иде, – дип искә төшерә Марат Хәйевич. – Бер генә фактны алып үтик: Марат Готыфович татар мәктәбен тәмамлаган, әмма ул үз алдына рус телен туган теле кебек үк бик яхшы итеп үзләштерүне максат итеп куйган һәм шуңа ирешкән дә! Хәзер ул аудитория алдында чыгыш ясаган чагында, беркем дә моны сизми. Ул һәрвакытта да кеше алдына чыгып сөйләргә бик нык әзерләнә. Ә чыгышларын тыңлап туймассың! Кызганычка, мин алай ук булдыра алмыйм...

Хәер, бу сүзләрне ул артык тыйнаклыктан гына сөйли. Чынлыкта Марат Зарипов – бик максатчан, зур мөмкинлекләргә, биниһая тормыш егәренә ия, кешеләр белән бер дигән итеп эшли белүче шәхес. Марат Хәйевичның 1987 елда ук Балтач районы башкарма комитеты рәисе булып сайлануы очраклы хәл түгел. Зарипов җәмгысе 15 ел Әхмәтов белән иңен иңгә куеп эшли.

– Марат Готыфович җитди һәм бик таләпчән җитәкче булса да, миңа аның белән эшләве рәхәт булды. Аның һәр нәрсәдә дә үземә ышаныч күрсәтүенә чиксез рәхмәтлемен. Ул чакта районда проблемалар баштан ашкан иде. Шуларның иң зурысы – газ кертү, без аны бергәләп хәл иттек. Республикада беренче булып башкарып чыктык! Балтач районы үзенең торак пунктларына зәңгәр ягулыкны 1985 елда ук кертә башлады, авылларны тулысынча газлаштыруны 1999 елда тәмамладык. Гомумән, районның социаль проблемаларын хәл итүдә бик максатчан эшләдек. Әйтик, юлларны асфальтлау белән ныклап шөгыльләндек. Соңрак, үзем район башлыгы булгач, кул астымдагыларга ышаныч белән карау, мөстәкыйльлеккә хәерхаһлык күрсәтү кебек Әхмәтовтан өйрәнеп калган принципларны кулландым.

1999 елның маенда Марат Әхмәтов ТР Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры итеп билгеләнә. Ә аның хезмәттәше һәм ышанычлы ярдәмчесе Марат Зарипов Балтач районын җитәкли башлый. Ул нәкъ менә чәчү өстенә туры килә, әмма Зарипов өчен игенчеләрнең язгы мәшәкатьләре – электән үк җайга салынган гадәти эш булып санала. һәр хуҗалык рәисе үз урынында, нәрсә эшләргә кирәклеген бик әйбәт белә. Шулай булгач, чәчүне дә җитди авырлыкларсыз тәмамлыйлар.

һәм янәдән, инде ничәнче мәртәбә, Марат Хәйевич әтисенең акыллы киңәшен искә төшерә: читтә олтан булганчы, туган җирендә солтан бул. Туган җире юкка гына аны үзендә калдыр-

**Кыш җитеп, җиргә кар ятуга, Марат Хәйевич хәзер дә келәттән чаңгыларын ала, битенә бәргән салкынча җил белән хозурланып, юлга кузгала. Ун чакрым араны 40 минутта үтә. Сүз дә юк, яшь чак түгел, ул вакыттагы рекордларны кабатлап булмый: күптән түгел Зариповка 65 яшь тулды. Әмма дәрт-дәрман әле җитәрлек!**

маган. Язмышында Балтачта яшәргә, туган авылына һәм районына яңа сулыш өрергә, авыл хуҗалыгын ныгытырга, аны яңа рельсларга куеп, уңышка ирешергә дип язылган булган, күрәсең.

Хәзер Марат Зариповның көне иртәнге биштә башлана. Ә район белән җитәкчелек иткән чагында, чәчү яки урак өстендә, ул бу вакытта инде әллә кайчаннан аяк өстендә булган, хуҗалыкларны әйләнеп чыккан, барысын да күздән кичереп, төпле киңәшләрен биргән. Дүшәмбе көннәрендә иртәнге сигездә – планерка.

– Гомумән, кешеләргә артык каты таләпләр куеп, үзәкләренә үтмәдем, иртәнге алтыда эшкә килергә мәҗбүр итмәдем, – дип сөйли Марат Хәйевич. – Планеркалар – атнага бер мәртәбә. Кешеләргә ышаныч белдердем, аларның мөстәкыйльлек күрсәтеп эшләүләрен, утырышларда вакытларын уздырмауларын хупладым.

Балтач районының җир биләмәләре җыйнак, чәчүлек мәйданнары нибары 71 мең гектар, шуның өстенә, уңдырышлы катламы да түбән. Ә балтачлылар, җирләрен сыйфатлы итеп эшкәртеп, аның турында тиешенчә кайгыртып, мул уңыш алырга өйрәнгән. Мәйданнар җитмәгәнгә күрә, биредә җир нигездә терлекчелеккә хезмәт итә, мал азыгы, фураж әзерлиләр.

Электән җирле халык терлекчелек белән шөгыльләнгән. Зарипов нәкъ менә шуңа исәп тоткан, сөтчелекне дә, ит җитештерүне дә максат итеп куйганнар. 2000нче еллар башында ук Балтач районы савымчылыкта рекордлы нәтиҗәләргә ирешә – һәр сыердан елына 5әр мең кг сөт савып алын. Горурланырлык күрсәткеч! Ә хәзер күпме сөт җитештерелгәнен үзегез санап чыгарыгыз: райондагы кумәк хуҗалыкларда – 7760 баш савым сыеры исәпләнә, шуңа өстәп, ШЯХларда – 15 мең.

Тотрыксыз 90нчы елларда, гадәти икътисадый элемтәләр өзелеп, предприятиеләр күпләп ябылып, авылда кумәк хуҗалыклар таркалган чорда, Балтачта элеккеге елларның уңай тәҗрибәсеннән ваз кичәргә ашыкмаганнар. Вакыт сынавы узган, табышлы колхоз, совхозлары ничек бар, шулай калдырганнар, бары тик атамалары гына үзгәргән, асылы элеккегечә сакланган, гомуми җыелышлар, халык җыеннары юкка чыкмаган. Колхозчылар җир пайлары алып, терлек азыгы белән тәэмин ителгән.

Терлекчелекнең асыл мәгънәсен аңлаган балтачлылар бүген дә ШЯХларда күп мал асрый. МЭТ икән – 10 йә 5 баш ул, кимендә – 3. Бер сыер тотудан мәгънә юк, табыш китерми.

– Хәер, без райондагы ШЯХларны да мал азыгы белән тәэмин иттек, бүген дә шулай, – дип сөйли Марат Хәйевич. – Алар бик көчле. Сүз дә юк, сөт сатып алу бәяләренең түбән булуы – гомуми проблема, әмма үз вакытында бу юнәлештә максатчан көч куйган идек. Эшнең асылы шуннан гыйбарәт: ШЯХлар саткан сөтнең сыйфаты бик түбән иде. Ана су кушалар, чисталыгы ташка үлчим. Кешеләр еш кына: үземә түгел ич, бигүк тырышмасаң да ярый, начаррагын тапшырырга була, ярамаган тагын сатарга, дип фикер йөртте. Әлеге проблеманы хәл итү белән ныклап шөгыльләнеп, максатыбызга ирештек. Алардан җыелган сөт бары тик беренче сорт белән генә сатыла башлады. Терлекчелектә ит җитештерүнең үзенчәлекләре, үз кагыйдәләре бар. Нәселле таналар саттык, бик отышлы гамәл, ә үгезләрне иткә симерттек. Колхозларыбызда дуңгызчылыкны җәелдердек, малларның башы саны 45 меңгә җитте (плюс 10 меңе – халыкта), 15–20 мең баш сарык асрадык. Кызганычка, хәзер эшләр алай ук сөенечле түгел. Элеккеге баш саны юк инде. Сәбәбе Россиядәге аграр сәясәтнең хилафлыгына бәйле. Хәер, дуңгызчылыкны аякка бастырырга бер-ике ел җитә, ә сөтчелек тармагына, аз дигәндә, дүрт ел сорала.

Марат Зарипов Балтач районы белән 13 ел идарә итә. 2012 елда ТР Дәүләт Советы депутаты булып сайлана, шунда даими эшкә күчә. Район дилбегәсен якташына, республикага танылган «Татарстан» колхозы рәисе Рамил Нотфуллинга тапшыра. Марат Хәйевич ике елдан артык, ул чакта Экология, табигый байлыклардан файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетын җитәкләгән Валерий Васильев командасында эшли.

...Тулыканлы тормыш белән яшәгән һәркемнең сөенеч китерүче, кирәк чакта киеренкелектән арынып хәл җыярга ярдәм итүче үз экологик почмагы булырга тиеш. Ә Марат Зарипов үзенең җир кишәрлегендә эшләп юана.

– Бакчада казынырга яратам, – ди Марат Хәйевич уңайсызланган кебек итеп. – Яшелчәләрне үзем карап үстерәм, чәчәкләрне – хатыным. Җирдә эшләгәндә рәхәтлек тоям. Утырту, карап үстерү, уңыш җыю сөенеч китерә. Җыйнаграк кына теплицам бар, хәер, шактый зур ул... Хатыным нигә шулчаклы күп итеп үстерәсең, ашап бетерә алмыйбыз бит, дип ачулана. Чыннан да, чөгендер белән кишердән башлап, борыч һәм кабакчыкларга чаклы – базда яшелчәнең барысы да бар. Бәрәңге белән суганны сатып алмыйбыз, үзебезнеке җитә. Кыярны майда ук ашый башлыйбыз, соңгы уңышын октябрьдә җыйдым. Помидорлар да суыкка чаклы тора. Бакча җиләгенең соңгысын кар төшкәндә җыйдым. Ул да майдан башлап уңыш бирде. Балалар, оныклар кинәнеп ашый. Кишер кетердәткәннәрен карап торуы рәхәт...

Еллар дәвамында акыл туплаган, үзен тулысынча эшкә багышлаган зирәк кешенең бәхете менә нәрсәдә икән дип әйтәсе килә. Көндәлек хезмәт киеренкелегеннән арынып, ял итәр вакыты җиткән, тормышының рәхәтен күреп яшә кебек. Тик Марат Хәйевич башкачарак уйлый:

– Сәламәтлек барда, эшлим әле, – ди ул.

Бүгенге көндә ул – ТР Газлаштыру, энергия саклау технологияләре һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фондының генераль директоры Җәүдәт Миңнеахмәтовның киңәшчесе. Балачакта әтисе, остазлары өйрәткәнчә, эшенә җаваплы карый.



Хәләл җефете белән бергә...




# НУРЛАТ районы: үсеш стратегиясе

**Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ тексты.**
**Фотолар Андрей ТИТОВТАН, шулай ук Нурлат муниципаль районының матбугат хезмәтеннән алынды.**

НУРЛАТКА БОЛЫТЛЫРАК, ТОМАНЛЫ ИРТӘДӘ КИЛЕП КЕРДЕК. ӘММА КӨЗГЕ ҺАВА ТОРЫШЫНЫҢ КӨЙСЕЗЛЕГЕ ГЕНӘ МИНЕМ БИРЕГӘ СОҢГЫ МӘРТӘБӘ КИЛЕП КИТҮЕМНӘН СОҢ ШӘҺӘРНЕҢ СИЗЕЛЕРЛЕК МАТУРЛАНУЫН КҮРЕРГӘ КОМАЧАУЛАМАДЫ. РАЙҮЗӘКТӘ ЯҢА КҮПКАТЛЫ БИНАЛАР ҺӘМ ШӘХСИ ТОРАК ЙОРТЛАР КАЛКЫП ЧЫККАН, СКВЕРЛАР, ПАРКЛАР ПӘЙДА БУЛГАН, БАЛАЛАРГА УЕН МӘЙДАНЧЫКЛАРЫ ТӨЗЕЛГӘН, ТӨЗЕКЛӘНДЕРЕЛГӘН ИШЕГАЛЛАРЫ КҮБӘЙГӘН, ЯҢА КИБЕТЛӘР, КАФЕЛАР АЧЫЛГАН, ЮЛ ҺӘМ СОЦИАЛЬ-МӘДӘНИ ИНФРАСТРУКТУРА ЯХШЫРГАН.

Узган җәйдә Нурлатта реконструкциядән соң Халыклар дуслыгы йорты яңадан ишекләрен ачты. Ачу тантанасында республика башлыгы Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Ә Халыклар бердәмлеге көнендә тантаналы шартларда күпфатирлы ике яңа йортка күченделәр. Аларның берсе – гражданнарны тузган торактан күчерү, икенчесе ятим балаларны торак белән тәэмин итү программалары кысаларында сафка баскан. Агымдагы ел ахырында райүзәктә тагын өч күпфатирлы йорт сафка басачак, аларга авария хәлендәге йортларда яшәүчеләрне күчерәчәкләр.

### КИҢ КОЛАЧЛЫ ТӨЗЕЛЕШ

Нурлат үзе генә түгел, бөтен район заманча рәвешкә керә. Соңгы өч елда муниципаль берәмлектә 3 күпфункцияле үзәк, 10 спорт мәйданчыгы, модульле 6 ФАП, 2 участок ветеринария пункты, участок инспекторлары өчен 4 йорт, 2 балалар бакчасы, 20 чакрымнан артыграк юл төзелгән, 70 мең квадрат метр торак кулланылышка тапшырылган. Шул ук вакыт эчендә 38 күпфатирлы йорт, 12 гомумбелем, 1 коррекция мәктәбе, «Елга аръягы» балаларны сәламәтләндерү лагере, 4 балалар бакчасы, 28 ФАП, 2 табиблык амбулаториясе, бер участок хастаханәсе һәм башка әһәмиятле социаль объектлар капиталь төзекләндерелгән, 30дан артык торак пунктта урамнарны яктырту яңадан торгызылган, 50 чакрымга якын юл төзекләндерелгән.

– Бүгенге көндә 27 Президент программасында катнашабыз, – дип сөйли Нурлат районы башлыгы Равил Кузюров. – Алар ҖҮИ органнарына җирле әһәмияткә ия күпсанлы мәсьәләләрне уңай хәл итү мөмкинлеге тудыра, нәтиҗәдә, кешеләрнең хакимияткә ышанычы арта, халыкның кәефе күтәрелә, социаль тотрыклылык яхшыра. Сентябрьдә узган Татарстан Президентын һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына депутатлар сайлаулар моның ачык мисалы. Районның социаль проблемаларын хәл итүгә нефтьчеләр зур ярдәм күрсәтә. Әйтик, соңгы ике елдан артыграк вакыт эчендә, «Татнефть» компаниясе район үсешенә 100 миллион сум чамасы инвестиция кертәкән. Әлеге акчалар нигездә юл төзелешенә һәм Нурлатның торак фондын яңартуга тотылган.

Узган елдан башлап, үзара салым программасы кысаларында, нурлатлылар да үзләре яшәгән территория үсешенә



Нурлатта Халыклар дуслыгы йортын ачу тантанасы.

**Нурлат районының 26 авыл җирлегендә җәмгысе 59,5 мең кеше яши, нигездә татарлар, руслар, чувашлар. Агымдагы ел нурлатлылар өчен юбилей елы. Ул 1930 елда оештырылган булган, әүвәле Октябрь районы дип йөртелгән, ә 1997 елда атамасы Нурлатка үзгәртелгән.**

хәл кадәренчә өлеш кертә. Быел районда, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен, үзара салымнан һәм республика субсидияләреннән өстәмә рәвештә 12,2 млн сум акча тупланган. Шуның 1 миллион сумы Якушкино, Абрыскино һәм Салдакай авылларын үзенә берләштергән Якушкино авыл җирлеге өлешенә туры килә. Әлеге акчаларга муниципалитетның беренче ике торак пунктындагы зират коймаларын яңартырга керешкәннәр.

– Үзара салым акчаларын төрле якка таратмыйбыз, «тәлинкә буенча сыламыйбыз», ә аерым бер торак пунктның көнүзәк проблемаларының иң әһәмиятлесен хәл итүгә юнәлдерәбез, – дип сөйли авыл җирлеге башлыгы Хасибулла Хәмидуллин. – Мәсәлән, былтыр Салдакайдагы ике зиратның коймаларын тәртипкә китергән идек. Менә быел Якушкино белән Абрыскинодагы мәңгелек йокы урынын төзекләндерәбез. Киләсе елда үзәк утардагы тагын бер зират биләмәләрен тәртипкә салырга, шулай ук барлык зиратларда хуҗалык йортлары төзергә ниятлибез. Иң мөһиме, программа гына гамәлдән чыгарылмасын.

Республика программалары кысаларында, Якушкино авыл җирлегендә киң колачлы эшләр башкарылган: Салдакай һәм Абрыскинода урам утлары челтәре яңартып төзекләндерелгән, соңгысында вак таштан яңа юл пәйда булган. 2012 елда ачылган Якушкино күпфункцияле үзәгендә дә эшсез ятмыйлар. Моннан тыш, быел муниципаль берәмлек авыл җирлекләренә ярдәм итүгә тәгаенләнгән республика грантын откан. 1 миллион сумга бөтен кирәкле җиһазлары булган трактор сатып алырга җыеналар. Хасибулла Хәмидуллин әйтүенчә, яңа техника кышын урамнарны кардан чистартуда, чүп-чарны полигонга ташуны оештыруда аларның төп ярдәмчесенә әверелергә тиеш.

## ЮБИЛЕЙНЫ КАРШЫЛАП

Нурлат районының 26 авыл җирлегендә җәмгысе 59,5 мең кеше яши, нигездә – татарлар, руслар, чувашлар. Агымдагы ел нурлатлылар өчен юбилей елы. Ул 1930 елда оештырылган булган, әүвәле Октябрь районы дип йөртелгән, ә 1997 елда атамасы Нурлатка үзгәртелгән.

Муниципаль берәмлек үзенең 85 еллыгын шактый әйбәт социаль-икътисадый күрсәткечләр белән каршылый. 2015 елның 9 аенда биредә 13 миллиард сумлык эш башкарылган, товар җитештерелгән һәм хезмәт күрсәтелгән, бу, узган елның шул чордагысы белән чагыштырганда, 118,3 процентны тәшкил итә. Әлеге вакыт аралыгындагысы белән чагыштырып караганда, сәнәгать җитештерүе индексы 2,7 процентка арткан, ул 104,4 процент тәшкил итә. Элеккедән килгән гадәт буенча, район икътисадына саллы өлеш кертүче җирле нефть чыгару предприятиеләре файдалы казылмалар табу күләмен арттыру темпларын саклап калган. Бары тик беренче яртыеллыкта гына да алар тарафыннан 1,2 миллион тонна нефть чыгарылган, әлеге күрсәткеч, узган елның шул чордагысына караганда, 1,1 процентка зуррак. Район икътисады авыл хуҗалыгына тыгыз бәйләнгән. Биредәге басуларда 7 авыл хуҗалыгы предприятиесе хезмәт куя. Шуларның иң эреләре – «Көньяк» агрофирмасы һәм «Сөләйманов» КФХ. «АгроИнвест» ИК» ЯАҖнең бүлендек предприятиеләре җирле чәчүлек мәйданнарының яртысын эшкәртә, муниципалитетта сөт җитештерү күләменең нигезен тәшкил итә. Болардан тыш, районда 43 гаилә фермасы гамәлдә, аларның 20се югары технологияле, шулай ук 9,5 мең шәхси ярдәмче хуҗалык исәптә. Бүгенге көндә районның бөтен төрдәге хуҗалыкларында мөгезле эре терлек санының артуы күзәтелә. Быел шәхси



Равил Кузюров Нурлат районын 2013 ел ахырыннан җитәкли башлады.



Нурлатта яңа йортлар пәйда була.



«Авылда яшәп, терлек асрарга куркып тору – гафу ителмәслек хәл», – дип саный Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы Илнур Хәнәфиев.



Нурлатның Тимерьюлчылар микрорайонындагы 9нчы ТИҮндә җыелыш.

хуҗалыкларда гына да МЭТнең баш саны 259 га күбәйгән.

– Авылда яшәп, терлек асрарга куркып тору – гафу ителмәслек хәл, – дип сөйли күптән түгел генә Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы итеп сайлап куелган Илнур Хәнәфиев. – Безнең алты торак пунктында бүгенге көндә 962 баш МЭТ исәпләнә, шуның өчтән бере – сыерлар. Шуның өстенә, савым сыерлары көтүендәге баш саны буенча без районда беренче урында. Өчәр сыер асраучы шәхси хуҗалыклар бар, ә кайберләренең абзарында уннан артык сөтбикә. Мәсәлән, Илназ Дәүләтшин утарында алар 13әү, ә МЭТнең гомуми саны – 25 баш.

Җирлек башлыгының үз мал абзары да игътибарга лаек. МЭТләре генә дә 28 баш, шуларның яртысы – савым сыеры. Көтмәгәндә терлекләре чирләп китсә дә, Илнурга ярдәмне читтән эзлисе юк, чөнки төп һөнәре буенча ул – мал табибы, ә бу елның көзенә чаклы ул район ветеринария идарәсендә эшләгән. Илнур Хәнәфиев терлек азыгын 50 гектарлы пай җирендә әзерли. Савым сыерларын һәм ана кәҗәләрне тотуга түләнә торган республика субсидиясе авыл кешесенә мал азыгы базасын сизелерлек дәрәҗәдә ныгытырга булышкан. Районда быел әлеге максатларда җәмгысе 13,3 млн сум акча таратылган.

ШЯХ үстерү максатыннан авылда яшәүчеләргә ташламалы кредитлар бирү мәсьәләсенә килгәндә, соңгы тугыз ел эчендә әлеге программа кысаларында нурлатлыларга гомуми күләме 3,4 миллиард сумлык 5,2 мең займ бирелгән. Халыкның кредит проценты түләүләренә 110,4 миллион сум субсидия кайтарылган. Моннан тыш, 2014 елда ШЯХларында биш баштан артыграк савым сыеры асраучыларга җирле бюджет хисабына 67 савым аппараты бирелгән. Җәмгысе 1 миллион сумлык техник ярдәм күрсәтелгән.

Районның авыл хуҗалыгы нык үсеш алган үсемлекчелек тармагына ия. Биредә бәрәңге үстерәләр, мал азыгы җитештерәләр, бөртекле ашлык, һәм техник культуралар игәләр. Соңгылары арасында шикәр чөгендере аерым бер урын били. Быел аны үстерүгә 6,5 мең гектарлы сөрүлек җир бүленгән булган. Татлы тамырның тулаем җыемы 203 мең тонна, һәр гектарының уртача уңдырышлылыгы 320 центнер тәшкил итә.

Бүгенге көндә Нурлат шикәр заводында яңа уңышны эшкәртүнең бик кызу барган чагы. Предприятие җитәкчелегенең оптимистларча фаразына караганда, әлеге эшләрнең декабрьдә тәмамлануы көтелә, биредә 250–260 мең тонна татлы тамыразык эшкәртергә ниятлиләр. Заводның милекчесе – «Агро Инвест» ИК» ЯАҖ соңгы ике елда бу предприятие үсешенә 130 миллион сумнан артык финанс чыгымнары тоткан, шуның 51 миллионы аерым бер технологик линияләрне реконструкцияләүгә сарыф ителгән. Нәтиҗәдә, завод бүгенге көндә тотрыклы рәвештә тәүлегенә 2500–2700 тонна шикәр чөгендере эшкәртә ала. Ә киләсе елда әлеге күрсәткечне 3000 тоннага җиткерергә ниятлиләр.

– Без хәзер үзебезнең югалткан позицияләребезне яңадан торгызабыз, – ди предприятиенең генераль директоры Игорь Сагайдак. – Җитди реконструкцияләү алда әле. Һәрхәлдә шуңа бик нык өметләнәбез.

## КЕЧЕ ЭШКУАРЛЫКНЫ «УЯТЫРГА»

Кече һәм урта эшкуарлыкның теләсә кайсы территориянең икътисадын алга җибәрүче локомотив булуы һәркемгә билгеле. Эшкуарлык үсешенә ярдәм күрсәтү йөзеннән, районда Эшкуарларның иҗтимагый советы оештырылган, 2014–2016 елларга исәпләнгән максатчан муниципаль программа гамәлгә ашырыла. Нәтиҗәдә, муниципаль берәмлек җитәкчелеге нурлатлыларның эшлеклелек активлыгын уята алган, соңгы елда районда кече эшкуарлыкның 160тан артык яңа субъекты барлыкка килгән. Әйтик, 2015 ел башында Нурлатның үзендә тузган шиннарны эшкәртү һәм утильләштерү цехы ачылган, ә җәй көне райүзәктә «Сервис хезмәте күрсәтү үзәге» ҖЧҖ – насос-компрессор торбаларын ремонтлау һәм насос җиһазларын диагностикалау цехы үзенең эшчәнлеген җәелдергән. Шушы көннәрдә шәһәрдә нефть сервисының тагын бер кече компаниясе ачылырга тора.

Октябрь ае башына, районда икътисадый яктан актив булган 458 кече һәм микропредприятие, 1090 шәхси эшкуар исәпләнә иде. Нурлатлы Зөфәр Миңнеголов алар арасында моннан сигез ел элек килеп кергән. Соңгы ике елда көн



«Без бүген заводның элеккеге абруен кайтару юнәлешендә эшлибез», – ди Нурлат шикәр заводы директоры Игорь Сагайдак.

**Нурлат районы үсешенең яңа стратегиясе нефть тармагына бәйле булмаган җирле табигый байлыклардан мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк файдалануны күздә тота. Аерып әйткәндә, Нурлатта керамик кирпеч һәм гранит эшләп чыгару буенча завод төзү хакында тугандаш төрек каласы – Джейхан эшкуарлары белән сөйләшүләр алып барыла.**



Тимерлек авыл җирлеге җитәкчесе Владимир Гаврилов.



Якты Күл авылыннан Хәлил һәм Гөлсинә Сатдаровлар гаилә бизнесларын 2009 елда башлаганнар.

итәрлек акчаны ярдырылган такталар сатып һәм заказга агач йортлар салып эшләгән. Быел шулар белән беррәттән, агач эшкәртү белән дә шөгыльләнә башлаган.

– Үзеңә эшләү – җаның телгән эш башкаруның бердәнбер ысулы, – ди эшкуар. – Әмма ничек кенә булмасын, эшкуарлыкның һәркайсына шәхси якын килү сорала…


Красномайский бистәсендә яшәүче бертуган фермерлар: Геннадий һәм Михаил Кирилловлар да аның фикере белән килешә. «Кириллов Г.А.» КФХ бүгенге көндә унга якын җирле эшчене даими хезмәт хакы белән тәэмин итә. Хуҗалыкта 100 баштан артык мөгезле эре терлек асрала, шуларның 75е – савым сыеры. Фермерлар мал азыгын авылдашларыннан вакытлыча файдалануга алып торган 125 гектар сөрүлек җирдә әзерли. Былтыр КФХ ике миллион сум республика гранты откан. Кирилловлар бу акчага үзләренең ике фермасының берсенең түбәсен өлешчә япкан.

Якты Күл авылында яшәүче Сатдаровлар гаиләсе дәүләт гранты ачкасына үз утарларында җыйнак кына сыер абзары төзегән. Сатдаровлар шәхси эшкуарлыкларын 2009 елда ук ачкан булган, Җирле хуҗалык таркалып, шунда ферма мөдире булып хезмәт куючы Гөлсинә һәм ире – терлекче Хәлил эшсез кала ул вакытта. Ун сыердан башлаганнар, ә хәзер аларның савым сыерлары көтүе икеләтә зурайган. Сатдаровлар 104 гектар җирдән файдалана.

– Районның моңарчы файдаланылмаган мөмкинлекләрен ачу, инвестицияләр кертү ягыннан җәлеп итүчәнлеген арттыру, тулаем территориаль продуктта кече эшкуарлыкның өлешен үстерү безнең өчен үзгәрмәс өстенлек саналды һәм шулай булып калачак, – дип сөйли район башлыгы Равил Кузюров. – Сүз дә юк, икътисадыбыз әлегә нефть керемнәренә бик нык бәйле. Әмма без кече эшкуарлыкны урыннан кузгатып җибәрә алдык, киләчәктә уңышларыбызның үсешенә муниципаль сәнәгый мәйданчыклар ярдәм итәр, дип өметләнәбез.

Аларның берсе 2013 елда кыскартуга эләккән Тәрнәче спирт заводы базасында урнаштырылачак. Әлеге мәйданчык кирәкле инженерлык инфраструктурасы белән тулысынча тәэмин ителгән һәм шушы араларда ТР Икътисад министрлыгында аккредитация уза. Районда шуңа параллель рәвештә, федераль мөмкинлекләрне җәлеп итеп, Нурлатның үзендә яңа сәнәгый зона оештыру буенча эш алып барыла.

Нурлат районы үсешенең яңа стратегиясе нефть тармагына бәйле булмаган җирле табигый байлыклардан мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк файдалануны күздә тота. Аерып әйткәндә, Нурлатта керамик кирпеч һәм гранит эшләп чыгару буенча завод төзү хакында тугандаш төрек каласы – Джейхан эшкуарлары белән сөйләшүләр алып барыла. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Инвестицияле үсеше агентлыгы белән берлектә, агач эшкәртү калдыкларыннан агач-полимер композицияле материаллар җитештерү мәйданы ачу мәсьәләсе актив тикшерелә һәм җентекләп өйрәнелә.



Заманча Нурлат.








**Олег ПЛАТОНОВ тексты.**
**Андрей ТИТОВ фотолары.**

# *Унбер «МИН»*

БУА РАЙОНЫНЫҢ ИСКЕ МЕРТЛЕ АВЫЛЫНДА ЯШӘҮЧЕ МАТВЕЕВЛАР ГАИЛӘСЕНДӘ, АЗ ДА ТҮГЕЛ, КҮП ТӘ ТҮГЕЛ, УНБЕР БАЛА ТӘРБИЯЛӘНӘ. ЭЛЕГРӘК ЗУР ГАИЛӘЛӘР (АЕРУЧА АВЫЛЛАРДА) БЕРӘҮГӘ ДӘ ГАҖӘП ТОЕЛМАГАН, БҮГЕН ИСӘ МОҢА МОГҖИЗА ИТЕП КАРЫЙЛАР. ДӨРЕС, ХӘЗЕР ДӘ АВЫЛЛАРДА БИШ, АЛТЫ, ХӘТТА ҖИДЕ БАЛАЛЫ ГАИЛӘЛӘР ОЧРЫЙ. ШУЛАЙ ДА БҮГЕНГЕ КҮЗЛЕКТӘН ЧЫГЫП КАРАГАНДА, МАТВЕЕВЛАРНЫ ГЕРОЙЛАР ИСЕМЛЕГЕНӘ КЕРТЕРГӘ БУЛА. ИҢ ӘҮВӘЛ БАШКА ШУНДЫЙ УЙЛАР ДА КИЛЕРГӘ МӨМКИН: «ЮНЬЛЕ ГАИЛӘ ТҮГЕЛДЕР», «ӘЛЛӘ БЕРӘР СЕКТАДА ТОРАЛАР МИКӘН?» ЛӘКИН БУ ҺИЧ ТӘ АЛАЙ ТҮГЕЛ. МАТВЕЕВЛАР – ГАДӘТИ ҺӘМ БӘХЕТЛЕ ГАИЛӘ, БАЛАЛАР ТАВЫШЫ АЛАРГА БИК КАДЕРЛЕ. БЕЗ УКУЧЫЛАРЫБЫЗГА ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН ШАРТЛАРЫНДА ӘЛЕГЕ ГАИЛӘНЕҢ НИЧЕК ЯШӘВЕ ТУРЫНДА СӨЙЛӘРГӘ БУЛДЫК.

## КРИЗИС БЕЗГӘ КАГЫЛМЫЙ

Буа районының Кошки-Шемяк авыл җирлегендә Матвеевлар гаиләсен белмәгән кеше юк. Кошки-Шемякка дүрт авыл карый – Чуваш Биморзасы, Канава, Кошки-Шемяк һәм Иске Мертле. Соңгы икесен бер генә урам аерып тора. Әлеге күп балалы гаилә Иске Мертледә әллә ни зур булмаган бер йортта яши. Аларны эзләп табарга безгә авыл җирлеге башлыгы Ирина Никитина булышты. Ул бу вазыйфасында дүрт еллап эшли икән, моңа кадәр авыл советында хисапчы булып эшләгән. Матвеевларга бару юлында Ирина Николаевна безне авыл белән дә таныштырды. Бүген андагы 240 йортта 794 кеше яши. Башка авыллардагы кебек үк, шактый искергән өйләр янәшәсендә капкалары сырлап эшләнгән, спутник антенналары беркетелгән хәйран нык йортлар тора. Элек кенә ул авыл халкы мәгълүмат киңлегеннән мәхрүм иде, бүген хәл тамырдан үзгәрде. Йорттагысы начар тота башласа, спутник антеннасы алып куярга була: сыйфаты да әйбәтрәк, каналлары да күбрәк. һәр авылга Интернет кертелгәнен дә исәпкә алсак, мәгълүмат алу өлкәсендә шәһәр белән авыл арасындагы аерма бөтенләй юк дияргә була.

Дөрес, башка авыллардагы кебек үк, бу җирлектә дә, кызганыч, халык саны кими бара. Аларның да

**Авылда әкренләп уңайлылыклар да тудырыла бара. Узган ел, мәсәлән, Кошки-Шемяк урамнарына вак таш җәйгәннәр, хәзер һава начар булганда да машина белән йөрү элекке кебек кыен түгел. Ирина Никитина Татарстанда гамәлгә кергән төрле Президент программалары буенча яңа клуб биналары, юллар төзелешенә өмет итә. Авыл өчен бу бәяләп бетергесез зур ярдәм бит.**

60 проценты тирәсе – пенсионерлар. Яшьләр, эш эзләп, Ульяновскига (ул Казанга караганда күпкә якынрак), республикабыз башкаласына һәм башка ераграк шәһәрләргә китә. Шулай да, Ирина Никитинаның сүзләренә караганда, соңгы елларда күп кенә яшьләр нигезләрен ташлап китми башлаган. Чөнки шәһәрдә фатирга төшеп яшәргә кирәк, ә авылда бөтен нәрсә үзеңнеке. Өстәвенә, әле күптән түгел генә әлеге җирлек территориясендә күпфункцияле мәдәни үзәк ачканнар – буш вакытларында яшьләргә ял итәргә урын бар.

Биредә халык нигездә авыл хуҗалыгында – колхозда эшли. Рәсмиләштерелгән шәхси хуҗалыклар юк, шулай да терлек асраучылар күп. Соңгы елларда сыерларның баш саны арткан, шәхси ярдәмче хуҗалыкларда өч, биш, хәтта сигез сыер тотучылар да бар. Бу ни белән аңлатыла соң? Җавап гади: сөт күпләп сатып алучыларга тапшырыла, аның өчен ай саен «чиста» акча түләнә. Авыл кешеләре өчен бу – икенче хезмәт хакы. Ирина Никитинаның үзенең дә ике савым сыеры бар икән.

Сөтне шәхси эшмәкәр җыя. Аннары аны Буа сөт заводына яисә күрше өлкәгә илтә. Бу ысул белән ун еллап эшлиләр икән инде. Элек сатып алу бәясе түбәнрәк булган, хәзер бераз күтәргәннәр. Шулай да халык бик

**Соңгы елларда күп кенә яшьләр туган нигезләрен ташлап китми башлады. Чөнки шәһәрдә фатирга төшеп яшәргә кирәк, ә авылда бөтен нәрсә үзеңнеке. Өстәвенә, әле күптән түгел генә әлеге җирлек территориясендә күпфункцияле мәдәни үзәк ачканнар – буш вакытларында яшьләргә ял итәргә урын бар.**



Александр Николаевич һәм Елена Николаевнаның бергә яшәүләренә инде 19 ел.



Ирина Никитинаның сүзләренә караганда, соңгы елларда күп кенә яшьләр туган нигезләрен ташлап китми башлаган.

үк канәгать түгел – шәһәрдә сөтнең литры 50 сум тора, ә монда 14тән сатып алалар...

«Эш булса, авыл яши дигән сүз, – ди Ирина Никитина. – Теләге булган кешегә эш һәрвакыт табыла. Юкны бушка уздырып йөрүчеләр бар инде ул, шулай да, тулаем алганда, бездә халык эшчән. Авылдагылар илдә икътисадый кризис баруы хакында белеп тә бетерми, дип уйлыйм мин. Аларга ул кагылмый, чөнки нигездә үзләре үстергән азык-төлек хисабына яшиләр».

## ҮТКӘНГӘ КАЙТУ

Авыл җирлеге башлыгы Ирина Никитина әйтүе буенча, соңгы елларда биредә кызыклы үзгәрешләр күзәтелә – шәһәр халкы авылга күчә башлаган. Әле күптән түгел генә күп балалы өч гаилә, ана капиталыннан файдаланып, авылдан йорт сатып алган. «Аларның берсе Казаннан Кошки-Шемякка кайтып урнашты, – ди Ирина Николаевна. – Биш балалары бар, авылда җәй буе яшәделәр. Бәрәңге, яшелчә утырттылар. Әле бөтенләйгә күченеп бетмәделәр, көзен кире шәһәргә кайтып китәргә туры килде үзләренә. Әниләре әйтә, бөтенләйгә монда гына яшәр идек, ди. Авылдагы өйләренә су кертелгән, канализацияләре бар, газ уткәрәсе генә калган. Шәһәрдә ике бүлмәле фатирлары бар икән, шулай да күңелләре авылда аларның».

Тагын икенче бер күп балалы гаилә дә шушыннан йорт сатып алган. Төпчекләренә әле ике генә ай. Хатыны авылда теркәлгән инде, ире Россия гражданлыгын рәсмиләштереп йөри – ул Таҗикстаннан килгән. Шәһәрдә фатирдан фатирга йөреп туйганнар.

Өченче гаилә бөтенләй авылга табына торган кешеләр булып чыккан. Ирина Никитина сүзләренә караганда, авылның төп халкы үз хуҗалыкларында болар хәтле үк эшләми. Бу чаклы авылга тартылу нидән килә икән, дип кызыксынгач, җирлек башлыгы, мөгаен, яшәү рәвешеннәндер, дип җавап бирде. Авылда ул салмак, җайга салынган.

Авылда әкренләп уңайлылыклар да тудырыла бара. Узган ел, мәсәлән, Кошки-Шемяк урамнарына вак таш җәйгәннәр, хәзер һава начар булганда да машина белән йөрү элекке кебек кыен түгел. Ирина Никитина Татарстанда гамәлгә кергән төрле Президент программалары буенча яңа клуб биналары, юллар төзелешенә өмет итә. Авыл өчен бу бәяләп бетергесез зур ярдәм бит.

## ЭГОИЗМНАН КОТЫЛУ ЧАРАСЫ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов күптән түгел ясаган чыгышларының берсендә бо-

лай дигән иде: «Соңгы елларда республика ирешкән төп казанышларның берсе – туучылар санының артуы. Хәзер гаиләдә өч, дүрт, хәтта биш бала булу сирәк күренеш түгел. Бу кешеләрнең иртәгәге көнгә ышанулары турында сөйли, чөнки Татарстанда моның өчен бөтен нәрсә эшләнә». Соңгы ике ел эчендә Кошки-Шемяк җирлегендә дә өч һәм аннан күбрәк бала булган гаиләләрнең саны сигезгә җиткән. Шулай да унбер балалы гаилә бөтен Буа районы өчен сирәк күренеш.

Матвеевлар йортына килеп җиткәнче үк, күршеләренең һәркайсы, безнең ни йомыш белән йөрүебезне белгәч, әлеге гаилә турында үзләренең фикерләрен белдерергә ашыкты. Николай Дмитриевич бигрәк үзенчәлекле итеп әйтте: «Аларның балалары беркайчан да колониягә эләкмәячәк». Ул үзе Эчке эшләр министрлыгының отставкадагы полковнигы икән, соңгы 18 елда колониядә эшләгән. «Берике, хәтта өч балалы гаиләдә дә балалар күпмедер дәрәҗәдә үзләрен генә яратучан булып үсә. Ә монда алай түгел. Вак-төяктән дә күренә ул. Менә бер кечкенәсе, кулына берничә печенье тотып, урамга чыга. Миңа да бир әле, дисәң, бүтәннәр булса, тыңламас иясә тешләнгәнне сузар иде. Ә бу соңгысы белән дә бүлешергә әзер. Алардан Курчатов яисә Ломоносов чыкмас та, бәлки, әмма менә яхшы, булдыклы кешеләр булып үсәчәкләрендә шик юк. Антоннары, әнә, хәзер үк кул астындагы әйберләрдән самокатлар ясап ята».

Бу гаиләгә карап, күршеләре шундый фикергә килгән: гаиләдә балалар күбрәк булган саен, аларда эгоистлык азрак, өлкәннәргә ихтирам-хөрмәт күбрәк була.

**Күрше-күлән әйтүе буенча, гаилә тату, яман гадәтләре юк. Балалар җәен сыерлар көтә, акча эшлиләр – мәктәп киемнәрен үз хисапларына алырга тырышалар. Мәктәптән кайткач, өсләрен генә алыштыралар да ишек алдына чыгалар – анда һәркемгә эш табыла. Терлек астын җыештырасымы, ян бакчада нидер эшләргә кирәкме... Ярамаган эш белән шөгыльләну исәпләрендә дә юк. «Яхшы тәрбия алалар, эти-әниләреннән күреп, үзләре дә эшкә тартылалар», – дип мактый күршеләре.**



Күрше-күлән әйтүе буенча, гаилә тату, яман гадәтләре юк. Балалар җәен сыерлар көтә, акча эшлиләр – мәктәп киемнәрен үз хисапларына алырга тырышалар. Мәктәптән кайткач, өсләрен генә алыштыралар да ишек алдына чыгалар – анда һәркемгә эш табыла. Терлек астын җыештырасымы, ян бакчада нидер эшләргә кирәкме... Ярамаган эш белән шөгыльләну исәпләрендә дә юк. «Яхшы тәрбия алалар, эти-әниләреннән күреп, үзләре дә эшкә тартылалар», – дип мактый күршеләре. Әти-әниләре үзләре дә беркайчан да боегып яшәми, тормыштан зарланмый. Мондый зур гаилә өчен йортлары гына бәләкәйрәк – шунысы кызганыч.

## ЗУР ГАИЛӘНЕҢ КЕЧКЕНӘ ЙОРТЫ

Өйгә килеп кергәч, тагын бер кат гаҗәпләндек: әниләре Елена Николаевна уникенче баласын табарга җыена икән. Кыш башларына гаилә тагын бер малайга артачак. Монда малайлар кызлардан болай да күбрәк – 6:5. Әтиләре белән әниләренә 43әр яшь. Александр Николаевич өйләнгәндә Елена Николаевнаның беренче ирennән өч кызы була инде. Бергә яши башлауларына да хәзер 19 ел булган. Балаларның кайсына ничә яшь икәнен алар тиз генә әйтеп тә бирә алмадылар – балалар үзләре ярдәмгә килде.

Екатеринага – 23, ул үзе дә кияүдә икән инде, ике бала тәрбияли. Татьянага – 21, ул ире белән Ульяновскида яши, бер баласы бар. Любага – 20 яшь, авылда эшли, Ваняга – 18, хәзерге көндә Ульяновскида укый, аны өйдә сагынып көтеп торалар. Антонга – 16 яшь, Кристинага – 14, Димага – 13, Алексейга – 10, Аняга – 6, Матвейга – 4 яшь, Артемга бер яшь тә ике ай. Инде менә уникенчесе туарга тора. Юкса, Матвеевлар инде өч онык сөяләр. «Ничек инде: синең балаларың энекәшләреңнән өлкәнрәк бит», – дим Екатеринага, гаҗәпләнеп. «Зыян юк, – дип елмая ул. – Аның каравы, һәммәбез бергә. Аерым яшәсәк тә, балалар әби-бабай янына ашкынып торалар. Монда күңелле бит».

Өй эче шау-гөр килеп тора: көлешәләр, уйныйлар, туктаусыз сөйләшәләр. Бер генә ягы җайсыз – урын аз. Болай караганда йорт иркен итеп салынган, әмма мондый зур «команда» өчен барыбер тыгызрак шул.

«Без хәзер торак алу өчен чиратта торабыз. Күп балалы гаилә буларак торакны чиратсыз алу өчен ун бала булуы шарт, – ди Елена. – Ә безнең кызлар балигъ булган дип исәпләнәләр, аларга 18дән артты инде. Һәрхәлдә, безгә шулай аңлаттылар. Уникенче балабыз тугач, эш җайланмасмы, дибез. Әлегә биш һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү программасы буенча чиратта торабыз...»

«Башта, билгеле, шулкадәр балабыз булыр дип уйламаган идем, – дип дәвам итә сүзен Елена. – Беренчесе үле туды. Шуннан үземә сүз бирдем: Ходай күпме бирә, барысын да табачакмын. Шулай булып чыкты да».

Матвеевларның әйтүенчә, балаларны алар беркайчан да авыр мәшәкать итеп кабул итмиләр. «Һәрберсе үзенчә, – ди Александр Николаевич. – Һәркемнең үз холкы. Малайлар тиктормасрак, кыз-

**Әниләре Елена Николаевна уникенче баласын табарга җыена икән. Кыш башларына гаилә тагын бер малайга артачак. Монда малайлар кызлардан болай да күбрәк – 6:5. Әтиләре белән әниләренә 43әр яшь. Александр Николаевич өйләнгәндә Елена Николаевнаның беренче иреннән өч кызы була инде. Бергә яши башлауларына да хәзер 19 ел булган. Балаларның кайсына ничә яшь икәнен алар тиз генә әйтеп тә бирә алмадылар.**



лар әниләренә елыша. Эшләргә күп туры килә инде, билгеле. Хәзер балалар үзләре дә булыша, Лена белән икебезгә генә кыенга туры килер иде».

Алар балаларын кече яшьтән хезмәткә өйрәтеп үстерәләр. Авыл җирендә башкача була да алмый. Монда да кем нәрсә булдыра, шуны эшли.

Елена сыер савучы булып эшли, Александр – колхозда терлекче. Кайчак өстәмә эшләр дә килеп чыга, андыйларына үзе белән өлкән улларын да ала, эшкә өйрәнә торсыннар.

«Балаларга мөмкин кадәр күбрәк бирәсе килә, – ди Елена. – Бездә артыгы була алмый инде, үзебез үстергән бакча һәм асраган терлек исәбенә яшибез. Аның каравы, ит тә, бәрәңге дә, сөт тә – барысы да үзебезнеке».

«Хатыным ипине дә үзе сала, – дип сүзгә кушыла Александр. – Бик тәмле килеп чыга. Ә көн саен баллы чәй эчү өчен ай саен бер капчык (50 кило) шикәр комы кирәк. Арзанга төшсен өчен, берничә дистә гектар җирдә чөгендер үстердек, аннары җыеп алган уңышны җирле шикәр заводында шикәр комына алыштырдык. Сатарга дип берничә баш терлек тә асрыйбыз, хезмәт хакына гына карап яту авыргарак төшә».

«Уку елына әзерләнгәндә (бездә дүрт мәктәп укучысы һәм бер студент) уку-язу әсбаплары өчен генә дә 15 мең сум тирәсе акча кирәк», – дип өсти Елена.

Алар әйтүенчә, дәүләттән ярдәм аз. Җирле хакимияткә дә мөрәҗәгать итеп караганнар, аннан аларны социаль яклау бүлегенә җибәргәннәр. Ә анда матди ярдәм өчен акча юклыгын әйткәннәр, бер айдан килергә кушканнар. «Бу айда документларыбызны кабул итмәделәр, киләсендә кабат җыярга туры киләчәк, – ди Елена. – Аларны юллап тегендә-монда чабып йөрү өчен ул матди ярдәмнең үзе кадәр акча китә. Өстәвенә, вакыт та җиткереп булмый».

**«Без хәзер торак алу өчен чиратта торабыз. Күп балалы гаилә буларак торакны чиратсыз алу өчен ун бала булуы шарт, – ди Елена. – Ә безнең кызлар балигъ булган дип исәпләнәләр, аларга 18дән артты инде. Һәрхәлдә, безгә шулай аңлаттылар. Уникенче балабыз тугач, эш җайланмасмы, дибез. Әлегә биш һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү программасы буенча чиратта торабыз...»**

## МАТВЕЕВЛАР КИҢӘШЕ

Әйе, мондый ишле гаиләне тәэмин итеп тору өчен шактый зур көч кирәк. Шулай да Елена белән Александр балалар тавышыннан башка яшәүне күз алдына да китерә алмыйлар. Берәрсе өйдә булмаса да аларга нидер җитмәгән кебек тоела башлый.

«Җәй көне бөтенебез бергә җыелган чакта бик күңелле була», – ди Елена. «Олыларын өйдән чыгарып җибәрү куркытмыймы соң?» – дигән сорауга ул фәлсәфи җавап бирде: «Акрынлап чыгара барырга кирәк. Укысыннар, кеше булсыннар, тормышта үз урыннарын тапсыннар. Гомер шулай ага инде ул».

«Иң мөһиме, яхшы кешеләр булып җитешсеннәр, бер-берсенә ярдәм итешеп, терәк булып яшәсеннәр», – ди әти кеше. «Әлегә булдыралар кебек, – дип өсти әниләре. – Дәрес хәзерләгәндә без бәләкәенекен генә тикшерәбез, калганнары үзләре тырыша яисә өлкәнрәкләре булыша, тикшерә».

Матвеевлардан бүген ни өчен гаиләләрнең күп бала табарга әллә ни ашкынып тормаулары белән кызыксындым.

«Бер яктан, тормыш җиңелләрдән түгел, – диде Елена. – Икенче яктан, кешеләрнең муллыкта яшиселәре килә. Яшьләр үсәргә тели, фатирның да зуррагына ирешәселәре килә, бала табып тәрбияләү өчен вакытлары калмый. Шәһәрдә фатирга төшү өчен хезмәт хакының яртысы китә. Шуңа күрә күп бала тапмыйлар да. Яшьләргә шундый киңәш бирәсе килә: өч бала булса да табарга кирәк. Аларны гына тәрбияләп, аякка бастырып була». Матвеевларның киңәше шул.



«ТАТАРСТАНДА ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ МУНИЦИПАЛЬ ХАКИМИЯТ ӨЧЕН ИҢ ӘҺӘМИЯТЛЕ ЯҢА ЗАКОННАРГА ҺӘМ НОРМАТИВ АКТЛАРГА, ШУЛАЙ УК ФЕДЕРАЛЬ ҺӘМ РЕСПУБЛИКА ЗАКОННАРЫНА КЕРТЕЛГӘН СОҢГЫ ҮЗГӘРЕШЛӘРГӘ КҮЗӘТҮ ЯСЫЙ.

**«Россия Федерациясе Административ суд эшләре кодексы» 2015 елның 8 мартындагы 21-ФЗ номерлы Федераль законы**

РФ Административ суд эшләре кодексында (РФ АСЭК) РФ Югары суды, гомуми юрисдикциядәге судлар гражданнарның бозылган яки дәгъвалана торган хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен, оешмаларның бозылган яки дәгъвалана торган хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау турында административ эшләрне, шулай ук административ һәм башка гавәми хокук мөнәсәбәтләренә бәйле барлыкка килә торган һәм дәүләт вәкаләтләрен, башка гавәми вәкаләтләрне башкаруның законлылыгына һәм нигезле булуына суд контролен гамәлгә ашыру белән бәйле башка административ эшләрне, шул исәптән норматив хокукый актларга дәгъва белдерү, дәүләт хакимияте органнарының, башка дәүләт органнарының, хәрби идарә органнарының, җирле үзидарә органнарының, вазыйфаи затларның, дәүләт хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъва белдерү турында, гражданнарның сайлау хокукларын һәм референдумда катнашу хокукын яклау һ.б. турында административ эшләрне караганда һәм хәл иткәндә административ суд эшләрен башкару тәртибе җайга салына.

РФ АСЭК нигезләмәләре административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча суд эшләрен башкаруга, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан түләттерелгән акчаларны дәгъва белдерүчегә кайтару турындагы эшләр буенча суд эшләрен башкаруга кагылмый. Документ (кайбер нигезләмәләреннән тыш) 2015 елның 1 сентябреннән гамәлгә керә.

**«2016 елга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары проектларын төзү һәм раслау үзенчәлекләре турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексындагы аерым нигезләмәләрнең гамәлдә булуын туктату турында» Федераль законның 3 статьясын үз көчен югалткан дип тану хакында» 2015 елның 30 сентябрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон**

Барлык дәрәҗәдәге бюджетларның проектлары вакытлыча бары тик бер елга төзеләчәк. 2016 елның 1 гыйнварына кадәр Россия Бюджет кодексының барлык дәрәҗәдәге бюджетларның һәм бюджеттан тыш фондларның проектларын план чорына төзү һәм раслауга кагылышлы нигезләмәләренең (социаль-икътисадый үсеш фаразыннан, бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәте юнәлешләреннән тыш) гамәлдә булуы туктатылды. Моның белән бергә муниципаль берәмлекләр шулай ук муниципаль берәмлекнең урта сроклы финанс планын эшләргә һәм расларга хокуклы.

Бюджет проектын Дәүләт Думасына кертү сроклары да вакытлыча (2016 елның 1 гыйнварына кадәр) чигерелде, әйтик, ул РФ Бюджет кодексы буенча 1 октябрьдән дә соңга калмыйча дип билгеләнгән булса, хәзер 2015 елның 25 октябреннән дә соңга калмыйча дип расланды. Моңа бәйле рәвештә Россия дәүләт программалары проектларын Дәүләт Думасына кертүнең 2015 елның 1 октябренә кадәрге срогы турындагы вакытлыча нигезләмә кире алынды.

Бюджетларның һәм фондлар бюджетларының региональ (муниципаль) проектларын кертү сроклары турындагы нигезләмәләрнең дә гамәлдә булуы туктатылып тора. Тиешле хакимиятләр срокларны үзләре билгеләргә хокуклы.

Бюджет акчаларын алучыларның 2016 елдан соң түләнәчәк шартнамәләрне бюджет йөкләмәләренең элек бирелгән лимитларына тәңгәл итеп төзү хокукын саклап калырга хәл ителгән. 2017 елда түләнергә тиешле шартнамәләр, күрсәтелгән елга лимитлар аларны алучыга бирелмәсә дә, өзелмәячәк.

Моннан тыш, производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү турындагы законның гамәлдә булуы план чорына ими-

ният тарифларын билгеләү өлешендә, шулай ук Россиядә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турындагы законның гамәлдә булуы план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау өлешендә туктатылып тора.

Бюджетның җыелма бюджет статьяларына үзгәрешләр 2015 һәм 2016 елларга бюджет турындагы законнарга үзгәрешләр кертмичә генә кертелергә мөмкин дип билгеләнгән. Мондый очраклар аерым алып күрсәтелгән. Әйтик, региональ бюджетларга кредитлар бирү буенча бюджет ассигнованиеләренең алдан билгеләп куелган күләмен арттыру.

Федераль закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә. Моның белән бергә җыелма бюджет статьяларына регионнар өчен кредитлар буенча ассигнованиеләр арттырылуга бәйле рәвештә үзгәрешләрне 2015 елда бюджет турындагы законга үзгәрешләр кертмичә генә кертү хокукы 2015 елның 13 июленнән (2015 ел бюджеты турында законга кертелгән төзәтмәләр үз көченә кергән көннән башлап) барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

## «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 24.5 статьясына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 77 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 октябрендәге 288-ФЗ номерлы Федераль закон

Административ хокук бозулар турында эш буенча эш башкарырга мөмкинлек бирми торган шартлар исемлеге киңәйтелгән.

Әгәр җирле администрациягә җитәкчелек итүче муниципаль берәмлек башлыгының, җирле үзидарә органындагы башка вазыйфаи затның, муниципаль учреждение җитәкчесенең вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга, устав бурычларын башкаруга ассигнованиеләр бирү турындагы тәкъдиме кертелеп тә яки юлланып та (җирле бюджет проектын төзү тәртибенә һәм срокларына ярашлы рәвештә), боларга акча бирелмәве ачыкланса, эш башкару туктатылырга тиеш.

Законнарда билгеләнгән таләпләрнең һәм процедураларның җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәлергә тиешлеген дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарының исәпкә алу бурычлары турындагы нигезләмәләр бәян ителгән.

## «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 10 һәм 71 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 3 ноябрендәге 302-ФЗ номерлы Федераль закон

Россия гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турындагы Законга төзәтмәләр кертелде.

Федераль парламент сайлауларында тавыш бирү көне, федераль органнарның яки шул органнар депутатларының вәкаләтләре сроклары бетә торган елда бердәм тавыш бирү көнен билгеләп, региональ һәм җирле хакимият органнарына сайлауларның тавыш бирү көне белән берләштерелде. Федераль сайлаулар үткәрү елында сайлауларны вакытыннан алда һәм өстәмә үткәрүгә кагылышлы нигезләмәләр төгәлләштерелде.

Парламент кампанияләре арасындагы вакытта (РФ Дәүләт Думасына сайлаулар үткәрелми торган елларда) бердәм тавыш бирү көне сакланып калачак, ул сентябрьнең икенче якшәмбесенә туры киләчәк.

## РФ Хөкүмәтенең «Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 12 августындагы 832 номерлы карары

Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертелде. Муниципаль район өчен, адрес биргәндә мәҗбүри рәвештә шәһәр яки авыл җирлеге күрсәтелергә тиеш. Әмма бу шартның авыллар арасындагы территорияләрдә урнашкан объектларга карамавы искәртелә.

Барлык төр объектлар өчен, адрес биргәндә мәҗбүри рәвештә торак пункт күрсәтелергә тиеш. Ләкин бу шартның торак пунктларның чикләреннән читтә урнашкан объектларга карамавы билгеләп үтелә.

## РФ Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына карата таләпләрне раслау турында» 2015 елның 1 октябрендәге 1050 номерлы карары

Җирлекнең, шәһәр округының җирле үзидарә органнары, җирлекнең, шәһәр округының генераль планнарына нигезләнеп, күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшлиләр һәм раслыйлар. Мондый программаларның структурасына һәм эчтәлегенә карата таләпләр куелган.

Программаларга мәгариф, сәламәтлек саклау, физкультура, массакүләм спорт, мәдәният өлкәләрендә җирле әһәмияттәге социаль инфраструктура объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү буенча чаралар комплексы кергән булырга тиеш.

Программалар социаль инфраструктура объектларыннан файдалануның куркынычсызлыгын, сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген, халыкның алардан файдалана алуын, атап кителгән өлкәләрдә халыкның хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителүенең уйланылган дәрәҗәсенә ирешүне тәэмин итәргә тиеш. Программалар кимендә 10 елга (әмма генераль планнарның гамәлдә булу срогыннан күбрәк вакытка түгел) төзелә.

## РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының финанс йөкләмәләрен финанслашуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына 2015 елда федераль бюджеттан бирелә торган субсидияләрне бүлү турында» 2015 елның 18 августындагы 1584-р номерлы күрсәтмәсе

«2014–2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга авыл

территорияләрен тотрыклы үстерү» федераль максатчан программасы кысаларында авыл гражданнарының торак шартларын яхшырту, авыл торак пунктларын социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары белән комплексы төзекләндерү, шулай ук авыл гражданнарының җирле инициативаларына грант ярдәмен күрсәтү буенча Федерация субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга субсидияләр бүлеп бирелә.

2015 елда бирелә торган субсидияләрне яңадан бүлгәннәр. Бүленмичә калган резервлар бетерелгән, кайбер регионнарга авылларны социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итү буенча субсидияләрнең суммалары арттырылган.

РФ Хөкүмәтенең субсидияләрне бүлү турындагы элек гамәлдә булган күрсәтмәсе үз көчен югалтты.

## РФ Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2010 елның 4 февралендәге 42 номерлы боерыгы белән расланган Күчемсез милекнең дәүләт кадастрын алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 16 июнендәге 376 номерлы боерыгы. РФ Юстиция министрлыгында 2015 елның 23 сентябрендә теркәлде. Теркәү номеры – 38973

Күчемсез милекнең дәүләт кадастрын алып бару тәртибенә төзәтмәләр кертелде. Аерым алганда, аңа шулай ук Россия халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) территорияләре, территорияләрне ызанлау проектлары турында белешмәләр кертелә.

Моңа бәйле рәвештә реестрда Федерация субъектлары арасындагы чик турындагы, муниципаль берәмлекләр, торак пунктлар чиге турындагы язмалар структурасына төзәтмәләр кертелде. Алар арасындагы чикләрнең урнашу урыны тасвирламасына, чиккә хас нокталар озак вакыт дәвамында булачак ызан билгесе белән беркетелгән очракта, ызан билгеләре тасвирламалары өстәләчәк. Тасвирламага шулай ук җир төзелеше объекты картасын (планын) дәүләт мәгълүматлар фондына тапшыру турында мәгълүмат кертелә.

Реестрда территорияне ызанлау проекты турында язманың структурасы аерым күрсәтелә. Үз эченә ул, шул исәптән территория чикләренең урнашу урыны тасвирламасын, ызанлау проектын раслау турында карарның реквизитларын һәм барлыкка килә торган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләрен ала.

Мәдәни мирас объекты территориясе исәп номерының, шулай ук территорияне ызанлау проекты исәп номерының нәрсәләрдән гыйбарәт булуы билгеләнгән.

Төзәтмәләр җир кишәрлеге турындагы белешмәләргә дә кагылды. Аерым алганда, реестрга расланган ызанлау проекты, йә аның урнашу схемасы нигезендә барлыкка килгән җир кишәрлегенең шартлы номеры кертелә. Моннан тыш, социаль яки коммерция файдалануындагы найм йортын төзү өчен, йә мондый йортны төзү максатларында территорияне үзләштерү өчен хакимият органы тарафыннан дәүләт милкендәге кишәрлекне бирү турында акт кабул итү һәм (яки) шартнамә төзү турында язма кертелә.

## «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәреш кертү турында» 2015 елның 7 октябрендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы

ТР Җир кодексында эре инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен җир арендалау кагыйдәләре беркетелгән. Татарстан Республикасында дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен социальмәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен арендага бирү мәсьәләләре регламентлаштырылган.

Арендалау шартнамәсен төзү өчен торглар уткәрү таләп ителми. Күрсәтелгән объектларны урнаштыру өчен җир бирү республиканың, муниципаль берәмлекләрнең стратегик планлаштыру документларында, социаль-икътисадый үсеш программаларында билгеләнгән өстенлекләргә һәм максатларга туры килгән очракта рөхсәт ителә. Болар мәдәният, сәнгать, кинематография, спорт, төзекләндерү, сәламәтлек саклау, мәгариф һәм тәрбия эше, социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү, коммуналь хуҗалык, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, күпкатлы яки җир асты машина кую урыннары (парковкалар), күпкатлы гаражлар булырга тиеш.

Җир бирү өчен масштаблы инвестиция проекты билгеле бер критерийларга туры килергә тиеш. Әйтик, эш урыннары булдыру яки аларның санын арттыру, салымнардан еллык керемнәрнең артуы, зыян күргән гражданнарның – күпфатирлы йортлар төзүдә өлешле катнашучыларның хокукларын яклау чараларын күрү өчен индивидуаль торак йортлар яки күпфатирлы йортлар төзү.

Әлеге критерийларның сыйфат һәм сан күрсәткечләре ТР Президенты тарафыннан билгеләнә. Җир алуда кызыксынган юридик зат ТР Министрлар Кабинетына яки ул вәкаләт биргән органга мөрәҗәгать итә. Юридик затлар объектның яки проектның күрсәтелгән критерийларга туры килүе турында документлар тапшыра.

Арендалау шартнамәсе, ТР Президенты күрсәтмәсенә нигезләнеп, республика дәүләт хакимиятенең башкарма органы яки җир кишәрлекләре белән эш йөртергә вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан төзелә.

## «Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2015 елның 13 октябрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы

Гражданнарның җир мөнәсәбәтләре объектларыннан файдаланганда РФ законнары, ТР законнары таләпләрен үтәвенә планлаштырылган һәм планнан тыш тикшерүләр уздырып, гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе билгеләнгән.

Тикшерүләр муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерүне билгеләү ту-

рында күрсәтмәсе (боерыгы) нигезендә уздырыла. Тикшерүләр документлар буенча һәм (яки) күчмә рәвештә үткәрелә, һәркайсын уздыру срогы 20 эш көненнән артык була алмый. Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерүләр уздырганда тикшерүләрне үткәрү тәртибе һәм гражданнарның хокуклары билгеләнгән.

## ТР Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнар җыенында бирелгән сорауларны хәл итү буенча 2015–2019 елларга чаралар комплексын («юл картасы») раслау турында» 2015 елның 20 августындагы 605 номерлы карары

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнар җыенында бирелгән сорауларны хәл итү буенча 2015–2019 елларга юллар картасы эшләнде. Юллар картасы чараларына капиталь ремонтка, авария хәлендәге торактан кешеләрне күчерүгә кагылышлы мәсьәләләр, республика территорияләрен газлаштыру, су белән тәэмин итү челтәрләрен, канализация челтәрләрен төзү, реконструкцияләү, алмаштыру һәм ремонтлау, урамнарның яктыртылуын кире кайтару, сәламәтлек саклау, мәгариф учреждениеләрен төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау, күпфункцияле үзәкләр төзү, юллар, күперләр ремонтлау һ.б.ш. мәсьәләләр кертелгән.

Проблемалы урыннарның адреслары һәм аларны тормышка ашыруның тәкъдим ителгән механизмнары (дәүләт программалары, муниципаль программалар) билгеләнгән. «Юл картасы» чараларын үтәү турындагы хисаплар квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15 числосына кадәр, ТР Икътисад министрлыгына тапшырыла.

## ТР Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүне оештыруның үрнәк регламентын раслау турында» 2015 елның 28 августындагы 631 номерлы карары

Документ белән расланган регламент өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча белем алуга (квалификация күтәрүгә, һөнәргә яңадан әзерләүгә) җибәрелә торган ТР дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең тәртипләре, хокуклары һәм бурычларының бердәм, шулай ук өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча укырга тыңлаучылар җибәрүче ТР дәүләт хакимияте органнары җитәкчеләренең һәм ТР муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең хокук һәм бурычларының кагыйдәләрен билгеләү максатларында эшләнгән.

## ТР Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милкендә булуы чикләнмәгән җир кишәрлекләренә сервитутны гамәлгә кертү турындагы килешү буенча түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау хакында» 2015 елның 28 сентябрендәге 712 номерлы карары

ТР муниципаль районнары һәм шәһәр округлары территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милкендә булуы чикләнмәгән җир кишәрлекләренә сервитутны булдыру өчен яклар килешүе буенча түләү күләме исәпләп чыгарыла торган формула билгеләнгән.

Даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга яисә гомерлеккә мирас итеп бирелгән, яисә арендага тапшырылган җир кишәрлекләре өчен түләү күләме җир кишәрлегенә күрсәтелгән хокукларның сервитут булдырылганга кадәрге һәм аннан соңгы базар бәясендәге, ул үз чиратында бәя кую эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә, аерма буларак кабул ителә.

## ТРнда минималь хезмәт хакы турында Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы Эш бирүчеләре берләшмәләренең координация советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында 2015 елның 2 октябрендә төзелгән килешү

ТР Һөнәр берлекләре федерациясе, ТР Эш бирүчеләре берләшмәләренең координация советы, ТР Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы турында килешү төзелгән.

Икътисадның бюджеттан тыш секторы оешмаларында минималь хезмәт хакы аена кимендә 7309 сум күләмендә билгеләнә. Дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр өчен – МРОТ турындагы федераль закон нигезендә (5965 сум).

Эш бирүче белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы һәм килешүнең гамәлдә булу көче кагылган хезмәткәрнең айлык хезмәт хакы килешүдә билгеләнгән минималь күләмнән кимрәк була алмый.

Хезмәт хакының билгеләнгән күләме хезмәт өчен түләү буенча тагы да югарырак минималь гарантияләр билгеләү өчен чик түгел.

Килешүнең гамәлгә ашырылуын тәэмин итү өчен яклар килешүгә республикада эшчәнлек алып баручы һәм килешү төзүдә катнашмаган эш бирүчеләрнең кушылуын тәэмин итү чараларын күрә.

Әгәр эш бирүчеләр аларга кушылудан, сәбәпләрен күрсәтеп, язма рәвештә баш тартмасалар, килешү әлеге эш бирүчеләргә таралган дип санала һәм алар тарафыннан мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиеш. Баш тарту гризасы килешүгә кушылу турында тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән алып 30 календарь көн эчендә ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына тапшырыла.

Килешү икътисадның бюджеттан тыш секторы оешмаларына – республика территориясендә эшчәнлек алып баручы, килешү төзегән яки аңа кушылган юридик затларга, физик затларга, ИПБОЮЛларга тарала. Килешү аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм яңа килешү үз көченә кергәнче гамәлдә була.

# АСК көне

7 октябрдә Татарстан гадәттәгечә республиканың агросәнәгать комплексы хезмәткәрләрен тәбрик итте. Бәйрәм тантаналары Казанның «Корстон» сәүдә-күңел ачу комплексында узды. Аның бер залында республикабыз авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре оештырган азык-төлек күргәзмәсе урнаштырылган иде.

Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре һәм бәйрәм кунаклары алдында ясаган чыгышында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов болай диде: «Инде биш ел рәттән һава торышы шартлары уңайсыз тора, шулай булуга карамастан, быел республикада 3,5 млн тонна ашлык, 2 млн тонна шикәр чөгендере, 1,5 млн тонна бәрәңге, 1,8 млн тонна сөт җитештерелде. Бу – авыл халкының гаять зур хезмәте нәтиҗәсе». Республика башлыгы агросәнәгать комплексы хезмәткәрләренә, шулай ук ТР шәһәрләрендә азык-төлек ярминкәләре оештыруда турыдан-туры катнашкан авыл халкына рәхмәтен белдерде.

«Сәяси хәлнең катлаулылануы халыкны азык-төлек белән тәэмин итүдә билгеле бер кыенлыклар китереп чыгарды. Әмма без Татарстанның, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләрнең республика халкын иң югары сыйфатлы азык-төлек белән тәэмин итәргә сәләтле икәнен күрсәттек. Бүген безнең республика продуктларны куллануга караганда күбрәк җитештерә. Бу тәҗрибәне бүтән төбәкләрдә дә җәелдерергә кирәк», – диде Рөстәм Миңнеханов. Ул авыл җирлеге үсешенә юнәлдерелгән барлык социаль программаларның үз эшләрен дәвам итәчәген ассызыклады. «Авыл кешесенең тормыш дәрәҗәсе шәһәрдә яшәүченекеннән берни белән дә аерылмаска тиеш, моны хәл итү – безнең бурыч», – диде ул.

Соңыннан республика агросәнәгать комплексының аеруча лаеклы дип табылган хезмәткәрләренә Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре тапшыру тантанасы уздырылды.






Фотолар www.tatarstan.ru сайтыннан


День работника
сельского хозяйства
перерабатывающей
промышленности


Бәйрәм










# *Татарстан муниципаллары журналы*







## Язылу индекслары:

**16867 –** татар телендә

**16863 –** рус телендә

**Журналга барлык элемтә бүлекләрендә язылырга була**